3° 2017

# ФӘННИ ТАТАРСТАН



ISSN 2499-9741

КАЗАН

***Журнал «2014 — 2020 елларга Татарстан Республикасында ТР дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында нәшер ителә***

*Массакүләм мәгълүмат чарасын регистрацияләү турындагы таныклык ПИ № ФС77-65242 01.04.2016*

► **ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ

► **ИДАРӘ:**

МИҢНУЛЛИН К.М., филология фәннәре докторы, профессор, идарә җитәкчесе (Казан)
АЛИШИНА Х.Ч., филология фәннәре докторы, профессор (Төмән)
АРСЛАНОВ М.Г., сәнгать фәннәре докторы, профессор (Казан)
БАҺАВЕТДИНОВ Ф.Н., хокук фәннәре докторы, профессор (Казан)
ВӘЛИЕВ Р.И., Татарстан Республикасы Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр буенча комитеты рәисе (Казан)
ДӘҮЛӘТ НАДИР, тарих фәннәре докторы, профессор (Истанбул)
ГЫЙЛӘҖЕВ И.А., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗАҺИДУЛЛИНА Д.Ф., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗӘКИЕВ М.З., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ҖАМАЛЕТДИНОВ Р.Р., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
КЕРИМОВ И.А., филология фәннәре докторы, профессор (Симферополь)
МИҢНЕГУЛОВ Х.Й., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
МӨХӘММӘТШИН Р.М., сәяси фәннәр докторы, профессор (Казан)
НАСИПОВ И.С., филология фәннәре докторы, профессор (Уфа)
ӨНӘР МОСТАФА, фән докторы, профессор (Измир)
СӘЛАХОВ М.Х., физика-математика фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты (Казан)
САЛИХОВ Р.Р., тарих фәннәре докторы (Казан)
СИБГАТУЛЛИНА Ә.Т., филология фәннәре докторы, профессор (Мәскәү)
СӨЛӘЙМАНОВ Җ.Ш., техник фәннәр докторы, профессор (Казан)
ТӘСИН ҖӘМИЛ, Бабеш-Больяй университетының Тюркология һәм Үзәк Азияне өйрәнү институты директоры (Клуж-Напока, Румыния)
ТИМЕРХАНОВ А.Ә., филология фәннәре докторы (Казан)
ФӘТТАХОВ Э.Н., Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары — мәгариф һәм фән министры (Казан)
ХИСАМОВ Н.Ш., филология фәннәре докторы (Казан)
ХУҖИН Ф.Ш., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШӘЙДУЛЛИН Р.В., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШАМИЛЬОГЛУ ЮЛАЙ, тарих фәннәре докторы, профессор (Мэдисон)

► **БАШ РЕДАКТОР**

КИМ МӨГАЛЛИМ улы МИҢНУЛЛИН

► **БАШ РЕДАКТОР УРЫНБАСАРЛАРЫ:**

ГОМӘРОВ И.Г., ДӘҮЛӘТШИНА Л.Ш. (җаваплы секретарь)

► **РЕДАКТОРЛАР:**

ЗАҺИДУЛЛИН И.К. (тарих), СОЛТАНОВА Р.Р. (сәнгать),
МИРХАЕВ Р.Ф. (тел белеме), ГАРИПОВА Л.Ш. (әдәбият һәм халык иҗаты)

► **ГАМӘЛИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘР:**

Я.М. АБДУЛКАДЫЙРОВА, Н.Т. АБДУЛЛИНА, Е.Ф. ЛУКЬЯНЧЕНКО

**БУ САНДА**


## ТЕЛ БЕЛЕМЕ

*Бәширова И.Б.* Иске татар телендә вариантлылык мәсьәләсенә карата . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7
*Миңнуллин Б.К.* XX гасыр башы татар газетасы һәм татар милли әдәби теленең формалашуы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 17
*Мирхәев Р.Ф.* Татар лингвокультурасында «Алла» концепты . . . . 22
*Хөсәенова А.Җ.* Татар теленең диалектларында соматизмнар . . . . 28

## КӘРИМ ТИНЧУРИНГА – 130

*Закирҗанов Ә.М.* XX гасырның I чирегендә татар драматургиясе үсешенә нисбәтле Кәрим Тинчурин иҗаты . . . . . . . . . . . . . 32
*Салихова А.Р.* Кәрим Тинчурин пьесаларының сәнгати үзенчәлеге . 41
*Фәйзерахманов Р.Ф., Әхмәтгалиева А.Г., Макарова В.Ф.* Кәрим Тинчурин әсәрләренең сәхнә язмышы . . . . . . . . . . . 46
*Галимова Э.М.* К. Тинчуринның драма әсәрләре үсешенә музыканың йогынтысы: «Каракүз» музыкаль кыйссасы мисалында . 56
*Миңнуллина Ф.Х.* К. Тинчурин драматургиясендә шәхес фаҗигасе . 60
*Фәрдиева Д.Р.* К. Тинчурин пьесаларында психология һәм геройларның эчке дөньясын чагылдыру («Соңгы сәлам» һәм «Сүнгән йолдызлар») . . . . . . . . . . . . . . . . 65
*Нургаянова Н.Х.* К. Тинчуринның иҗади мирасын саклауда һәм пропагандалауда музыкаль белемнең роле . . . . . . . . . . . 69

## ХАЛЫК ИҖАТЫ

*Закирова И.Г.* Туган телдә кылган догам . . . . . . . . . . . . . . . . . . 74
*Дәүләтшина Л.Х.* Татар халкының мифологик системасына бер караш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 81

## ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕ

*Беккин Р.И.* Гатаулла Баязитовның соңгы гозере . . . . . . . . . . . 92
*Хәбибуллина З.Р.* Башкортстанда мөселманнарның «изге урыннар»ы (1944–1965 еллар) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 97
Мөселман руханиларының 1905 елгы Уфа корылтаенда каралган кайбер проектлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 103

## МИЛЛИ МӘГАРИФ

*Багирова Э.Г.* Балалар бакчасында татар теле укытуның үзенчәлекләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 114

## ТАБИГАТЬ ФӘННӘРЕ

*Миңнуллина Л.Ф., Лотфуллин М.Т.* Ризосфера бактерияләренең үсемлекләр үсешенә тәэсире . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 119
*Миңнуллина Л.Ф., Шәйдуллина Э.Р., Мәрданова А.М.* Оппортунистик инфекцияләр сәбәпчесе Morganella morganii: антимикроб матдәләргә чыдамлылыгы һәм биоэлпәләр хасил итүе . 124

**ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ**

*Харрасова Р.Ф.* Фәнгә багышланган гомер
*(Галимҗан Нигъмәтинең тууына 120 ел)* . . . . . . . . . . . . . 130
*Мөхәммәтшин З.Г.* Шәркыятьче галим үрләре
*(С. Гыйләҗетдиневкә – 70)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 144

**СӘНГАТЬ**

*Улемнова О.Л.* Татарстан Республикасы Дәүләт сынлы сәнгать музее тупланмасында илебезнең 1910–1920 еллар авангард сәнгате . 150
*Герасимова Н.В.* 1920 елларда Татарстан музейлары сәнгати коллекцияләрен формалаштыруда Дәүләт музей фондының роле . 157
*Кривошеева Т.Н.* Казан сәнгать мәктәбендә скульптура дәресләре алып баруның Көнбатыш Европа һәм Көнчыгыш традицияләре . 162

**ЯҢА КИТАПЛАР**

Тормышка ашкан хыял . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 167
Велиев А. XXI гасыр башы Азәрбайҗан театры . . . . . . . . . 170
Сабитова И.И. Татар теленең сүзьясалыш сүзлеге:
«кеше» тематик төркеменә караган лексика . . . . . . . . . . . 172

**ФӘННИ-ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШЫБЫЗДАН**

## В НОМЕРЕ

### ЯЗЫКОЗНАНИЕ


*Баширова И.Б.* Вариативность в старотатарском языке . . . . . . . . 7
*Миннуллин Б.К.* Татарская газета начала XX века и формирование татарского литературного языка . . . . . . . . . . 17
*Мирхаев Р.Ф.* Концепт «Алла» в татарской лингвокультуре . . . . 22
*Хусаинова А.Дж.* Соматизмы в диалектах татарского языка . . . . 28


### КАРИМУ ТИНЧУРИНУ – 130


*Закирзянов А.М.* Творчество Карима Тинчурина в свете развития татарской драматургии в первой четверти XX в. . . . . . . . . . . . . . 32
*Салихова А.Р.* Художественное своеобразие пьес Карима Тинчурина . 41
*Файзрахманов Р.Ф., Ахметгалиева А.Г., Макарова В.Ф.* Сценическая судьба произведений Карима Тинчурина . . . . . . . 46
*Галимова Э.М.* Влияние музыки на развитие драматических произведений Карима Тинчурина: на примере музыкальной поэмы «Каракүз» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 56
*Миннуллина Ф.Х.* Трагедия личности в драматургии К. Тинчурина . 60
*Фардеева Д.Р.* Психология в пьесах К. Тинчурина и раскрытие внутреннего мира героев (на примере пьес «Последний привет» и «Угасшие звезды») . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 65
*Нургаянова Н.Х.* Роль музыкального образования в сохранении и пропаганде творческого наследия К. Тинчурина . . . . . . . . . . 69


### НАРОДНОЕ ТВОРЧЕСТВО


*Закирова И.Г.* Молитва на родном языке . . . . . . . . . . . . . . . . 74
*Давлетшина Л.Х.* Взгляд на мифологическую систему татарского народа . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 81


### СТРАНИЦЫ ИСТОРИИ


*Беккин Р.И.* Последняя просьба Атауллы Баязитова . . . . . . . . . 92
*Хабибуллина З.Р.* «Святые места» мусульман в БАССР (1944–1965 гг.) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 97
Некоторые проекты, рассмотренные на курултае мусульманского духовенства в 1905 г. в Уфе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 103


### НАЦИОНАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ


*Багирова Э.Г.* Особенности преподавания татарского языка в детском саду . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 114


### ЕСТЕСТВЕННЫЕ НАУКИ


*Миннуллина Л.Ф., Лутфуллин М.Т.* Ростостимулирующая активность бактерий ризосферы. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 119
*Миннуллина Л.Ф., Шайдуллина Э.Р., Марданова А.М.* Возбудитель оппортунистических инфекций Morganella morganii: резистентность к антибиотикам и биопленкообразование . . . . 124

## ПЕРСОНАЛИИ

*Харрасова Р.Ф.* Жизнь, посвященная науке
*(120 лет со дня рождения Галимджана Нигмати)* . . . . . . . 130
*Мухаметшин З.Г.* Достижения ученого-востоковеда
*(С. Гилязутдинову –70)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 144

## ИСКУССТВО

*Улемнова О.Л.* Отечественное авангардное искусство
1910–1920-х гг. в собрании Государственного музея
изобразительных искусств Республики Татарстан . . . . . . . . 150
*Герасимова Н.В.* Роль Государственного музейного фонда
в формировании художественных коллекций музеев Татарстана
в 1920-е гг. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 157
*Кривошеева Т.Н.* Традиции западноевропейской и восточной
школ в преподавании скульптуры в Казанской художественной
школе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 162

## НОВЫЕ КНИГИ

Воплощенная мечта. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 167
Велиев А. Азербаджанский театр начала XXIвека . . . . . . . . . 170
Сабитова И.И. Словообразовательный словарь татарского языка:
лексика тематической группы «человек» . . . . . . . . . . . . . 172

УДК 811.512.145

***И.Б. Бәширова***

# ИСКЕ ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ВАРИАНТЛЫЛЫК МӘСЬӘЛӘСЕНӘ КАРАТА

На протяжении всей своей истории старотатарский литературный язык функционировал в различных письменных вариантах, которые дифференцириуются на основе употребления арабо-персидских заимствований, слов и словоформ живого разговорного языка и огузско-турецких элементов. В статье анализируется особенности отражения данных вариантов в произведениях старотатарской литературы, созданных в Поволжье в различные эпохи.

**Ключевые слова:** тюркский язык, тюрки, старотатарский язык, живой разговорный язык, письменный литературный язык, арабско-персидские заимствования, огузско-турецкие слова и словоформы, норма и вариативность нормы.

Тормыш-көнкүреш өчен зарур булган эшчәнлек төрләре, әдәби язма текстларда чагылыш тапканнан соң, иҗтимагый фикер (аң) дәрәҗәсендә ныгытыла һәм, дәүләт тарафыннан кирәк дип саналса, аларны алга таба яшәтү дәвам ителә. Яңа вазгыять шартларында барлыкка килгән эшчәнлек төрләрен характерлап язу барышында әдәби телнең кулланылыш өлкәсе тагын да киңәя һәм шул нигездә ул структур яктан да байый (әдәби телдә яңа сүзләр, терминнар файдаланыла башлый һ.б.). Дәверләр буена эзлекле рәвештә үсештә булган иске язулы телләрдә традицион нормалар төрле объектив сәбәпләр нәтиҗәсендә барлыкка килгән вариантлары белән бергә кулланылган. Норма һәм норма вариантлылыгы белән бәйле мәсьәләләрне теоретик һәм практик аспектларда тикшерү әдәби телләрнең үсешен күзалларга, шул үсешне яшәтә торган вариантларның табигате һәм вазифасын тулырак ачыкларга мөмкинлек бирә. Алар соңгы елларда дөнья күргән «Татар әдәбияты тарихы» (2014) һәм «Татар әдәби теле тарихы» (2015) хезмәтләрендә чагылыш тапты. Биредә төп максат – мең еллар буена кулланылышта булган төрки-татар теленең төрле вариантлары барлыкка килү сәбәпләрен ачыклау. Әлеге үзенчәлекнең хәзерге әдәби телдә чагылыш табу-тапмау мәсьәләсенә ачыклык кертү бүгенге көндә дә тел белемендә хәл итәсе проблемаларның берсе булып кала бирә.

**Төрки-татар теле – иске язулы телләрнең берсе.** *Төрки* терминының, төрки гаиләдәге кавемнәрнең исем-шәрифе, аларның сөйләмә һәм язма телләренең атамасы булуы М. Кашгариның «Диване лөгатет-төрек» сүзлегендә тәфсилләп аңлатылуы мәгълүм (466/1072–1074). Бу атамалар хәзерге вакытта да шул ук мәгънәләре белән кулланыла. «Языки мира: тюркские языки» исемле энциклопедик басмада язма традицияләре ерак

гасырлардан килә торган һәм язылу тарихы билгеле булган язма истәлекләргә ия борынгы төрки телләр рәтендә, азәрбайҗан, төрек, төрекмән, уйгыр, үзбәк телләре белән бергә, татар теле дә карала [Языки мира..., с. 358]. Иске язулы телләр, кагыйдә буларак, әдәби нормаларга нигезләнә, ә нормалар традицияләр нигезендә дәвам иттерелә. Язма норма дигәндә, график билгеләр системасы һәм аларның графо-орфографик тәртибе күздә тотыла.

Бүгенге көндә Идел – Чулман буйларында Болгар дәүләте чорыннан сакланып калган рун язулы истәлекләр табылу дәвам итә [Курбатов, б. 13–32]. 922 елда рәсми рәвештә ислам дине кабул ителү белән бергә, гарәп алфавиты гамәлгә куела һәм әлеге графика болгар-татарларда XX йөзнең беренче чирегенә кадәр кулланылышта була. Гарәп язуында Болгар дәүләтендә XIII гасырда угыз-кыпчак нигезле телдә Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы иҗат ителә [Хисамов, б. 10]. Поэма 1233 елның 12 маенда тәмамлана. XIII–XIV гасырларда Болгар дәүләтенең Казан төбәгендә гарәп графикасы белән каберташларга штамп-текстлар язылa. Болардан алдарак, XII йөздә, Төркестанның мәдәни үзәге саналган Яссы шәһәрендә, кимәк-кыпчак-искел-болгар-татарларның сөйләмә телендәге уртак сүз, сүзформаларга нигезләнеп әдәбиләштерелгән, Әхмәт Ясәви (1166 елда вафат), Сөләйман Бакыргани (1111–1186) һ.б.ның әсәрләрендә чагылыш тапкан, киң катлам төрки кавемenә аңлаешлы телдә язу башлана. Галимнәр фикеренчә, «Кыйссаи Йосыф» әсәрендә дә бу телнең традицияләре дәвам иттерелә [Гайнетдинов, б. 252–253]. Димәк, хәзерге татар әдәби язма теленең мең еллар буена эзлекле рәвештә килә торган тарихы бар, дип әйтә алабыз. Төрки-татар телендә барлык жанр-стильләргә дә караган (матур әдәбият, эш кәгазьләре, фәнни, дини-дидактик, иҗтимагый-публицистик һ.б.) язма әдәбият барлыкка килә. Алар галимнәр тарафыннан барысы да диярлек өйрәнелгән. Әмма бүгенге көндә әдәби тел тарихын тулаем күз алдына китерү өчен, бу истәлекләрне өйрәнү барышында моңарчы кулланылган ысуллар кулай булмаганга, фәнни тикшеренүләрнең методологиясен яңартып, аларны ныклы бер системага нигезләп, язма телнең традициясен, норма һәм норма вариантларының кулланылыш үзенчәлекләрен тәгаенләргә кирәк. Аерым алганда, язма әдәби телне тармакларга бүлеп тикшерә башлаганчы, алдагы хезмәтләрдә чагылыш тапмау сәбәпле, төрки тел һәм иске татар теленең табигатен, вазифасын, әдәби телнең тарихын һәм язма нормаларның үсешен өйрәнгәндә кулланыла торган метод-ысулларны барлау, бу мәсьәләләрнең ничек итеп өйрәнелүен ачыклау соралды. Моның өчен язма телнең Болгар, Алтын Урда чорларында, Казан ханлыгында һәм аннан соңгы дәверләрдә ничек яшәвен, ничек файдаланылуын күз алдына китерү зарур. Нәтиҗәдә, иске татар әдәби теленең (XIII гасыр –

XX гасыр башы) фонетика һәм графика тармакларында язма традициянең ничек баруы, норма һәм аның вариантлары мәсьәләсе анализланып, «Татар әдәби теле тарихы» ның 1 томы дөнья күрде (Казан, 2015). Бүгенге көндә әлеге эш морфология һәм лексика тармаклары өчен алып барыла.

**Язма телнең гомумтөрки чорда ук аристократ-абруйлы (престижный) һәм халыкчан-сөйләмә вариантларга дифференциацияләнүе.** Бу мәсьәлә беренче мәртәбә «Татар әдәби теле тарихы»н язганда калкып чыкты. Әдәби телнең тарихын ныклы бер системага салып тикшергәндә һәр дәвердә язма телнең табигате һәм вазифасының нинди үсеш-үзгәреш кичергәнлеге күренә. XI гасырдан башлап XIX гасыр ахырына кадәр иҗат иткән авторларның барысы да диярлек әсәрләренең төрки телдә язылуына, ягъни гарәп яисә фарсы телендә язылмаганлыгына басым ясап, кат-кат искәртә баралар. Әлеге аерымлану «Котадгу Белек» һәм «Диване хикмәт»ләрдән башлана. Йосыф Хаҗ Баласагунлының төрки дөньяда ислам идеологиясен аңлату һәм тарату максатын күздә тотып язылган беренче мәшһүр әсәрендә (1069), үзеннән-үзе аңлашылганча, гарәп һәм фарсы алынмалары мул кулланыла. Шул ук вакытта анда Орхон язмаларыннан килә торган югары стильдәге региональ төрки архаик сүз һәм сүзформалары да файдаланыла. Галимнәр фикеренчә, бу әсәр Караханилар империясендә (840–1212) ханнар ханы Кара Бограхан хөкем сөргән вакыттагы аристократ-абруйлы язма әдәби тел белән иҗат ителгән [Кононов, с. 502; Благова, с. 99–100]. Әхмәд Ясәвинең (1091–1166) «Диван-е хикмәт»ләрендә исә «...аять, хәдис мәгънәсе төрки булса муафикъ / Мәгънәсенә йиткәнләр йиргә куяр бүркене», – дип, төрки телдә дә гыйлемле булу мөмкинеге турында белдерелә [Татар әдәбияты.., 2014, б. 139]. Нәтиҗәдә алынмаларны куллану билгеле бер дәрәҗәдә азая.

Төрки тел дигәндә, киң далаларда таралып яшәгән төркиләрнең диалектларындагы аларның күбесе өчен уртак һәм әдәбиләштерелгән сөйләмә сүз һәм сүзформаларына нигезләнгән халыкчан язма әдәби тел истә тотыла. «Татар әдәби теле тарихы» хезмәтен язу барышында әдәби истәлекләрнең дәверләр дәвамында янәшә кулланылып килгән, берсе икенчесенә бәйле булган ике төрле төрки телдә язылганлыгы мәгълүм булды [Татар әдәби..., 2015].

Аристрокат-абруйлы классик иске татар телендә, ягъни сөйләмә-диалекталь сүз һәм сүзформаларына караганда, гарәп-фарсы алынмалары күбрәк кулланылган телдә язылган әсәрләр дигәндә, XIII гасырда Болгар дәүләтендә тудырылган «Кыйссаи Йосыф», XIV гасырда Алтын Урдада иҗат ителгән дини вә дөньяви әдәбият, XV–XVI гасыр уртасына кадәр Казан ханлыгында язылган Өмми Камал шигырьләре, Максудиның (Мөхәммәд Әмин) «Могҗизнамә» һәм «Мансур Хәлләҗ кыйссасы» әсәрләре, Мөхәммәдъяр поэмалары,

Кол Шәриф әсәрләре, Әднаш Хафизның «Сираҗел колүб» әсәре күз алдында тотыла. XVI гасыр ахыры – XVII гасырда проза жанры үсеш алу сәбәпле, бу мәсьәлә шактый катлаулана. Тәгаен билгеле иҗтимагый-сәяси вакыйганы «әкиятләштереп» язылган «Җәмигыт-тәварих» [Татар әдәбияты..., 2014, б. 205] һәм «...халык хыялы күзаллаган тарихи хәл» буларак язылган «Дәфтәре Чыңгызнамә» («Дастаннар китабы») [Татар әдәбияты..., 2014, б. 207] әсәрләре телендә халык авыз иҗатына хас җанлы сөйләмә формаларның чагылышы табигый булып кабул ителә. Фарсы телендә иҗат ителгән әсәрен төркиләштереп язган Суфи Аллаһиярның (1616–1713) «Сөбател-гаҗизин» теле, әлбәттә, абруйлылыгын саклап, Мәүлә Колыйның халыкчан сөйләмә телне әдәбиләштерелеп язылган «Хикмәтләр»е теленнән аерыла. XVIII гасыр урталарыннан башлап XIX гасырның беренче яртысына кадәр дәвам иткән дәвердә Батыршаның (Абдулла Алиев) (1710–1762) «Гарызнамә»се (1756), Т. Ялчыголның (1768–1838) «Рисаләи Газизә: шәрхе «Сөбәтел-гаҗизин» (1796/1847/1850) әсәре, Г. Утыз Имәни (1754–1834), Ә. Каргалый (1782–1833), Һ. Салихов (1794–1867), Ш. Зәки (1822–1865) һәм Г. Чокрыйның (1826–1889) бераз соңрак язылган тезмә әсәрләренең гарәп-фарсы алынмалары һәм гомумтөрки архаик формалар мул кулланылган аристократ төркидә иҗат ителүе мәгълүм.

Шул ук вакытларда абруйлы классик иске татар телендәге әсәрләр белән рәттән халыкчан юнәлештәге классик иске татар телендә, ягъни җанлы сөйләмә-диалекталь сүз, сүзформаларының гарәп вә фарсы алынмаларына караганда күбрәк кулланылып язылган әсәрләр параллель бара. Биредә XV гасыр – XVI гасыр уртасында яшәгән Хәсән Кайгы Дусмәмбәт, Казтуган һ.б. шагыйрь-җыраулар иҗатын, XVII гасырда иҗат иткән Мәүлә Колый «Хикмәтләр»ен, билгеле бер дәрәҗәдә халык авыз иҗаты үзенчәлекләрен файдаланып язылган «Җәмигыт-тәварих», «Дәфтәре Чыңгызнамә» кебек тарихи истәлекләрне искә алу кирәк. XVIII гасыр дәвамында иҗат ителгән илаһи бәетләр, авторлар үзләре искәртә барганча, Болгар-Казан шивәсенең җанлы сөйләмә һәм халык авыз иҗаты үзенчәлекләре белән баетылган халыкчан иске татар телендә тудырылганнар. Бу юнәлеш XIX гасырда Баһавиның «Бүз егет китабы» (1842) һәм Г. Кандалый (1797–1860), Әхмәт Уразаев-Кормаши (1855–1883), М. Акмулла (1831–1895), Яков Емельянов (1848–1893) шигырьләрендә дәвам итә. Бу авторларның әсәрләрен фәнни өйрәнү күрсәткәнчә, традиция булып параллель килә торган ике варианттагы язма телдә иҗтимагый тормыш таләпләре яисә иҗтимагый фикер үсеше, әдәби-мәдәни багланышлар тәэсирендә әдәби телнең һәр чорында билгеле бер яңарышның барлыкка килүе күзәтелә.

**Әдәби телдә язма норма һәм вариантларның яңарып дәвам ителеше.** Тикшерүләрдән күренгәнчә, һәр чорда әдәби тел-

нең кулланылышында, гасырлардан гасырларга күчеп килгән ике төрле традициясе-нигезе сакланган хәлдә, үзенә хас булган яңалыклар барлыкка килә. Һәр дәвернең иҗтимагый-сәяси шартларына, әдәби телнең әсәр язылган төбәктә яшәүчеләрнең җанлы сөйләмә һәм халык авыз иҗаты әсәрләре теле үзенчәлекләре белән бәйләнешенә, шул чорда яшәгән авторларның белеме, нинди тема күтәрүләре, аларның әдәби телнең кайсы жанр-стилендә, кайсы укучыны күздә тотып иҗат итүләренә, гомумән максатлары нинди булуга һ.б. шартларга бәйләнеш-мөнәсәбәттә әдәби телдә барлыкка килгән яңалыклар язма норманың дәвам ителешенә дә, вариантларның табигатенә һәм вазифасына да, хәтта төрки тел дигән төшенчәнең нинди мәгънә белән кулланылышына да тәэсир итәләр. Әлеге катлаулы мәсьәләләр әдәби тел тарихын җентекле анализлау нәтиҗәсендә генә ачыла баралар.

Югарыда китерелгән мисалларга бәйле рәвештә, иҗтимагый-сәяси шартлар дигәндә, иң беренче чиратта, төрки-татарларның, XII–XVI гасыр уртасына кадәр дәүләтле халык булып яшәп тә, 1552 елдан чит дәүләттә яшәргә мәҗбүр ителүе истә тотыла. Бу вакытка кадәр язылган әдәбиятта әдәп-әхлак, Аллаһыдан курку, гөнаһлардан саклану кебек мәсьәләләр яктыртыла. XVI гасырның икенче яртысыннан башлап иманны саклау төп проблема булып күтәрелә, ул риваятьләргә нигезләнеп аңлатыла. XVII йөздә белемсезлек, мәгърифәтсезлекнең имансызлыкка илтүе мәсьәләләре яктыртыла башлый, «онытылып юкка чыгу чигенә җиткән әсәрләр» кабат җанландырыла» [Татар әдәбияты ..., 2014, б. 207]. Иман өчен җаваплылык тулысынча шәхеснең үзенә йөкләнә, алгы планга кешенең иҗтимагый активлыгы, үз сүзендә нык тору зарурлыгы кебек мәсьәләләр чыга. XVIII гасыр урталарына кадәр, ягъни мәдрәсәләр торгызылып, милли мәгариф аякка басканчы, әдәби истәлекләрнең барысы да халыкның хәтерен, иманын, киләчәккә булган ышанычын саклау максаты белән языла, аның шәһәравыллары, җир-сулары, урманкырлары, укымышлы кешеләренең исем-шәрифләре, аларның каберләре кайда булулары тәфсилләнә, ислам дине кануннары буенча яшәгәндә генә кеше булып калырга мөмкинлек аңга сеңдерелә. Бу чорда бер үк әсәрләрдә гарәп-фарсы алынмалары һәм төрки-татар сүз һәм сүзформалары, нигездә, бергә файдаланыла. Прозада синкретизм саклана: бер үк әсәрдә хәзерге филологиядә хосусый сөйләм тибы булып аерып чыгарылган төрле стильләрнең берьюлы берничәсенә (әдәби, фәнни, публицистик) хас үзенчәлекләрнең бергә үрелеп китүе күренә. Галимнәр белдергәнчә, моның ачык мисалы булып Батыршаның «Гарызнамә» трактаты санала [Гайнетдинов, б. 96].

Шуның белән бергә җәмгыятьттә бара торган вакыйгаларның язма текстларда турыдантуры теркәлә баруы әдәби телдә жанр-стильләрнең аерылуын көчәйтә. Бу хәл Пугачев хәрәкәте

белән бәйле рәсми эш кәгазьләрендә ачык чагыла (1773–1775), иске татар телендә өндәмә, манифест, указ, устав, билет һ.б. рус теле терминнары файдаланылып языла башлый [Фасеев, с. 62].

Төрки тел дигән төшенчә, XVI гасыр ахырында Әднаш Хафизның «Сираҗел колүб» әсәрендә гарәби һәм фарсига каршы куелып, татар халкының яшәгән вазгыятькә бәйле рәвештә, заманалар ахыры җитү сәбәпле (Казан ханлыгының Мәскәү дәүләте тарафыннан басып алынуы күздә тотыла), исән калганнарның теле мәгънәсендә кулланыла башлый [Татар әдәби..., 2015, б. 146]. Алга таба ул Т. Ялчыголның «Рисаләи Газизә» әсәрендә «кәндү-үз телемез», ягъни болгар-татар телендә сөйләшүчеләрнең телләре дигән мәгънәдә дәвам ителә. Шул ук вакытта Г. Утыз-Имәнинең, гыйлем белән генә гамәл кылу дөрес була, дигән фикере үстерелә. Язма телнең күпсанлы гарәп-фарсы алынмалары белән туендырылуы Ә. Каргалый, Һ. Салихов, Ш. Зәки һ.б. иҗатларында дәвам ителә. Алар үзләренең әсәрләрен аңлы рәвештә авторның фикер агышын аңлый торган укымышлы-гыйлемле кешегә багышлап язалар.Укучыга карата мөнәсәбәт иҗтимагыйфункциональ яңгыраш ала. Болгар-Казан шивәсе дип атала торган төрки телне куллануда иҗтимагый-социаль аерымлану хасил була. Шулай итеп, гасырларны узып килгән төрки телнең аристократ-абруйлы һәм сөйләмә-халыкчан вариантларының кулланылуы, һәр дәвердә төрле иҗтимагый вакыйгаларга яраклашу максатыннан билгеле бер яңарышлар алып дәвам итә.

XIX гасырның урталарында татар халкының бөек мәгърифәтчесе К. Насыйри (1825–1902) эшчәнлегенең башында ук сөйләү теле белән язу теленең хосусый үзенчәлекләре булуына игътибар итә. (Бу мәсьәләнең асылы әлегә кадәр җитәрлек дәрәҗәдә аңлатылмаган.) Әдәби әсәрләрен аңлы рәвештә халыкчан тел белән, фәнни хезмәтләрен, «һәрбер фәннең үзенә мәгълүм истыйляхы бардыр вә үзенә махсус теле бардыр...» дип, һәр фән тармагының үзенә яраклы булган терминнарын кулланып яза.

Бу чорда татар язма теле функциональ-стилистик яктан аерымланып тикшерелү мөмкинлеге ала. С. Кукляшев тарафыннан тәкъдим ителгән, язма татар телен гади (простой), эш (деловой), гыйльми (ученый) төрләргә бүлеп карарга мөмкин, дигән теоретик фараз [Кукляшев, 1859] К. Насыйри иҗаты белән гамәли яктан раслана. Төрле авторларның төрле әсәрләрендә параллель килә торган ике вариантлы иске татар теле XIX гасырның ахырларына таба Г. Кандалый (1797–1860), Г. Тукай (1886 –1913) кебек авторларның төрле әсәрләрендә уңышлы файдаланыла.

**Иске татар теленең угызтөрек варианты.** XVI гасырдан Россия хакимиятенә төрки телле халыклар белән аралашу өчен тылмачлар, писерләр, илчеләр кирәк була башлый. Көнчыгыш илләре, шул исәптән Урта Азия илләре, Кырым белән дипломатик мөнәсәбәтләр урнаштыруда

иске татар теле XVI гасырдан XIX гасыр башларына кадәр икенче функциональ дәүләт теле булып файдаланыла. XVIII гасыр ахырларына таба сәнәгать, икътисад өлкәсендәге хәрәкәт халыкларның иҗтимагый аңы, мәдәнияте, мәгарифе үсешенә тәэсир итә, мәдрәсәләр ачыла, алар өчен дәреслек булырдай әсәрләр языла, халыкның хәтерен, динениманын, кешелеген саклау фикере сәнгатьчә тасвирланып бирелә. Һәм болар барысы да, авторлар үзләре белдергәнчә, Болгар-Казан төркисендә тормышка ашырыла. Бу чорда язылган «Сәяхәтнамәләр»дә дә халыкчан сөйләмә тел өстенлек итә.

Төркиләрнең мәдәни тормышында көчле мәдәни яңарыш буларак 1883 елда Кырымда «Тәрҗеман» газетасы басыла башлый. Аның финанс ягын тәэмин итүгә Идел буе татарлары да шактый өлеш кертә. Газетаны редакцияләү һәм чыгару эшендә Зөһрә Акчурина, Муса Акъегетзадә кебек татар укымышлылары актив катнаша. Нашир Исмәгыйль Гаспралы бу җәридәне, барча төрки халыклар укый һәм файдалана алсыннар, дигән изге ният белән, барысына да аңлаешлы булган «урта лисан» – бер шивәдә чыгарырга тырыша. Төрки кавемнең күпчелеген угыз телләре тәшкил иткәнгә күрә, «урта лисан» дигәндә традицион абруйлы төркинең угызчылык белән баетылган варианты – язма аралашу теле барлыкка килә. Г. Ибраһимов раславынча, «Тәрҗеман» бик тиз арада Идел буе мәдрәсәләрендә һәр саны зарыгып көтеп алынган үз газетага әйләнеп китә. Татар телендә газета бастырырга рөхсәт алыну белән, «Нур» газетасында «Әдәби телемез нә делдер?» дип башланган бәхәстә бу күренеш, иске татар теле дигән төшенчәгә каршы куелып, төрек-госманлы теле дип атала («Нур», 1905, № 4 һ.б.). М. Акъегетзадәнең (1864–1923) татар әдәбиятында реалистик прозаның беренче үрнәге дип санала торган «Хисамеддин менла» әсәре (1886) менә шушы телгә якын булган төрки-татар телендә иҗат ителә. Автор үзенең милли романында «Тәрҗеман»ны «Русия исламларының сәламәтене вә хөсне мәгыйшәтене мөхафәзә идән (*саклый торган*) җәридә» дип атый [Акъегет, б. 4]. М. Акъегетзадә «урта лисан»ны файдалана: бер үк төшенчә *авыл, карья, көй* дип өч төрле тел сүзләре белән бирелә. Шул ук вакытта, ул үз туган төбәгендәге мишәр диалектына хас булган *кырмалау, бакты, ашагы* һ.б. сүзләрне дә куллана. Язма телдәге әлеге яңалыкка төрлечә мөнәсәбәт белдерелә. Г. Баттал Таймас (1883–1969) «melez dıl» (катнаш тел) барлыкка килде дип саный. Бу билгеләмәне Адилә Айда (1912–1992) «Садри Максуди Арсал» дигән хезмәтендә, М. Акъегет әсәре Казан телендә язылмаган, аның әдәбият тарихында кыйммәте юк, С. Максудиның «Мәгыйшәт» хикәясе генә саф Казан телендәге беренче әсәр, дигән фикерен раслау өчен китерә [Айда, б. 23–25].

XIX йөз ахырына таба татар халкының танылган мәгърифәтчеләре, төркиләрнең күпчелеге укысын дигән максатны күздә

тотып, кайбер әсәрләрен, «урта лисан» белән иҗат итәргә кирәк дип саныйлар. З. Бигиевнең (1870–1902) тулаем төрки дөнья укып аңласын дигән максат белән язылган «Мавәраэннәһердә сәяхәт» юлъязмасы (1902), татар укучысына тәкъдим ителә торган «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» (1887) һәм «Гөнаһе кәбаир» (1890) әсәрләренең теленнән шактый аерылып, угыз-төрки сүз һәм сүзформалары белән баетылып бирелә.

Күренекле әдип һәм мәгърифәтче-педагог, танылган тәрҗемәче һәм журналист, җәмәгать эшлеклесе һәм мөхәррир Ф. Кәриминең (1870–1937) татар укучысы укысын дип язылган «Салих бабайның өйләнүе» (1897, 1901), «Җиһангир мәхдүмнең авыл мәктәбендә укуы» (1899) һ.б. хикәяләре язма телнең җанлы-сөйләмә халыкчан варианты белән иҗат ителә. «Вакыт» газетасында басылган күпчелек мәкаләләренең теле дә асылда әлеге юнәлештә бара: «Рус милләтчелеге» («Вакыт», 1910, 4 февраль), «Кем иде Шакир әфәнде?» («Вакыт», 1912, 25 март) һ.б. Ф. Кәриминең төрле фәннәргә караган тарихи, дини әсәрләрендә истыйлах-терминнар күп кулланылганга, «Мәрхүм Гыйльман ахунд» рисаләсендә рәттән диярлек гарәп-фарсы алынмалары файдаланылганга иске татар теленең классик-абруйлы варианты белән файдалану барлыкка килә. Авторның барлык төркиләр дә укысын дип язылган «Аурупа сәяхәтнамәсе» (1902) һәм «Кырымга сәяхәт»е (1904), аңлашылганча, «Тәрҗеман» газетасында чагылыш тапкан «урта лисан» белән языла.

Мөселман дөньясында мәшһүр дин белгече, философ, мәгърифәтче-педагог, тарихчы-галим, җәмәгать эшлеклесе, әдип вә публицист Р. Фәхретдиннең (1858–1936) иҗатында да, әдәби телнең өч тармагын куллану дәвам ителә. Татар халкының «ак өстендә кара таныган» күпчелек укучылары өчен «ачык ана телемездә» дигән искәрмә белән «Тәрбияле ана» (1898), «Тәрбияле бала» (1898), «Тәрбияле хатын» (1899) һ.б. гыйльме әхлак һәм көндәлек тормышны алып баруда кирәкле тәртип-низам турындагы дөньяви-дидактик әсәрләре халыкның җанлы сөйләменә хас булган сүз һәм сүзформалары файдаланылып, классик иске татар теленең халыкчан варианты белән языла. «Сәлимә яки гыйффәт» (1898), «Әсма яки гамәл вә җәза» (1903) кебек сәнгатьле чәчмә әсәрләре дә, шушы ук юнәлешкә нигезләнә. Р. Фәхретдин, танылган галим, теолог Ш. Мәрҗани (1818–1889) тарафыннан гарәп телендә язылган биобиблиографик хезмәтне дәвам итеп, төрки-татар телендә ике җилд, 14 җөзьәдә «Асәр»ен төзи (1900–1908). Әлеге хезмәтен автор Диния нәзарәтенә казый итеп сайлангач яза башлый, шуның белән бергә ул архивтагы күпсанлы кульъязмаларны да тәртипкә китерә. Бу язмаларның күбесе имам вә мөдәррисләрнең эшләренә һәм тормышларына караган чыганаклар, ягъни эшчәнлекләре турыдан-туры гарәп, фарсы, төрек телләре белән бәйле шәхесләр хакында була. Әле-

ге хезмәтнең жанры, үзенчәлекле материалы традицион классик иске татар теленең гарәп-фарсы алынмалары мул кулланыла торган вариантында гына языла алган. Әдипнең дини-рухи эчтәлекле «Коръан вәтәбәгать» (1900), «Мөхәммәд галәйһиәссәлам» (1908), «Җәвамигуль-Кәлим шәрхе» (1911) хезмәтләренең теле дә шушы юнәлештә бара. Р. Фәхретдиннең барлык төрки телле халык укып аңласын дип язылган фәнни хезмәтләре һәм «Шура» журналында (1909–1918) эзлекле рәвештә басылып килә торган мәкаләләренең күбесе «Тәрҗеман» теленә якын булган «урта лисан»да языла. В. Бартольд «Шура» журналының телен «госманлыча катышкан Казан татарлары әдәби теле» дип белдерә [Мәрдәнов, б. 31–32]. Димәк, иске татар әдәби телендә урын алган бу вариантның хосусый яшәвенә махсус рәвештә игътибар ителә. Поэзия әсәрләрендә угызлашкан вариантның гүзәл үрнәге татар халкының тулаем төрки дөньяда дан алган, даһи шәхесе Г. Тукай иҗатында дәвам ителә.

Иҗтимагый тормышта бара торган вакыйгалар әдәби телнең үсеш-үзгәрешенә тәэсир иткән кебек, әсәрләрнең теле өйрәнелеп языла торган хезмәтләргә дә үзенчә йогынты ясый. 1930 еллардан соң билгеле бер эзлеклелектә иске татар теленең һәр өч варианты да юкка чыгарыла бара. Әлеге йогынтының ничек баруын күзәтү барышында, кызганыч ки, әдәби телнең угызлашкан вариантының вазифасын аңламау һәм аны ярсып инкарь итү хронологик яктан беренче булып тора. Бу мәсьәлә Г. Тукайның башлангыч чор иҗатына тәнкыйть мәкаләләре язган күренекле әдип Ф. Әмирхан (1887–1926) тарафыннан мәйданга куела. Алга таба әлеге мәсьәлә панисламизм, пантюркизм дигән төшенчәләр белән бергә кулланылып, сәясәткә бәйләп күтәрелә, аннан соң, әдәби язма тел сөйләмә телгә тәңгәл булырга тиеш, дигән тәгълимат нигезендә, филологик планда кире кагыла, шул сәбәпле «урта лисан»да язылган әсәрләрнең теленә фәнни объектив бәя бирелмичә кала.

Гасырлар буена, билгеле бер үзгәрешләр белән, беренчедән, гарәп-фарсы алынмалары мул кулланылып һәм, икенчедән, гомумтөрки уртак сөйләмә сүзләр әдәбиләштерелеп язылган, аристократ-абруйлы һәм сөйләмә-халыкчан вариантлары белән ике параллель нигездә барган иске татар теле XIX гасырның икенче яртысыннан, аерым әдипләр күпчелек төркиләр аңласын дигән максатны күздә тотып яза башлау сәбәпле, өч вариантлы булып файдаланыла башлый. Угызлашкан өченче вариантка караган әсәрләр барлык төркиләр укысын дигән максат белән басыла башлаган «Тәрҗеман» газетасының «урта лисан»ына якын телдә язылалар, нәтиҗәдә язма әдәби телдә аралашу тагын да киңәя. Алга таба ул татар зыялылары тарафыннан теоретик планда көчле тәнкыйть утына тотылса да, гамәли яктан билгеле бер үзгәрешләр белән дәвам ителә.

**Әдәбият**

*Айда А.* Садри Максуди Арсал. Анкара: Культур Баканлыгы, 1991. 290 б.

*Акъегет М.* Хисаметдин менла. Милли роман яки хикәя. Казан: Казан университеты табгыханәсе, 1886. 70 б.

*Благова Г.Ф.* О методике изучения морфологии средневековых тюркских поэтических текстов // Вопросы языкознания, 1977. № 3. С. 86–100.

*Гайнетдинов М.В.* Литература XVIII века // Средневековая татарская литература (VIII–XVIII вв.). Казань: Фэн, 1999. 240 с.

*Кашгари М.* Диван Лугат ат-Турк / перевод, предисловие и комментарии З.-А.М. Ауэзовой. Индексы составлены Р. Эрмерсом. Алматы: Дайк-Пресс, 2005. 1288 с.

*Кононов А.Н.* Поэма Юсуфа Баласагунского «Благодатное знание» // Юсуф Баласагунский. Благодатное знание. М.: Наука, 1983. С. 495–517.

*Кукляшев С.* Татарская хрестоматия. Казань: Тип. ун-та, 1859. 107 с.

*Курбатов Х.Р.* Татар әдәби теленең алфавит һәм орфография тарихы. Татар. кит. нәшр., 1999. 139 б.

*Мәрдәнов Р.* «Шура» журналы (1908–1917): әдәбият мәсьәләләре. Казан: Рухият, 2001. 152 б.

Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. 1 т.: Борынгы чор һәм Урта гасырлар. 415 б.; 2 т.: XV–XVIII гасырлар. 471 б.

Татар әдәби теле тарихы (XIII гасыр – XX йөз башы). Казан: ТӘҺСИ, 2015. 1 т.: Фонетика. Графика: язма традицияләр, норма һәм вариантлылык. 696 б.

*Фасеев Ф.С.* Старотатарская деловая письменность XVIII века. Казань, 1982. 171 с.

*Хисамов Н.Ш.* Кол Гали һәм төрки «Йосыфнамә» (XIII–XV йөзләр). Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. 208 б.

Языки мира: Тюркские языки. Бишкек: Кыргызстан, 1997. 543 с.

**Бәширова Илида Басыйр кызы,**
*филология фәннәре докторы, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми тел белеме бүлеге баш фәнни хезмәткәре*

УДК 811.512.145

***Б.К. Миңнуллин***

# XX ГАСЫР БАШЫ ТАТАР ГАЗЕТАСЫ ҺӘМ ТАТАР МИЛЛИ ӘДӘБИ ТЕЛЕНЕҢ ФОРМАЛАШУЫ

В статье рассматриваются роль и место татарской периодической печати в истории формирования татарского национального литературного языка. В начале XX века на страницах татарской периодической печати велись споры о путях дальнейшего развития старотатарского языка. В данный период он функционировал в нескольких письменных вариантах, которые нашли отражение в том числе и в языке татарских газетных текстов.

**Ключевые слова:** литературный язык, татарский национальный литературный язык, языковая вариативность, татарская периодическая печать.

Билгеле булганча, XIV гасырдан башлап татар теле халык сөйләм теле кысаларында үсеш ала. Казан ханлыгының Рус дәүләтенә кушылуы нәтиҗәсендә, бүгенге урта диалект вәкилләренең ата-бабалары – Казан халкының бер өлеше Идел буенда көн күргән кыпчак кабиләләре белән кушылып, катнаш яшәү урыннары барлыкка китерәләр. Әлеге процесс нәтиҗәсендә, башка халыклардан аермалы буларак, Идел буе татарларында, капиталистик мөнәсәбәтләр урнашканчы ук, төп диалектларның характерлы үзенчәлекләрен үз эченә алган авыл гомумхалык сөйләмә теле, ягъни авыл койнесы барлыкка килә. Алга таба, капиталистик мөнәсәбәтләр ныгыган саен, илнең төп сәнәгать үзәкләре саналган Казан, Уфа, Екатеринбург, Пермь, Оренбург, Җаек, Троицк, Чиләбе шәһәрләрендә, татар теленең төрле диалектларында сөйләшүче авыл халкы күпләп күчеп килү белән бәйле рәвештә, татар шәһәр койнесы да формалаша. XX гасыр башларында исә, авыл һәм шәһәр койнелары нигезендә Идел буе татар милли әдәби теле барлыкка килә һәм халык сөйләмә теленә турыдан-туры йогынты ясый башлый [Закиев, 1995, с. 264]. Шул ук вакытта, татар милли әдәби теленең формалашуына XX гасыр башында барлыкка килгән татар вакытлы матбугаты да йогынты ясамый калмый. Милли телнең башлангыч формаларын XX гасыр башында дөнья күргән татар газета-журналларының телендә табарга мөмкин.

XX гасыр башына кадәр чын мәгънәсендә «татар газетасы» булган дип әйтү дөрес булмас. Әлбәттә, 1883–1918 елларда Бакчасарайда нәшер ителгән «Тәрҗемән», 1903–1905 елларда Тифлистә чыккан «Шәркый рус» газеталары күпмедер күләмдә татар халкының рухи ихтыяҗларын канәгатьләндергән. Ләкин әлеге газеталарның бөтен төрки-мөселман дөньясының, шул исәптән татар дөньясының формалашуына һәм үсешенә керткән өлешен исәпкә алган очракта да, XX гасыр башында Россиядә яшәүче татар халкы үз вакытлы

матбугатын булдыру өчен инде өлгереп җиткән була. 1905–1917 еллар арасында Россиянең Казан, Оренбург, Уфа, Петербург һ.б. шәһәрләрендә барлыгы 120 дән артык татар телле газета-журнал дөнья күрә. Шундыйлардан, мәсәлән, «Нур» (Санкт-Петербург, 1905–1914), «Вакыт» (Оренбург, 1906–1918), «Йолдыз» (Казан, 1906–1918), «Кояш» (Казан, 1912–1918), «Борһане тәрәккый» (Әстерхан, 1906–1911) газеталарын һ.б.ны атап китәргә мөмкин.

Гомумән алганда, бу чорда татарлар арасында укымышлы халыкның саны югары булу сәбәпле, нәшриятчылык эше зур үсеш ала. Татар вакытлы матбугатының беренче үрнәкләре гарәп графикасында басыла һәм идеологик күзлектән чыгып караганда, ике яклап реакцион-клерикаль һәм революцион-радикаль агымнар белән чикләнгән киң бер аланны тәшкил итә. Хронологик планда XX гасыр башы татар вакытлы матбугаты, югарыда әйтелгәнчә, 1905–1907 һәм 1917 елгы революцияләр арасындагы чорны алып тора. Шунысы мөһим, әлеге вакыт аралыгында басылган газета һәм журналлар укучыга тәкъдим ителгән тема һәм фикер төрлелеге ягыннан совет чоры татар вакытлы матбугатыннан күпкә баерак була. Әйтергә кирәк, татар газеталарының зур өлеше кыска гына вакыт эчендә басылып, юкка чыгалар, яисә башка исем астында чыгуларын дәвам итәләр. 1905–1908 елларда татар вакытлы матбугаты күтәрелеш чорын кичерсә, берничә ел үтүгә, хөкүмәт эзәрлекләве һәм цензура белән бәйле рәвештә, татар телендә чыгып килүче газета һәм журналларның саны кискен рәвештә кими башлый. Әлеге үзгәрешне беренче чиратта татар вакытлы матбугатының либераль һәм социал-демократик юнәлештәге вәкилләре тоя. Мәсәлән, 1905 елдан соң чыга башлаган һәм 1911 ел ахырында нәшер ителүен дәвам иткән либераль газета һәм журналлардан бары тик «Йолдыз» (Казан, 1906–1918), «Вакыт» (Оренбург, 1906–1918), «Шура» (Оренбург, 1908–1917) һәм «Идел» (Әстерхан, 1907–1914) басмаларын атап китәргә була.

XX гасыр башы татар вакытлы матбугаты, идеологик планда капма-каршы ике агым вәкилләре – җәдитчеләр һәм кадимчеләр кулында җитди коралга әйләнә. XIX гасырның икенче яртысында, Россиядә буржуаз мөнәсәбәтләр урнашуга бәйле рәвештә, татар җәмгыятенең социаль-икътисади һәм рухи-идеологик тормышында барлыкка килгән үзгәрешләргә карата реакция буларак үсеп чыккан кадимчелек юнәлешенең татар вакытлы матбугатындагы төп өлгесе итеп «Дин вә мәгыйшәт» (Оренбург, 1906–1918) журналын атарга мөмкин. Кадимчеләр яклы булган әлеге иң консерватив һәм кискен-клерикаль дини, фәнни, әдәби һәм сәяси басманың нашире мулла Мөхәммәдвәли Хөсәенов була. Татар җәмгыятендә урнашкан идеологик кырның икенче ягында исә җәдитчелек агымын пропагандалаган милли-демократик юнәлештәге атналык

«Әлислах» (Казан, 1907–1909) газетасы урын ала. Рәсми нашире һәм мөхәррире Вафа Бәхтияров булган, ә чынлыкта бу вазифаны Габдулла Тукай белән Фатих Әмирхан үтәгән әлеге басма ике елдан азрак вакыт дәвамында гына чыгып калса да (барлыгы – 68 сан), татар җәмгыятендә милли үзаң, демократия, дөньяга яңа караш формалаштыруда эз калдыра.

Географик яктан чыгып карагында, XX гасыр башы татар вакытлы матбугаты киң территориядә дөнья күрә. Россиядә басылган беренче татар газетасы булып «Нур» газетасы (Санкт-Петербург, 1905–1914) санала. Ләкин, шуңа да карамастан, XX гасыр башы татар җәмгыятенең, шул исәптән татар вакытлы матбугатының үзәге Казан саналган. Казанда чыга башлаган беренче газета – «Казан мөхбире» (1905–1911). Аның рәсми нашире һәм мөхәррире Сәедгәрәй Алкин – адвокат, Казан губернасыннан Дәүләт думасының беренче чакырылыш депутаты, «Иттифакъ әл-мөслимин» партиясенә нигез салучыларның берсе. «Казан мөхбире»нән соң берничә ай узуга Казанда «Йолдыз» (1906–1918), соңрак – «Азат» (1906, барлыгы – 56 сан) газеталары дөнья күрә. 1905 елда Җаекта «Фикер» (1905–1907), соңрак «Яңа тормыш» (1907–1908) газеталары басыла башлый. Петербургта «Өлфәт» (1905–1907), ә 1913 елда «Ил» (1913–1915) газеталары чыга башлый. 1914 елда «Ил» газетасы Мәскәүдә басыла башлый, «Сүз» (1915–1916), соңрак «Безнең ил» (1916–1917), ә 1917 елның 23 мартыннан янәдән «Ил» (1917–1918) исемнәре астында нәшер ителә. 1906 елда Оренбургта «Вакыт» (1906–1918), ә 1907 елда социал-демократик «Урал» (1907, барлыгы – 31 сан) газетасы, 1908 елда «Шура» (1908–1917) журналы чыга башлый. Әстерханда 1906 елда «Борһане тәрәккый» (1906–1911), 1907 елда «Ислах» (1907, барлыгы – 3 номер), «Хәмият» (1907–1908), «Идел» (1907–1914), «Мизан» (1908–1909) газеталары дөнья күрә. Уфада 1906 елда «Әлгаләмел ислами» (1906–1907), Самарада 1908 елда «Икътисад» (1908–1913) журналы басыла башлый.

XX гасыр башы татар вакытлы матбугатының һәрбер вәкиле, нашир һәм мөхәррирләрнең теләк-хуплауларына бәйле рәвештә, үзе үк әдәби телнең теге яки бу вариантын кулланылышка кертүче бер механизм ролен башкара. Шушы фикернең дәлиле итеп, XX гасыр башында татар вакытлы матбугаты битләрендә «Татар теле нинди булырга тиеш?» дигән сорауга багышланган бәхәсне китерергә мөмкин. Әлеге бәхәс, гомумән алганда, татар милли әдәби теле формалаштыруга зур өлеш кертә.

«Нур», «Фикер», «Йолдыз», «Шура» газета-журналларында барган тел бәхәсләренә карагында, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар әдәби теле берничә вариантта үсеш ала:

1. Әдәби тел – классик язма иске татар әдәби теленең традицияләрен дәвам итүче, гарәп-фарсы лексик һәм грамматик формалары белән баетылган вариант;

2. Җәдиди-госманлы – «Тәрҗеман» газетасының теленә якын булган вариант;

3. Татар сөйләмә теленең лексик һәм грамматик формалары белән баетылган вариант [Бәширова, 1999, б. 12].

Аңлашылганча, хөкүмәттән татар телендә вакытлы матбугат чыгаруга рөхсәт алу XX гасыр башы татар җәмгыяте өчен катлаулы мәсьәләләрнең берсе була. Газета һәм журналлар халык арасында киң таралыш тапсын өчен, аларның теле барлык социаль катламнарга да аңлаешлы булу зарурияте туа. Ләкин шул чорда яшәгән бер төркем шәхесләрнең фикеренә караганда, чыгып килүче газеталарның телен кистереп «татарча» дип әйтү дөреслеккә бик үк туры килеп бетми. XX гасыр татар вакытлы матбугаты теле яисә төрек теленә бик охшаш була, яисә татар әдәби теленең эшкәртелмәгән вариантын чагылдыра [Вәлиди, 2007, б. 159].

Милли интеллигенциянең бер өлеше газета теле итеп татар сөйләмә телен кулланырга өндәсә, икенче өлеше исә төрек теле нигезендә формалаштырылган вариантны тәкъдим итә. Вазгыятьне Төркиядә укып кайткан һәм мәдрәсәләрдә чор таләпләренә туры килгән «яңача» белем бирүче ярым-татарча, ярым-төрекчә сөйләшә торган яшь буын вәкилләре тагын да кискенләштерә. Шул рәвешле, «Тәрҗеман» үз битләрендә, барлык төрки халыкларны берләштерү максатын күз уңында тотып, госманлы төрекчәсенең гадиләштерелгән вариантын, «Нур» газетасы – катнаш татар-төрек вариантын, ә «Казан мөхбире» Казан татарлары телен куллана.

Мисал өчен XX гасыр башында нәшер ителгән «Вакыт» һәм «Йолдыз» газеталарын алыйк. «Вакыт» газетасы, үзенең якын кардәше «Шура» кебек үк, госманлы төрекчәсенә хас булган тел формаларын һәм татар теленең традицион байлыгын нигез итеп ала һәм татар халкының барлык социаль катламнарына да аңлаешлы булган сөйләм телен куллануга каршы була. Ә «Йолдыз» газетасы, киресенчә, төрек йогынтысыннан баш тарту юлына баса. Ягъни әлеге ике басманы чагыштырганда без өйрәнелгән чор өчен хас булган ике агым – төркичелек һәм татарчылык агымнарының вакытлы матбугат теленә карата каршылыклы юнәлешләре белән очрашабыз. Гомумән, «Йолдыз» газетасының телен шул ук чорда басылып килгән башка газеталар теле белән чагыштырганда, кискен аерма күзгә ташлана. Шунысы кызык, «Йолдыз» газетасының телендә, «Вакыт»тагы кебек үк, татар теленең традицион формалары чагылыш таба. Ләкин алар, «Вакыт» газетасының теленнән аермалы буларак, госманлы төрекчәсе белән янәшә түгел, ә бәлки әдәби телнең һәркемгә аңлаешлы булган варианты белән үрелеп бара [Вәлиди, 2007, б. 160].

Нәшер ителә башлаган дәверләрендә «Йолдыз» газетасы да, «Вакыт» та көндәлек басма булмый, алар атнасына өч тапкыр чыга. Шул сәбәпле һәрбер санның күпчелек текстлары басманың мөхәррирләре тарафыннан языла, ә читтән килгән текстлар

исә редакция хезмәткәрләре тарафыннан эшкәртелә. Газеталарның тел ягыннан булган аермалыклары, беренче чиратта, нәкъ менә әлеге факт белән бәйле булса кирәк. «Йолдыз»ның баштагы саннарында Һади Максудиның, «Вакыт»та Фатих Кәриминең каләме сизелә. Алга таба, газеталар көндәлеккә әйләнгәч, мәкаләләрне басмага әзерләү өчен бирелгән вакытның азаюы белән бәйле рәвештә, текст төрлелеге сизелә башлый, акрынлап газеталарның телендәге аерымлыклар кими һәм, ахыр чиктә, вакыт шаукымына буйсынып, алар да татарчылык агымы тәэсиренә эләгәләр. Ләкин шунысы үзенчәлекле, XX гасыр башында телдәге татарчылык һәм төркичелек агымнары өчен хас булган гарәп һәм фарсы тел формалары, нигездә бер-берсенә капма-каршы булган агымнарның уртак характерлы үзенчәлегенә әйләнә. Шул рәвешле, госманлы төрекчәсенә охшарга тырышкан «Вакыт» халык өчен, татарга якынрак булган, ләкин гарәп һәм фарсы тел формаларыннан кирәгеннән артык файдаланган «Йолдыз»га караганда, күпкә аңлаешлырак була. Ничек кенә булмасын, 1910 елдан соң милли интеллигенциянең бер өлеше «Вакыт»ның төркичелеге, «Йолдызның» «татарчылыгы»на каршы татар халкының барлык социаль катламнарына да аңлаешлы булган татар сөйләмә телен куя. Вакытлы матбугатның татар сөйләмә теленә нигезләнгән вариантын без, мәсәлән, «Кояш» газетасы текстларында күрә алабыз.

Әйтеп үтелгәнчә, татар вакытлы матбугатының барлыкка килүе һәм үсеше белән татар милли әдәби теленең формалашуы арасында билгеле бер бәйләнеш бар. Җәмгыятьнең сәяси, мәдәни һәм рухи тормышында зур үзгәрешләр вәгъдә иткән XX гасыр башында, милли әдәбият белән беррәттән, татар вакытлы матбугаты да теге яки бу телнең камиллеген күрсәтүче төп фактор – милли әдәби телне булдыруда ярдәм итәрлек корал ролен үти. Милли әдәби телнең нигезе булырдай тел вариантлары нәкъ менә 1905–1907 һәм 1917 елгы революцияләр арасындагы чорда дөнья күргән татар вакытлы матбугаты битләрендә чагылыш таба, сайлап алу процессын кичерә.

**Әдәбият**

*Бәширова И.Б.* Татар әдәби теле тарихы: XIX гасыр ахыры – XX йөз башы. Казан: Казан дәүләт технология университеты нәшрияты, 1999. 528 б.

*Вәлиди Җ.* Сайланма хезмәтләр. Казан: Мәгариф, 2007. 271 б.

*Закиев М.З.* Татары: проблемы истории и языка. Сб. статей. Казань, 1995. 464 с.

*Мәкалә «2014–2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Дәүләт программасының 3.5.4. номерлы чарасын тормышка ашыру кысаларында нәшер ителде*

***Миңнуллин Бәхтияр Ким улы,***
*филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге мөдире*

УДК 811.512.145′373

***Р.Ф. Мирхәев***

# ТАТАР ЛИНГВОКУЛЬТУРАСЫНДА «АЛЛА» КОНЦЕПТЫ

Религиозное мировоззрение татарского народа представляет собой особую систему духовных ценностей и традиций, представлений о мире, которая складывалась в течение многих веков под воздействием ислама. В то же время в ней прослеживается и слияние тэнгрианства, которое до принятия ислама исповедовали предки современных татар. Все это определило сложность и многогранность татарской религиозной концептосферы. В качестве ее основополагающего ядра выступает концепт «Алла» – «Бог», в тесной взаимосвязи с которым раскрывается содержание других элементов. Статья посвящена изучению особенностей его вербализации в татарской лингвокультуре. Исследование проведено на основе материала, извлеченного из старотатарских письменных текстов.

**Ключевые слова:** языковая картина мира, религиозное мировоззрение, религиозная концептосфера, религиозный концепт.

Татар халкының дөньяны дини күзаллау системасын күп гасырлар дәвамында формалашкан рухи кыйммәтләр, гореф-гадәтләр һәм карашлар тәшкил итә. Тарихи планда ул мөселман традициясенең йогынтысы астында оеша. Шул ук вакытта анда ислам дине кабул ителгәнгә кадәр хәзерге татарларның борынгы бабалары тоткан тәңречелекнең эзләре дә сакланган. Боларның барысы да безнең көннәргә кадәр килеп җиткән күпсанлы язма чыганакларда чагылыш таба. Бүгенге көндә аларның тел үзенчәлекләрен (график, фонетик, морфологик, лексик) өйрәнеп, күпсанлы фәнни хезмәтләр язылды. Шул ук вакытта күпчелек язма текстларның аерылгысыз өлешен тәшкил иткән, үзендә татар халкының дөньяны күзаллавы һәм аның телдә чагылышы белән бәйле мәгълүматны туплаган дини лексика игътибардан читтә кала бирә.

Фәнни хезмәтләрдән күренгәнчә, әлеге төр лексика галимнәр тарафыннан, әдәби әсәрләр теленең башка үзенчәлекләре белән бергә, лингвостилистик планда, яисә татар әдәби теле нормаларының формалашу һәм үсү тарихы контекстында карала [Ахметгалеева, с. 105–106; Зайнуллин, с. 80–91; Кадирова, с. 120–121; Нуриева, с. 82–83, 137–138; Хаков, б. 71, 117; Хисамова, б. 105, 125, 172, 196, 206, 300]. Бу өлкәдәге тикшеренүләр арасында махсус дини лексикага багышланганнары да бар. Мәсәлән, И.Б. Бәширова XVIII гасыр татар поэзиясе әсәрләре телен өйрәнеп, Аллаһы Тәгалә атамаларының семантикасын ачыклый һәм аларның әдәбистилистик кулланылыш үзенчәлекләрен билгели [Бәширова, б. 124–133].

Татар халкының дөньяны дини күзаллау системасы структур яктан күпкырлы һәм катлаулы күренеш тәшкил итә. Ул үз эченә, «Пәйгамбәр», «Фәрештә», «Оҗмах», «Тәмуг», «Гөнаһ»

концептлары белән бергә, «Кеше», «Язмыш» кебек турыдан-туры бу өлкәгә карамаган һәм билгеле бер контекстта гына өстәмә мәгънә төсмерләренә ия булган берәмлекләрне дә ала. Әлеге системаның үзәгендә аларның барысын үзара бәйләп торучы «Алла» концепты тора.

Ислам динендә Алла үзенә тиңе булмаган, югары акыл, чиксез куәт, тулы камиллек һ.б. сыйфатларга ия изге зат, абсолют башлангыч буларак күзаллана. Татар лингвокультурасында аның вербаль чаралары буларак *Аллаһы Тәгалә / Аллаһы / Алла, Ходай / Хода, Тәңре* лексемалары кулланыла. Килеп чыгышы ягыннан төрле тел берәмлекләре (гарәп, фарсы, төрки-татар) булуларына карамастан, алар барысы да ‘алла, илаһи өстен көч’ мәгънәсен белдерәләр [Татар теленең аңлатмалы..., I т., 2015, б. 137; Татар теленең аңлатмалы ..., I т., 1977, б. 47; Татар теленең аңлатмалы..., III т., 1981, б. 240, 370; Татар теленең этимологик..., I т., б. 93; Татар теленең этимологик ..., II т., б. 245–246, 390].

Хәзерге татар телендә бу лексемалар өчен уртак сүз кулланылышы да хас. Мәсәлән: Алла (Тәңре, Ходай) хөкеме; Алла (Тәңре, Ходай) йорты; Аллага (Тәңрегә, Ходайга) ышанмаучы; Аллага (Тәңрегә, Ходайга) ышанучы; Алладан (Тәңредән, Ходайдан) куркучы; Алла (Тәңре, Ходай) колы; Алла (Тәңре, Ходай) бәлә; Алла (Тәңре, Ходай) боерса; Алла (Тәңре, Ходай) каргаган; Алла (Тәңре, Ходай) каршына (хозурына, янына) бару; Алла (Тәңре, Ходай) кодрәте белән; Алла (Тәңре, Ходай) ризалыгы өчен; Алла (Тәңре, Ходай) сакласын һ.б.

Әлеге сүзләрнең мәгънә уртаклыгы, сөйләм барышында бер-берсен алыштырып килә алулары иске татар язма чыганакларында да күзәтелә. Биредә алар, Аллаһы Тәгаләне атау белән бергә, билгеле бер контекстта аңа хас булган сыйфатларны да белдереп киләләр. Мәсәлән:

кичерүче: Аллаһыдан ғисмәтнәҗат умар имди [Кол Гали, б. 166];

саклаучы: Мәғаз Аллаһ, ул иш рәуа ирмәз имди [Кол Гали, б. 166];

әмер бирүче: Аллаһ әмрин сындурмағә қурқарвән [Кол Гали, б. 236] һ.б.

бар нәрсәне белүче: Хода йа, бу хаҗәтем сәңа мәғлүм [Кол Гали, б. 104];

коткаручы: Ходавәндә, фазлең берлә қуртар имди! [Кол Гали, б. 104];

язмышларны билгеләүче: Ходавәндә, ходавәндә, сәнең хөкемең кәлтүрде бәни бунда [Кол Гали, б. 158];

хөкем итүче: Қыйамәт булса, Хода булыр үзе қази [Мөхәммәдъяр, б. 55] һ.б.

Моннан тыш Аллаһы Тәгаләнең табигате, аңа хас булган сыйфатлар язма текстларда контекст ярдәмендә дә ачыла: Қөдрәтең вар, «Ул!» дидекең улур имди [Кол Гали, б. 48]; Андан соңра шиддәтләрдән бән қортарам, атасына хәқиқәтдә бән күстәрәм, дәүләтин вә мөлкәтин бән артдырам, таҗ вә тәхет, солтанат вирәм имди [Кол Гали, б. 78]; Сонғы берлә байық бәни ул йаратды,

буның кеби күрекле җәмаль ул дүзәтде, бу қазаны үстүмә ул йөретде, аның хөкемен һич кемсәнә йықмаз имди [Кол Гали, б. 126].

Алда әйтеп үтелгәнчә, татар телендә Алланың атамасы буларак төрки-татар асыллы *Тәңре* сүзе дә кулланыла. Борынгы төрки телдә ул баш Күк Алласын белдергән [Древнетюркский словарь, с. 544; Сравнительно-историческая..., с. 562–564]. Ислам дине кабул ителгәннән соң, әлеге сүзнең семантикасы мөселман традициясенә хас булган өстәмә мәгънәләр белән баеый. Шуның нәтиҗәсендә ул алга таба да кулланылыштан төшеп калмый. Билгеле бер контекстта аның ярдәмендә Аллаһы Тәгаләнең түбәндәге сыйфатлары ачылырга мөмкин:

куркуга салучы: Йағқуб сәүчи хақға ғаси һич улмады, сезләр дағы Тәңредән курқың имди! [Кол Гали, б. 70];

чиксез кодрәт иясе: Бу хәлдә Тәңредән фәрман улды, қөдрәт берлә күкдә қара булут туғды [Кол Гали, б. 106]; Әйа Зөләйхә, күрдүңмү, қадир Тәңремнең қодрәтенә ирдүңмү [Кол Гали, б. 172];

язмышлар белән идарә итүче: Бу тәқдири Тәңредән белмеш кәрәк [Кол Гали, б. 100]; Бу тәқдир Тәңремдәндер, белең мәғлүм [Кол Гали, б. 102];

җәза бирүче: Бәңа бу қазаны Тәңре вирди [Кол Гали, б. 86]; Сәңа бу қазаны Тәңре вирди [Кол Гали, б. 94];

мәрхәмәтле, рәхимле, шәфкатьле: Фазле берлә қылсун бәңа Тәңрем рәхмәт [Кол Гали, б. 102]; Һәмандәм Тәңредән мәдәд ирди ‘В тот же миг его достигла милость Бога’ [Кол Гали, б. 116]; Сәҗдә қылыб, Тәңресенә йалварыр имди [Кол Гали, б. 182]; Бән Тәңредән хуб умармын [Кол Гали, б. 256];

кабул кылучы: Доғасыны Тәңреси қабул қылды [Кол Гали, б. 106]; Улуқ сағәт Йусеф сәүчи доға қылди, Тәңредән иҗабәт хасил улды [Кол Гали, б.150];

бер һәм бердәм: Қамулары ушбу сүзә инандылар, җөмләси бер Тәңрейә бүгүлдиләр [Кол Гали, б. 110]; Қодес бике аны күреб, әхуаль белди, Тәңренең берлекинә мөқир қылды [Кол Гали, б. 112];

бүләк итүче: Ул ниғмәтләр бу Тәңремдән [Кол Гали, б. 182]; Тәңре буйруқы улды, ун ики уғыл бәңа рузи қылды [Кол Гали, б. 246];

ярлыкаучы: Йарлықамақ – Тәңредин, һичкем дәгүл [Мөхәммәдьяр, б. 54].

Язма текстларда Алланың төрки-татар асыллы икенче атамасы буларак *Изе* сүзе дә очрый (< *Ädi // Äzi* ‘алла, хуҗа’): Изем бәңа рузи қылды бу дәүләти [Кол Гали, б. 120]; Изеси қаза вирмеш [Кол Гали, б.196].

Тәңредән аермалы буларак, биредә ул, нигездә, гарәп асыллы эпитетлар белән бергә кулланыла. Мәсәлән: Хатеримни рәушан қылғыл, Изем лятиф [Кол Гали, б. 48]; Сезгә ғәзим афәт вирә Изем бари [Кол Гали, б. 84]; Әйа солтан, қавидер, қадир ирүр Изем сөбхан [Кол Гали, б. 172]; Улуқ сәғәт ғәреш Изесе, улу Сөбхан, ... [Кол Гали, б. 182]; Аның Изесе вар ирүр, қадир Сөбхан, ... [Кол Гали, б. 196]; Дүгәл

ишә қадир дурур Изем бари [Кол Гали, б. 274]; Қәрдәшләриме дуст қылды Изем сөбхан [Кол Гали, б. 274]; Изең һәм мәзһәбен белмәз татар сән [Мөхәммәдъяр, б. 52].

Гарәп асыллы *гәреш* ‘күк түбәсе, күкнең иң югары катлавы’лексемасы белән бергә килгәндә, ул үзенең беренчел мәгънәсендә кулланыла: Ғәреш Изесе безләрә қәһәр қылды [Кол Гали, б. 106]; Аны йаулақ ғәни итмеш Ғәреш Изесе [Кол Гали, б. 128]; Ғәреш Изесе сәңа рузи қылмыш имди [Кол Гали, б. 162].

Шуның белән бергә язма текстларда Аллаһы Тәгаләнең гарәп асыллы башка эпитетлары да теркәлде:

Әхәд (احد) ‘Бер’: Әлхәмдү шөкер вә сипас ул Әхәдә [Кол Гали, б. 46]; Мөлкәт эчрә биля шәрик ул Әхәдә [Кол Гали, б. 46];

Самәд (صمد) ‘Мәңге бетмәс’: Самәд күрәр, күргәнин һич йаңылмаз, Самәд бушуб йаздығын қол аңламаз, Самәд уқы дуқынса, һич уңалмаз [Кол Гали, б. 168]; Йусеф сиддиқ бәнүм қолум улур иди, ғобудийәт Самәдинә қылур ирди, мөдам Самәд әмрилә йүрер ирди, Самәд аңа улу мөлек вирир имди [Кол Гали, б. 212];

Зүл-Җәлял (ذولجلال) ‘Олылык иясе’: ... аны бақи Зүл-Җәлял белдек имди [Кол Гали, б. 46];

Җәббар (خبار) ‘Куәтле’: Аның васфын Қөръан эчрә үкди Җәббар [Кол Гали, б. 46]; Иқрар қылдым, инандым бер Җәббарә [Кол Гали, б. 214];

Ғәффар (غفار) ‘Кичерүче’: Зәһи диққәт ғәта вирмеш аңа Ғәффар [Кол Гали, б. 46]; Өмид уйлә дутарым ул Ғәффарға [Кол Гали, б. 262];

Халиқ (خالق) ‘Яратучы, бар кылучы’: Җөмләсендән Халиқ рази улсун имди [Кол Гали, б. 48]; Кучылардан бәкләсүн Халиқ сези [Кол Гали, б. 54]; Халиқ ани Йусефә мөшфиқ қылды [Кол Гали, б. 68]; Халиқдан узун ғөмер теләр имди [Кол Гали, б. 72]; Халиқ аңа узун ғөмер рузи қылды [Кол Гали, б. 72];

Хақ (حق) ‘Чын’: Хақдин рәхмәт даим улсун һәм анлара [Кол Гали, б. 48]; Йағқуб сәүчи Хақға ғаси һич улмады [Кол Гали, б. 70]; Хақ сәлями-дөруди кәлди ирсә [Кол Гали, б. 76]; Хақ хөкменә қоллар рази улмыш кәрәк [Кол Гали, б. 100]; Хақ тәқдире бүйлә иркән, кимсә белмәз [Кол Гали, б. 102]; Нәтәр дошман, Хақ мәңа булса йар [Мөхәммәдьяр, б. 47]. И теләкләр биргүче Хақ, Падишаһ, колларыңа сәндин үңин йуқ пәнаһ [Мөхәммәдьяр, б. 54].

Рәхман (رحمان) ‘Мәрхәмәтле’: Иляһем рәхманемғә сығынмайынму [Кол Гали, б. 48]; Дәрмандәләр дәстгире Мәлик рәхман [Кол Гали, б. 76]; Андан соңра Рәхман рәхим қылдачидур [Кол Гали, б. 198];

Сөбхан (سبحان) ‘Мактаулы’: Сөбханемдән мәдәд-йари теләмәйенмү [Кол Гали, б. 48]; Сөбхан сәңа тәлим ихсан қылур имди [Кол Гали, б. 54]; Йусеф һәрдәм йалуарыр Сөбханенә [Кол Гали, б. 176]; Мунчә лөтъф-у кәрәм кәлди Сөбханемдән [Кол Гали, б. 182]; Ғилм-ү хикмәт рузи қылмыш аңа Сөбхан [Кол Гали, б. 196];

Мәүля (مولی’مولا ) ‘Хуҗа’: Мәүлем, сәңа сығынурмын мән

бер зәғиф [Кол Гали, б. 48]; Өмиддер-кем, Мәүлядән мәдәд ирди [Кол Гали, б. 52]; Бәс, Мәүлүмдән әмер-хөкем үйлә улса [Кол Гали, б. 216]; Мәүля бәңа бу ғинайәт качан кыла? [Кол Гали, б. 256];

Лятиф (لطيف) 'Сизгер': Хәтеримне рәушан кылғыл, Изем лятиф [Кол Гали, б. 48];

Җәлил (جليل) 'Бөек': Әй, кәрдәшләр, күрмәзмесез ул Җәлили? [Кол Гали, б. 66]; Ушбу эше Җәлил рәуа күрмәз имди [Кол Гали, б. 66]; Уд эчендә сақлады аны Җәлил [Кол Гали, б. 70]; Йа Йусеф, Җәлил әмре бүйлә дорыр [Кол Гали, б. 206]; Мәүля Җәлил Җәбраилә һәм бойурды [Кол Гали, б. 222];

Кәрим (كريم) 'Юмарт': Иляһәна, кәрим Хәннан, бичаралар өмиде сән, рәхим Мәннан [Кол Гали, б. 74]; Йа Кәрим, дир, фазлең берлә йарлықағыл [Кол Гали, б. 106]; Кәрим Аллаһ кәлименә әмер қылды [Кол Гали, б. 290];

Хәннан (حنان) 'Мәрхәмәтле': Иляһәна, кәрим Хәннан, бичаралар өмиде сән, рәхим Мәннан [Кол Гали, б. 74];

Рәхим (رحيم) 'Рәхимле': Йа Рәхим, дир, бәнем хәлем сән белүрсән [Кол Гали, б. 106]; Рәхим Мәүлем рәхмәтенә билен бағлар [Кол Гали, б. 184];

Мәннан (منان) 'Нигъмәт бирүче': Иляһәна, кәрим Хәннан, бичаралар өмиде сән, рәхим Мәннан [Кол Гали, б. 74];

Мәлик (ملك) 'Хөкемдар': Дәрмандәләр дәстгире Мәлик рәхман [Кол Гали, б. 76]; Улуғ мәнсаб вирде аңа Мәлик сөбхан [Кол Гали, б. 108]; Һәман дәмдә бер фәрештә кәлде хазир, виреб йиде ул Йусефә Мәлик қадир [Кол Гали, б. 166]; Андан соңра үкүш дәгүл, бир қач күндән, ғәзизнең җанын алды Мәлик рәхман [Кол Гали, б. 178];

Қадир (قدير) 'Кодрәт иясе': Қадир аңа ғәта қылмыш қати қуввәт [Кол Гали, б. 76]; Қадир Мәүлем тәкдирени кем шашыра? [Кол Гали, б. 92]; Бәс, Қадирдән хөкем-фәрман үйлә улды [Кол Гали, б. 122]; Фазле берлә қортарды Қадир дәййан [Кол Гали, б. 200]; Ғәта қылды Қадир сөбхан [Кол Гали, б. 202]; Қадир улдур – қолға ризықын биргүче [Мөхәммәдъяр, б. 54];

Бари (بارى) 'Юктан бар кылучы': Сезгә ғәзим афәт вирә Изем бари [Кол Гали, б. 84]; Дүгәл ишә қадир дурур Изем бари [Кол Гали, б. 274];

Ғафир (غافر) 'Ярлыкаучы': Бу тәкдире қылды бәңа Мәүлем ғафир [Кол Гали, б. с. 102];

Раббе (رب) 'Хуҗа': Йа Раббе, нидән улды безгә ушбу туфан? [Кол Гали, б. 106]; Йа Раббе, зинданы ихтийар қылдым имди! [Кол Гали, б. 176];

Ғәлим (عليم) 'Бар нәрсәне белүче': Йа Ғәлим, дир, һәр хәл эчрә сәңа пәнаһ қылдум имди! [Кол Гали, б. 106];

Ғәфур (غفور) 'Ярлыкаучы': Ходавәндә, Ғәфур ғөфран, куртылмаға булумадым һәргиз дәрман [Кол Гали, б. 168];

Қави (قوى) 'бар нәрсәдән көчле': Әйа солтан, қавидер, қадир ирүр Изем сөбхан [Кол Гали, б. 172].

Мисаллардан күренгәнчә, язма текстларда Аллаһы Тәгаләнең исемнәре күпчелек очракта парлап кулланылалар. Шул

рәвешле аларга хас образлылык тагын да көчәйтелә һәм аңа карата чиктән тыш буйсынучанлык, ихтирам белдерелә.

**Әдәбият**

*Ахметгалиева Я.С.* Исследование тюркоязычного памятника «Кисекбаш китабы». М.: Наука, 1979. 191 с.

*Бәширова И.Б.* Хәзерге татар әдәби теле. Семасиология: татар лексикасында системалы бәйләнеш-мөнәсәбәтләр. Казан: ИЯЛИ АН РТ, 2006, 192 б.

Древнетюркский словарь. Л.: Наука, 1969. 676 с.

*Зайнуллин Г.Г.* Татарская богословская литература XVIII – начала XX веков и ее стиле-языковые особенности: дис. в виде науч. докл. … д-ра филол. наук. Казань, 1999. 107 с.

*Кадирова Э.Х.* Поэмы Мухаммедъяра «Тухфа-и мардан» и «Нур-и содур: лексика. Казань: РИЦ: «Дом печати», 2001. 232 с.

*Кол Гали.* Кыйссаи Йосыф. Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. 543 б.

*Мөхәммәдъяр.* Нуры содур. Поэмалар, шигырь. Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. 336 б.

*Нуриева Ф.Ш.* Исторические и лингвистические условия формирования тюрко-татарского литературного языка золотоордынского периода. Казань: Казанский государственный университет, 2004. 376 с.

Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Пратюркский язык-основа. Картина мира пратюркского этноса по данным языка / отв. ред. Э.Р. Тенишев, А.В. Дыбо. М.: Наука, 2006. 908 с.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: өч томда. I т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. 476 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: өч томда. III т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. 832 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: I т.: А–В. Казан: ТӘҺСИ, 2015. 712 б.

Татар теленең этимологик сүзлеге: ике томда. I т. (А–Л). Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015. 543 б.

Татар теленең этимологик сүзлеге: ике томда. II т. (М–Я). Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015. 567 б.

*Хаков В.Х.* Тел – тарих көзгесе (Татар әдәби теленең үсеш тарихыннан). Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. 295 б.

*Хисамова Ф.М.* Татарский язык в восточной дипломатии (XVI – нач. XIX в.). Казань: Мастер Лайн, 1999. 408 с.

*Мәкалә РФФИ һәм Татарстан Республикасы хөкүмәтенең финанс ярдәме белән 16-14-16011 номерлы проект кысаларында әзерләнде*

***Мирхәев Рифат Фирдинат улы,***
*филология фәннәре кандидаты, доцент, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 811.512.145′282

***А.Җ. Хөсәенова***

# ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ ДИАЛЕКТЛАРЫНДА СОМАТИЗМНАР

В современном языкознании соматическая лексика характеризуется как определенная лексико-семантическая система, в которой отражаются знания, представления носителей языка о самом себе и своем организме. В статье рассматриваются вопросы изучении названий соматизмов в татарском языке и диалектах.

**Ключевые слова:** когнитивная лингвистика, терминологическая лексика, татарская лексикология, диалектная лексика, соматизмы.

Башка катламнар кебек ук, телнең сүзлек байлыгы да киң һәм күпкырлы системаны тәшкил итә, чөнки сүзлек составына бер-берсенә төрле мөнәсәбәтләр белән бәйләнгән күп лексик берәмлекләр керә. Тел аралашу чарасы буларак уңышлы кулланылсын өчен, лексика да аерым бер тәртиптә оешырга тиеш. Аның гомуми үсеше, кулланылыш өлкәсенең киңәюе билгеле бер дәрәҗәдә терминологик атамаларны туплау, үстерү, системага салуга бәйле. Галимнәр билгеләвенчә, хәзерге телләрдә барлыкка килүче 90% яңа сүзләр махсус лексиканы тәшкил итә. Шуңа күрә дә әлеге төр сүзләр күп кенә телче галимнәрнең игътибарын үзләренә җәлеп итәләр.

Хәзерге заманда телдә кеше факторын өйрәнүгә игътибар арта бара, имманент лингвистикадан телне кеше, аның аңы, фикер йөртүе, рухи-гамәли эшчәнлеге белән тыгыз бәйләнештә өйрәнүне максат итеп куйган антропологик лингвистикага күчеш күзәтелә [Роль человеческого..., с. 8]. Шуңа бәйле рәвештә, соматизмнар да яңа аспектлардан чыгып өйрәнелә. Әлеге төр сүзләр, ягъни кеше тәне әгъзаларын, чир атамаларын атаган лексика – татар теленең иң кызыклы лексик-семантик төркемнәрен тәшкил итәләр. «Соматик» атамасы [грек *soma (somatos)* – җисем] биологиядә һәм медицинада «кеше җисеме белән бәйле» дигән мәгънәдә кулланыла, «психика» төшенчәсенә каршы куела. Тел белемендә соматизмнар XX йөзнең икенче яртысыннан өйрәнелә башлый. Алар күренекле телчеләрнең чагыштырма-тарихи, лингвокультурологик хезмәтләрендә төп тикшерү объекты, гадәттә тел системасында иң беренче чиратта аерып чыгарыла торган лексик катлам булып торалар.

Бу төр сүзләр телдә күп гасырлар дәвамында формалашкан төп сүзлек байлыгына карый һәм кешеләрнең тирә-як дөнья турында мәгълүмат биреп кенә калмый, ә аларның үзләре, үз организмнары турындагы белемнәрен дә чагылдыра. Кеше әйләнә-тирә мохиттә үз урынын турыдан-туры сизү органнары һәм тән әгъзалары ярдәмендә билгели. Алар-

ның атамалары телдәге башка күп кенә лексик берәмлекләр кебек борынгы катламны тәшкил итә. Кеше шушы танып белү «инструменты» ярдәмендә билгеле бер пространство һәм вакыт аралыгында, дөньяга карашын белдереп, үз урынын билгели. Әлеге процесста эталон ролен кеше тәненең структур ассиметриясен чагылдырган сизү, күрү органнары урнашкан алгы һәм арткы өлешләре үти [Богус, б. 8–9]

Соматик сүзләр телнең төп лексик фондына карый һәм алар арасында бик борынгы чорларга караганнары да, соңрак барлыкка килгәннәре дә бар. Бүгенге көндә анатомия һәм физиология терминнары күп кенә телчеләр тарафыннан тикшерелә. Биредә М. Корбангалиев, Р.М. Гатин, Р.Р. Шәмсетдинова, Ю.А. Кривощапова, Т.А. Трафименкова, П.Ш. Абдулхалимова һ.б галимнәрнең хезмәтләрен атап үтәргә мөмкин.

Шулай да, татар тел белемендә соматизмнар аерым аспектларда бик аз өйрәнелгән. Татар телендә кеше, кеше тәненең әгъзалары темасы Д.Б. Рамазанова тарафыннан «Татар телендә кешегә бәйләнешле лексика» (2013) дигән хезмәтендә синхроник һәм диахроник планда, башка телләр белән чагыштырылып махсус тикшерелә. Галим соматизмнарны ике зур төркемгә бүлеп карый:

1) кешенең физик төзелешен, әгъзаларын белдерә торган сүзләр;

2) кешенең эчке дөньясын белдерә торган сүзләр [Рамазанова, 2013, б. 4].

Моннан тыш әлеге темага багышланган тикшеренүләр Ф.С. Баязитова, Л.Г. Габдрахманова, Л.И. Муравьева, Н.Г. Йосыпова, И.И. Сабитова, Г.Ч. Файзуллина, А.М. Ямалетдинова хезмәтләрендә урын ала. Ләкин татар соматик лексикасын бар яклап та комплекслы тирәнтен тикшерү киләчәк бурычы булып кала бирә.

Татар әдәби телендә һәм диалектларда нигездә бер үк соматизмнар кулланыла (*баш, кул, беләк, уч, бармак, аяк, сөяк, сеңер, җилек, арка, кабырга, бөер, йөрәк, күз, колак, борын* һ.б.). Мәгънәләре ягыннан да алар бер-берсенә туры киләләр. Әлеге лексик берәмлекләрне А.М. Кочеваткин классификациясе буенча [Кочеваткин, 2001] һәм атау объектының үзенчәлекләре нигезендә түбәндәгечә төркемләргә мөмкин:

**1. Сомонимик лексика** (грекча *soma* «тән», *onim* «исем, атама») – кеше тәненең өлешләрен атаучы сүзләр. **Арға** 1. Себ. арка (спина); 2. Арт (задняя часть). Чуал арғазына кирде. – твр. [Татар теленең..., б. 50]; **Бәбәнәк** II трх. Кул (рука). Чәчем белән җир себердем, бәбәнәгем белән җир казыдым (107 б.); **Бӧйын** тара. муен (шея) [Татар теленең..., б. 127].

**2. Остеонимик лексика** (грекча *osteon* «сөяк») кеше тәненең сөякләре һәм аларны тоташтырып торучы җисемнәр атамалары. **Арқа сабағы** перм. **арқа севәге** миш. д., **арқа сийәге** кмшл. Умыртка, умырткалык (позвоночник) Шәп қаты қайғының арқа сабағына зыйаны күп. – перм. Мына ушы тештән арқа сийәгем аwырта. – кмшл. [Татар

теленең..., б. 51]; **Арқа үзәге** минз. к.: **арқа чоқоры. Арқа чоқоры** мам. Арка сөяге (спинной хребет) [Татар теленең..., б. 51]; **Баш чирәбе** хвл,. мәл. баш сөяге (череп) [Татар теленең..., б. 105].

**3. Спланхнонимик лексика** (грекча *splanchna* «эчке органнар») кеше тәненең эчке органнары исеме. **Базык эчәге** т. я.-крш. юан эчәге (толстая кишка). Базык эчәге аwырта. (95 б.); **Баур** твр. бавыр (печень) [Татар теленең..., б. 104]; **Йōғы** брб.д. талак (селезенка) [Татар теленең..., б. 251].

**4. Ангионимик лексика** (грекча *angeion* «кан тамыры») – кеше тәненең кан тамырлары системасын атаучы сүзләр. **Қан** урт. д. кан (кровь) [Татар теленең..., б. 386]; **Қычу** дөб. кан басымы (кровяное давление). Әwәл қычу диләр ийе, қан басымы диләр хәзер [Татар теленең..., б. 451].

**5. Сенсонимик лексика** (грекча *sensus* «хис, тойгы») – кешенең сиземләү органнарын белдерүче сүзләр. **Ағыс** брб. д. Авыз (рот) [Татар теленең..., б. 20]; **Борын танаwы** дөб. Борын (нос). Борын танаwы җимерелмәсен, карап йөр [Татар теленең..., б. 129]; **Күс** себ. күз (глаз) [Татар теленең..., б. 358]; **Кылак** миш. д. колак (ухо) [Татар теленең..., б. 365].

**6. Чир атамалары. Аwыр төшү** 1. т.я. күзенең кызарып, яшь агып һәм эренләп авыруы (болезнь глаз: конъюктивит ). Күзенә аwыр төшкән, күзен дә ача алмый, бертуқтаусыз җәш аға, эрер қойола. – к.т. [Татар теленең..., б. 18]; **Әсбе** [рус. оспа] 1. Байк. чәчәк авыруы (оспа). Әсбә кара цир ул, бер керсә, кырып цыга ул йәш балаларны; 2. нрл. Сызлавык (фурункул, нарыв) [Татар теленең..., б. 88].

Мисаллардан күренгәнчә, сөйләшләрдә соматик атамалар өчен күп кенә семантик үзенчәлекләр хас булуга карамастан, әдәби тел белән уртаклыклар да шактый күп. Чөнки әлеге сүзләр нигездә номинатив характердагы конкрет мәгънәгә ия һәм аларга терминологиклык хас. Шулай да биредә аларның функцияләре киңәю, коннотатив, метафорик мәгънәләр барлыкка килүе дә күзәтелә.

Диалектларда соматик берәмлекләр, нигездә, аерым тән әгъзаларын яисә өлешләрен номинацияләүдә кулланылалар: *беләзеклек* «беләк сөяге», *дөбә (кабыргасы)* «нижнее грудное ребро» һ.б. Шул ук вакытта тән әгъзаларының аерым өлешләренең атамалары сүзтезмәләр белән дә бирелә: *уч табаны* «учның уртасы», *урта тийәк* «урта бармак», *айақ бите* «аяк табанының өске өлеше», *сакал севәге* «ияк сөяге», *арқа үзәге* «арка сөяге» һ.б. Алга таба әлеге сүзтезмәләр кушма сүзләргә әйләнәләр: *йанбаш* «оча сөяге», *йаналыш* «тын алу», *айагасты* «аяк табаны» һ.б.

Чир атамалары нигездә шулай ук әдәби тел белән туры килә. Мәсәлән: *авыру, чир* «болезнь» һ.б. Шуның белән бергә саф диалектизмнар да очрый:

*зыңқар* бгрс., кргл. (авыру). *Ике ел торгач, зыңқар булып китте* [Татар теленең..., б. 203];

*җыланкүз* перм. бармакка чыга торган шеш (нагноение

на пальце). Бармакка җыланкүз чыкты [Татар теленең..., б. 195];

*отыры* тбл. шайтан тырнагы (заусенец). Пармагына отыры цыгаты [Татар теленең..., б. 507] һ.б.

Семантик аспектта тикшерү диалектлар һәм сөйләшләрнең үзара бәйләнешле булганын һәм бер-берсенә тәэсир иткәнен күрсәтә. Мәсәлән, урта диалектта *кәсел кеше* дигән гыйбәрә бар. Ул «авыру, чирле кеше» дигән мәгънәне белдерә. Без сүзнең этимологиясе себер диалектларындагы *кәс* «начар, ахмак» дигән сүз белән бәйле дип саныйбыз. Мишәр диалектында әлеге сүз «булдыксыз, сәләтсез, уңмаган» мәгънәсен белдерә.

Тел үсеше барышында соматизмнарның семантикасы да киңәя. Моңа мисал итеп урта диалектның каргалы сөйләшендә *беләк* сүзендәге метафорик мәгънә көчәеш китерергә мөмкин. Биредә ул «бер тапкыр кулга уарлык күләмдә җеп чыгарырлык кәҗә мамыгы» мәгънәсендә кулланыла: *Маңганнан соң, бер беләклек алып беләккә урыйлар эрләр өчен, ул беләк була* [Татар теленең..., б. 113].

Татар теле сөйләшләрендә соматизмнар болар белән генә чикләнми әлбәттә. Әлеге төр сүзләрне лингвоструктур һәм башка аспектларда тикшерү зур әһәмияткә ия. Чөнки әлеге атамалар халыкның рухи дөньясы, ышанулары, эстетик карашлары белән тыгыз бәйләнгән. Алар тел мәдәниятен, аның гамәли, фәлсәфи нигезләрен аңларга ярдәм итә, тел аша белдерелгән дөнья картинасы сурәтләрен ачып бирә.

**Әдәбият**

*Богус З.А.* Соматизмы в разносистемных языках: семантико-словообразовательный и лингвокультурологический аспекты (на материале русского, адыгейского и английского языков). Автореф. дис. ... канд. филол. наук. Майкоп, 2006. 32 с.

*Кочеваткин А.М.* Соматическая лексика эрзянского языка. Саранск: Красный октябрь, 2001. 200 с.

Роль человеческого фактора в языке. Язык и картина мира / отв. ред. Б.А. Серебренников. М.: Наука, 1988. 216 с.

*Рамазанова Д.Б.* Татар телендә кешегә бәйләнешле лексика. Казан: ИЯЛИ, 2013. 364 б.

Татар теленең зур диалектологик сүзлеге / төз.: Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, З.Р. Садыйкова, Т.Х. Хәйретдинова. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. 839 б.

***Хөсәенова Алина Җәмил кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 821.512.145-2

*Ә.М. Закирҗанов*

# XX ГАСЫРНЫҢ I ЧИРЕГЕНДӘ ТАТАР ДРАМАТУРГИЯСЕ ҮСЕШЕНӘ НИСБӘТЛЕ КӘРИМ ТИНЧУРИН ИҖАТЫ

Статья посвящена рассмотрению творчества видного татарского драматурга Карима Тинчурина в контексте развития сценической литературы в первой трети XX века. Особое внимание уделяется выявлению социокультурных, общественных условий литературного процесса начала XX века и 1920–1930-х годов. Выявляя основные этапы творчества драматурга, исследуется его поиски в области тематики и жанрового своеобразия, конфликта и национального образа, художественных средств.

**Ключевые слова:** Карим Тинчурин, татарская драматургия, литературный процесс, эпоха, национальная особенность, жанр, конфликт.

Татар драматургиясе һәм театры тарихында җуелмас эз калдырып, татар мәдəниятен классик әсәрләре белән баеткан, аңа яңа рух, көч биреп, киң планда үсү-үзгәрүенә юл ачкан шәхесләребезнең берсе – Кәрим Тинчурин. XX гасыр башы һәм 1920–1930 еллар татар әдәбияты һәм сәнгатендә тирән эз калдырган К. Тинчурин иҗатыннан башка татар драматургиясе һәм театры тарихын тулы аңлап та, бәяләп тә булмый. Шактый кыска вакыт аралыгында ул артист, драматург, шагыйрь, театрны оештыручы, укытучы-педагог, театр сәнгате теоретигы булып таныла, һәрбер өлкәдә бай мирас калдыра, ә инде сәхнә әдәбиятында тулы мәктәбен булдыра.

К. Тинчурин XX гасырның 10 нчы елларында әдәби иҗатка килә. Чорның гаять катлаулы вакыйгалары, инкыйлаблар, күчеш дәверләре каршылыгына һәм иҗади эзләнүләренә бәйле рәвештә драматург иҗаты аерым чор-этаплар аша үтә. Билгеле булганча, төскә-биткә матур, шактый тормыш тәҗрибәсе туплаган егетне Г. Кариев 1910 елда «Сәйяр» труппасына эшкә чакыра. Истәлекләрдән күренгәнчә, аның артистлык таланты тиз ачыла. К. Тинчурин сәхнәдә Г. Камал, Г. Исхакый, Ф. Әмирхан, А. Островский, Ф. Шиллер һ.б. драматурглар әсәрләре буенча куелган спектакльләрдә гаять уңышлы образлар тудыра [Гыймранова; Арсланов, б. 27]. Бер яктан, артист буларак сәхнә серләренә төшенү, икенче яктан, татар, рус, чит ил авторларының иҗаты белән якыннан танышу, өченче яктан, җәмгыятьтә барган кискен үзгәрешләр йогынтысында К. Тинчурин әдәби иҗатка килә. Ул бер-бер артлы «Хәләл кәсеп», «Шомлы адым» (1910–1912), «Беренче чәчәкләр» (1914), «Ач гашыйк» (1915), «Назлы кияү» (1915), «Җилкуарлар» (1916), «Соңгы сәлам» (1917) пьесаларын яза. Патша цензурасы «Назлы

кияү»дән башка әсәрләрен сәхнәгә куярга рөхсәт бирмәсә дә, яшь автор иҗатын дәвам итә – чорның катлаулы сорауларына мөнәсәбәтле язылган хикәяләрен газета-журналларда бастыра.

К. Тинчурин иҗатка килгән еллар – татар драматургиясенең ныклап аякка басу, үз йөзен, стилен эзләү вакыты. Гасырның беренче унъеллыгында Г. Камал, Г. Исхакый, Г. Коләхмәтов, Ф. Әмирхан, И. Богданов, С. Рәмиев иҗатлары белән сәхнә әдәбияты тема һәм жанр төрлелегенә ирешеп, чынбарлыкка нисбәтле вакыйгаларны сурәтләү аша реализм юнәлешен үзләштерә, акрынлык белән синкретизмнан арына барып, сурәт чараларының бай төс-төсмерләрен бирә, үз чорының үзенчәлекле образларын тудыра. Ә инде гасырның икенче унъеллыгы сан һәм сыйфат үзгәрешләре белән характерлана. Инкыйлабтан соңгы реакция, Беренче бөтендөнья сугышы авырлыкларына карамастан, татар җәмгыяте Яңарыш рухы белән яши. Газета-журнал битләрендә татар халкының бүгенгесе һәм киләчәге, укыту программаларын үзгәртеп кору, кадимчелек һәм җәдитчелек, төрле социаль катлауларны берләштерү һ.б. мәсьәләләр буенча кызу бәхәсләр бара. Драматургия дә шул максатка хезмәт итә. XIX һәм XX гасырлар чигендә билгеле бер тәҗрибә туплаган драматурглар Шәрык һәм Гаребнең әдәби-эстетик фикере тәэсирен тоеп иҗат итәләр. Нәкъ менә Шәрыкның ерактан килгән традицияләре һәм рус-европа әдәбиятының чорга бәйле эзләнүләрен үзләштерү нәтиҗәсендә үзгә бер синтез рәвешендәге сәнгати табышлар татар әдәбиятының, шул исәптән драматургиянең милли үзенчәлеген хасил итә. Д. Заһидуллина билгеләп үткәнчә, жанрлар кушылу, Көнчыгыш һәм Көнбатышның әдәби традицияләре үтеп керү, фәлсәфи-әдәби синтез, төрле әдәби стильләр поэтикасы берләшү яңа әдәби фикерләүне чагылдыруга хезмәт итә [Загидуллина, 2013, с. 21–22]. Ул – сурәтләнгән тормыш материалында, милли типлар, характерлар тудыруда, тормышчан ситуацияләрдә, сурәт чараларында һ.б.да чагыла. Ул елларда актив иҗатта булган драматурглар янына М. Фәйзи. К. Тинчурин, Ш. Камал, Ф. Бурнаш һ.б. килеп кушыла.

Татар тормышын сурәтләү аша драматурглар чынбарлыктагы җитди проблемаларны укучы-тамашачы алдына куялар. Аерым алганда, җәмгыятьтәге искелек һәм яңалык көрәше чагылышы буларак, һәртөр әхлаксызлык күренешләрен, социаль каршылыкларны, аеруча байларны һәм дин әһелләрен усал тәнкыйтьләгән әсәрләр (М. Фәйзи «Яшьләр алдатмыйлар», Ш. Камал «Хаҗи әфәнде өйләнә», Ф. Бурнаш «Язмыш», Ф. Сәйфи-Казанлы «Ямьсез тормыш» һ.б.) дөнья күрә. Бу елларда яңалыкка омтылган яшьләр үсеп җитә. Нәтиҗәдә төрле буын арасындагы каршылык җәмгыятьтә «аталар» һәм «балалар» конфликты төсендә чагылыш табып, сәхнә әдәбиятына да үтеп керә. Мисал өчен, Ф. Әмирханның «Тигезсезләр»е әлеге мәсьәлә гыйбрәтле

чагылыш тапкан пьеса буларак яңгыраш ала.

Драматургларның төрле юнәлештәге эзләнүләре, «эстетик яңарыш романтизм иҗат юнәлеше формалашуга китерә» [Ханзафаров, б. 32]. Бу чорда драматурглар урта гасырлар әдәбиятына хас экзотик күренешләр, гадәттән тыш геройлар, купшы пафос кебек сыйфатлардан арынып, ике дөнья сурәте тудыруга, хыялидеал белән бәйле күренешләргә мөрәҗәгать итәләр, чынбарлык белән килешә алмаган, нечкә күңелле, мәхәббәт утында янучы геройларны, заман проблемалары белән тыгыз бәйләнештә мәйданга чыгаралар. Мисал өчен, Г. Исхакыйның «Мөгаллимә», М. Фәйзинең «Кызганыч», «Галиябану» кебек пьесаларында шәхес иреге, хатын-кыз язмышы, милләткә хезмәт итү мәсьәләләре романтик эстетика таләпләреннән чыгып яктыртыла.

К. Тинчурин татар җәмгыятендә һәм сәхнә әдәбиятында барган әлеге үзгәрешләр, эзләнүләр уртасында яши. Октябрьгә кадәрге иҗатының иң яхшы үрнәкләре булган «Беренче чәчәкләр», «Назлы кияү», «Соңгы сәлам» пьесаларында Г. Камал, Г. Исхакый, Ф. Әмирхан һ.б. иҗатындагы табышларны үстерә. Драматургның башлангыч чор иҗатына караган әсәрләре билгеле бер кимчелекләрдән азат булмаса да, аларда яшь әдипнең заман рухында иҗат итүе, үз чоры проблемаларын уңышлы тотып алуы, остазлары тәҗрибәсен уңышлы үстерүе, баетуы, гомумән, шәхси стилен эзләве чагылыш таба [Әхмәдуллин, 1993, б. 210].

«Беренче чәчәкләр» К. Тинчурин иҗатында программ әсәр булып санала ала. Халкына хезмәт итү, аны яңарышка рухландыру теләге белән янып яшәгән автор әлеге пьесада чорның гаять актуаль мәсьәләләрен күтәрә: милләтнең төрле социаль катлауларын берләштерү, хатын-кыз азатлыгы, мәгариф системасын үзгәртеп кору, миллимәдәни үсештә рус-европа халыклары дәрәҗәсенә ирешү, хокуксызлыктан, милли һәм социаль изүдән котылу һ.б. Әсәрнең төп герое Хәмит халыкчылык идеясен яклап болай ди: «Халыкка аң кертергә кирәк..., уятырга кирәк. Минем тоткан юлым шул: халыкта үзен үзе аңлау хисен уятырга кирәк». Әлеге фикер К. Тинчуринның бөтен иҗатын иңләп үтә. Ә менә «Назлы кияү»дә драматург Г. Камал, И. Богданов песаларында урын алган «кияү егетләре»нең яңа тибын сурәтли. «Безнең шәһәрнең серләре»ндә кәләш эзләп Казанга килгән Себер бае төрле ситуацияләрне һәм типларны ачу өчен өлге булып хезмәт итсә, И. Богдановның «Помада мәсьәләсе»ндәгечә гаиләгә, хатын-кызга булган иске карашлар фаш ителә. К. Тинчурин «Назлы кияү» комедиясендә, Төркестаннан килеп «укымышлы, общество күргән кызга өйләнү» нияте белән йөрүче Рәшитнең беркатлылыгын, мәгънәсезлеген генә түгел, шул чор җәмгыятендәге социаль катламнарның «чын йөзе»н дә ача. «Соңгы сәлам» драматургның, Шәрык һәм Гареб йогынтысын тойган хәлдә, татар драматургиясен үстерүнең төрле

юлларын эзләвен чагылдыра. А. Әхмәдуллин билгеләп үткәнчә, пьеса үзенең хисләрендә, теләк-омтылышларында адашып калган яшь буржуа образын гәүдәләндерүе белән кызыклы [Әхмәдуллин, 1980, б.156]. Автор геройларының рухи кичерешләрен ачуда яңа алымнар эзли, шуңа да әсәрдә тирән психологизм белән янәшә сентименталь пафос, сызланулы (экзистенциональ) халәт урын ала. Ә инде «без китап кушканча эшләдек. Дәүләт (мал, байлык. – *Ә.З.*) кайдан килгән булса, шунда азаттык та» дип яшәүче Мөхәммәтша эш-гамәлләрендә суфичылыктан килүче фикерләренең яңа эчтәлек белән баюын чагылдыра.

К. Тинчурин иҗатының үзәген тәшкил иткән 1920 еллар татар драматургиясе үсеш процессында җитди сыйфат үзгәрешләре белән аерылып тора. Инкыйлаблар, гражданнар сугышы, 20 нче елларның каршылыклы хәяты, шулай ук ачлык, НЭП еллары, алфавит алышыну, «милләтче»ләрне эзәрлекләүләр башлану һ.б., гомумән, әдәбиятның эчтәлеген тамырдан үзгәртә. Татар әдипләренең абсолют күпчелеге, шул исәптән К. Тинчурин да, инкыйлабларны шатланып каршы ала һәм яңа тормыш белән рухланып иҗат итә. Билгеле булганча, әдәбият-сәнгать совет идеологиясе тудырган мифларны пропагандалауга хезмәт иттерелә. Алар исә, нигездә, ике юнәлештә чагыла: берсе – үткәнне бары тик каралтып сурәтләү, икенчесе – совет җәмгыятен, аның казанышларын күпертеп, каршылыкларын шомартып һәм якты төсләрдә чагылдыру [Закирҗанов, б. 217]. Бу чорда үткәнне һәм бүгенге чынбарлыкны ничек чагылдыруга бәйле җитди бәхәсләр бара. Язучыларны «пролетар», «крестьян» һәм «юлаучылар» дигән төркемнәргә бүлеп карау (К. Тинчурин соңгысына кертелә) эчке каршылыкны тагы да арттыра. Сәхнә әдәбиятында Г. Ибраһимов, К. Тинчурин, Ф. Сәйфи-Казанлы, Ф. Бурнаш, Н. Исәнбәт, Ш. Усманов актив эшли, аларга пьесалары белән Һ. Такташ, Ш. Камал, Т. Гыйззәт һ.б. килеп кушыла. Җитди яңалык рәвешендә тематик төрлелек күзәтелә: гражданнар сугышы, инкыйлаб һәм кеше, шәхес иреге, социаль һәм сыйнфый тигезлек, бәхеткә хокук, милләт язмышы, яңа җәмгыять төзү, дингә каршы көрәш, җитәкчеләргә мәдхия уку, интернационализм идеясен яклау һ.б.

Чор драматургиясенең йөзен билгеләгән әсәрләр булып Г. Ибраһимовның «Яңа кешеләр», Ф. Сәйфи-Казанлының «Дошманнар», Н. Исәнбәтнең «Һиҗрәт», «Пикүләй Шәрәфи», «Портфель», Ш. Усмановның «Канлы көннәрдә», Ф. Бурнашның «Камали карт», «Хөсәен мирза», «Адашкан кыз», Т. Гыйззәтнең «Наемщик», Һ. Такташның «Җир уллары трагедиясе», «Югалган матурлык», М. Фәйзинең «Асылъяр», Ш. Камалның «Ут», «Козгыннар оясында» кебек пьесалар тора. К. Тинчуринның бу чор иҗаты да гомум әдәби процесска кушылып китә һәм үзенең әһәмияте белән аның үсеш-үзгәрешенә яңа сулыш өрә. Бу елларда әдипнең «Казан сөлгесе»

(1923), «Зар» (1923), «Сүнгән йолдызлар» (1923), «Американ» (1924), «Җилкәнсезләр» (1925), «Зәңгәр шәл» (1926), «Ил» (1927), «Хикмәтле доклад» (1928) кебек пьесалары языла, сәхнәгә менә. Драматург комедия жанрының яңа, эчке сыйфатларын ачып, яңа баскычка күтәрә. Элекке байларны, кичәге җәмәгать хадимнәрен фаш итүне максат иткән «Американ»ы чор рухын чагылдыру аша, татарга хас сыйфатлар, аның менталитеты турында җитди уйлануга алып чыга. Мәзәк хәлләрдә, комедиячел ситуацияләрдә бөтен түбәнлекләрен, наданлыкларын, мин-минлекләрен, буш куык булуларын уңышлы алым-чараларда ачып, үзләрен зыялылар, җирнең кендеге дип санаучылардан ачы итеп көлә. Болар «кичәгеләр», тарих чүплегендә генә калучылар дип тә булмый, чөнки алмашка киләбез дип лаф оручылар – Искәндәр белән Апушлар – алардан әллә ни аерылмый.

Драматургның җитди яңалыгы Камал, Исхакыйлардан килүче комедия жанрына хас көлү алымнарын баетуда чагыла. Үзен гаҗәеп мәзәк хәлләр, көлкеле ситуацияләр, уен эчендә уен кору остасы итеп таныта. Шуларга нисбәтле һәртөр мәгънәсезлектән тел чаралары, жорлык, тапкырлык ярдәмендә көлә. Халыкчан көлүнең нигезен тәшкил иткән карнаваллык, ягъни халык йола-бәйрәмнәренә бәйле образлы-символик фикерләү яңа төсмерләр белән баеп, чистарынуга китерә. Драматургның «Казан сөлгесе», «Зәңгәр шәл»ендә көлү, уен-көлке тирән мәгънәле җыр-музыка белән кушылып китә һәм ул аның стиль үзенчәлеген дә билгели. Э. Галиева язганча, «ул халыкчан юморны, халыкчан көлүне, «карнавальләштерү»не лирик, музыкаль башлангыч белән оста үрә белде. Шуларның икесен бергә тоташтырды, синтезлаштырды» [Галиева, б. 35].

М. Фәйзи башлап җибәргән музыкаль драма жанрын К. Тинчурин яңа баскычка күтәрә. Җыр татар халкының гомерлек юлдашы, шатлык-куанычын да, кайгы-хәсрәтен дә ул көй-моңга салган. Шуңа да мелодрама жанры башлангычында ук киң яңгыраш ала һәм бүген дә, татар театрының милли үзенчәлеген билгеләгән жанр формасы буларак, сәхнәләрдән төшми. Драматургның «Казан сөлгесе», «Зәңгәр шәл» «Сүнгән йолдызлар», «Ил» пьесаларын җырлардан башка күз алдына да китереп булмый. Аларда җырлар әсәрнең мөһим компоненты, гадәттә фикерне укучы-тамашачыга җиткерү алымы булып тора. Җырларда геройның күңел халәте, теләк-омтылышы, хәтта аң төпкелендә сакланган серле, интим хис-кичерешләре чагылыш таба. Без моны «Сүнгән йолдызлар»дагы акылын җуйган Сәрвәрдә генә түгел, бәлки «Зәңгәр шәл»дәге Булат һәм Мәйсәрә, «Ил»дәге Айтуган, Зифабану, Юлаучы җырларында да тоябыз.

К. Тинчурин әсәр текстына керткән җырлар фольклорга тартым булулары белән дә халык иҗатына якыная һәм һәркем күңелен биләп алып, укучы белән әсәр, тамашачы белән театр сәхнәсен үзара бәйли, тоташтыра.

К. Тинчурин һәм С. Сәйдәшевнең уртак иҗаты буларак туган җырлар ана телен онытучыларның да күңелен кузгатып, милли хисләрен уята. Бу да әсәрләрнең кыйммәтен билгеләүче бер күрсәткеч. Пьеса текстына килеп кергән җыр-моң, кичке уеннар, аулак өйләр, бербөтенгә әйләнеп, халыкның матур рухын, кешелекле яшәешен һәм һәртөр явызлык-начарлыкка каршылыгын чагылдыра. Тинчурин әсәрләре буенча куелган спектакльләрдәге әлеге хис-халәт тамашачыга күчеп, аның күңелен сафландыра, өмет-хыялын үстерә. Шул рәвешле, идеология тудырган мифлар кире кагылып, халык Хәтере белән бәйле мәңгелек Моң, Өмет, Ирек тудырган хис-кичереш беренче планга күтәрелә. Драматург пьесаларының төрле буыннар, хәтта төрле милләт кешеләре өчен дә кызыклы, гыйбрәтле булуының бер сәбәбе әнә шунда.

Драматург иҗаты 20 нче еллар әдәби процессыннан аерылгысыз, ул хакимият таләпләрен кабул итәргә мәҗбүр. Шуңа да пьесаларында октябрьгә кадәрге тормышның авырлыклары, сыйфый көрәш, байлар-ярлылар каршылыгы, руханиларның әдәпсез яшәү рәвеше кебек мәсьәләләр киң урын ала. Әмма әлеге күренеш-вакыйгалар артында, еш кына, әдипнең үзен борчыган-уйландырган, укучы-тамашачы белән уртаклашырга теләгән фикерләре дә чагылыш таба. «Зәңгәр шәл», «Сүнгән йолдызлар», «Җилкәнсезләр», «Ил» һ.б. пьесаларында лейтмотив буларак халыкның үткәне, бүгенгесе, киләчәге, аның теләк-омтылышы, өмете алга чыга. Символлаштырылган шәхес-мәхәббәт иреге, кеше азатлыгы яисә качкыннар язмышына бәйле күтәрелгән гаделлек, социаль тигезлек темасы, хакыйкатькә омтылу фикере һәм аларның җыр-музыкага, уен-биюләргә төреп бирелүе – болар барысы да «Зәңгәр шәл»не чор-вакыт чикләрен үтеп, бүген дә заманча яңгырашлы классик әсәр итә. Ә менә «Җилкәнсезләр» – бүген яңача укыла, бәяләнә торган әсәрләрнең берсе. Автор аерым кешеләр язмышы аша ил, халык фаҗигасенә алып чыга. Пьеса К. Тинчуринның күңел ярасын, әрнүле уйлануларын шактый тулы гәүдәләндерә. Шуңа да ул эстетик планда, трагикомедия жанрының уңышлы үрнәге буларак, елау аша көлүне чагылдыра.

К. Тинчурин иҗатының тагын бер үзенчәлеге шунда, аның әсәрләре төрлечә кабул ителә. Шул ук «Зәңгәр шәл»не берәүләр көнкүреш вакыйгалары урын алган дип аңласа, икенчеләр социаль-иҗтимагый яңгырашлы дип, өченчеләр исә сәяси эчтәлекле әсәр дип бәяли. «Назлы кияү», «Җилкәнсезләр», «Америкән», «Хикмәтле доклад» һ.б. пьесаларының да театр коллективлары, беренче чиратта, режиссерлар тарафыннан төрлечә шәрехләнүе күз алдыбызда.

Әдипнең дөньяга карашы, әдәби-эстетик идеаллары, сәнгати фикерләве дә үзгәреш кичерә. Әсәрләрнең язылу вакытын һәм аларга салынган әхлакый, фәлсәфи, сәнгати йөкләмәләрне карасак («Казан сөлгесе» белән бер

вакытта диярлек «Сүнгән йолдызлар» һәм «Зар», «Җилкәнсезләр» белән бергә дип әйтерлек «Зәңгәр шәл» языла), «авторның фикерләү стилендә параллельлек феномены» [Игламов Р., с. 91] урын алуын күрәбез. Әдипнең «Зар» (1923) трагедиясе, бердән, авторның сәнгати фикерләвендә сирәк кунак булган трагедия жанрында язылуы белән, икенчедән, дини мифологиягә мөрәҗәгать итүе һәм романтик сурәтлелеккә йөз тотуы белән үзенчәлекле. Автор 20 нче еллар башында Һ. Такташның «Җир уллары трагедиясе»ндә (1921) башланган җитди фәлсәфи бәхәскә кушыла һәм укучы-тамашачы белән бергә кеше һәм Алла, ирек һәм зиндан, мәхәббәт һәм гөнаһ, матурлык һәм явызлык төшенчәләре турында фәлсәфи уйлана. «Бәхәс-диалогларда уңай геройга авторның теләктәшлегендә аның эстетик идеалы төсмерләнә. Гүзәллек категориясе, сәнгатьнең асыл вазифасы турындагы фикерләр драматургның башка әсәрләрен аңлау өчен гаять кыйммәтле» [Ханзафаров, б. 460], – дип яза Н. Ханзафаров.

30 нчы елларда К. Тинчурин гаҗәеп зур сәяси, иҗтимагый, идеологик басым астында булып, аның әлеге халәте әсәрләрендә дә чагылыш таба. Шуның өстенә әдәби тәнкыйть тә еш кына берьяклы бәя белән чикләнә. Аерым язмаларда аның иҗаты уңай бәяләнсә, байтак мәкаләләрдә драматургны үткән тормыш вакыйгалары белән мавыгуда, чынбарлыкны сурәтләүдән качуда гаеплиләр. Театрдагы мохит тә уңай гына булмаган. 1927 елда театрны ташлап, кубарылып Әстерханга чыгып китүенең җитди сәбәпләре булуын һәркем яхшы аңлый. Шул елларда К. Тинчурин совет җәмгыяте тормышын әдәби чагылдыруга йөз тота. 1928 елда язылган «Хикмәтле доклад» комедиясе, Н. Исәнбәтнең «Пикүләй Шәрәфи»е, «Портфель»е белән бергә, драма төрендә яңа бер юнәлешкә нигез сала. Ф. Әмирханның «Шәфигулла агай» (1924) әсәрендә урын алган совет тормышының мәгънәсез эш-гамәлләреннән ачы итеп көлүне сәхнә теленә күчереп, драматург җәмгыятьтә урын алган бюрократик башбаштаклык, сүз һәм җыелышлар белән мавыгу, хезмәтнең дөрес оештырылмавы кебек мәсьәләләргә игътибарны юнәлтә, үз стиленә тугры калып, аларны бай көлү чаралары ярдәмендә фаш итә һәм шуның белән әлеге хакимияткә бәя бирә. Әсәрнең әледәнәле театр сәхнәләренә менүе дә аның һәр чорда яңача яңгыраш алуын күрсәтә. Кызганыч ки, К. Тинчурин һәм Н. Исәнбәтнең бу өлкәдәге эзләнүләре алга таба дәвам итми. «Солтангалиев эше»нә, «Җидегәнчелек»кә бәйле эзәрлекләүләр, бер төркем әдипләрнең кулга алынуы һ.б. шундый вакыйгалар язучыларны билгеле бер кысага куып кертә. 30 нчы елларда юмор-сатираның киселеп калуы әдәбият үсешендәге каршылыклар, югалтулар турында сөйли.

К. Тинчуринның шундый шартларда язылган «Кандыр буе» (1930) пьесасы тулысы белән авылда барган үзгәрешләргә багышланып, яңа җәмгыять төзү

идеясе белән янып яшәгән, үзен шуңа багышлаган кешеләрнең үзенчәлекле образларын тудыра. Бу яктан караганда, яңа тормышка мәдхия укый торган әсәр һич тә бер катламлы түгел. Н. Игъламов дәлилләгәнчә, Акбирдин белән Гөләндәм мөнәсәбәтендә, тискәре герой буларак сурәтләнгән Минһаҗ сүзләрендә, аерым сүз-репликаларда, деталь-фактларда драматургның колхоз системасына икеләнүле карашы, әлеге идеология яклаган идеалларны шиккә алуы чагыла [Игламов Н., с. 82–84 ].

Бу елларда К. Тинчуринга күптөрле борчу-хәсрәтләр кичерергә туры килә: 1930 елны аны театрдагы эшеннән азат итәләр, 1931 елны әтисен, энесе Юнысны, сеңлеге Гайшәне кулга алалар. Мондый шартларда аның иҗади эзләнүләренең саегуы табигый хәл. «Корыч орчык», «Тургай», «Булат бабай семьясы» кебек песаларын Ф. Сәйфи-Казанлы, Р. Ишморат, К. Нәҗмиләр белән берлектә язуы да аның икеләнүле халәтен, аркадашлар эзләвен күрсәтә кебек. Ә инде әдипнең үз-үзен, иҗади асылын табу омтылышы буларак 1935–1937 елларда «Мәрҗәннәр» циклы дөнья күрә. Татарның бөек улы 1938 елда тоталитар режим тарафыннан юк ителсә дә, аның бай мирасы халык күңелендә яши, чөнки «төп геройларының хис-кичерешләрен идеаллаштыру һәм романтик сыйфатларга төреп бирү, эмоциональ тәэсир итү, музыка белән кушу, символлаштыру алымнары ярдәмендә, драматург ирек сөюче, көчле кешеләрнең өстән билгеләнгәнлек, язмыш, көнкүреш фаҗигалелеген үтеп чыгу өчен көрәшен тасвирлый» [Загидуллина, 2016, с. 9].

Шулай итеп, К. Тинчурин XX йөз башы татар Яңарышы дулкынында, Шәрык һәм Гареб әдәби-эстетик фикере йогынтысын тойган хәлдә әдәби иҗатка килә. Остазлары Г. Камал, Г. Исхакый, Ф. Әмирхан, И. Богданов, С. Рәмиев һ.б. традицияләрен үстерә барып, үзен драматургиянең төрле жанрларында сынап карый, тема-мотивлар төрлелегенә омтыла. 1920 елларда ул татар сәхнә әдәбиятын әйдәп баручы ролендә иҗат итә һәм тематикада, жанрлар һәм жанр формаларында, музыкаль жанрның яңа хасиятләрен ачуда, көлү алымнарын үзләштерүдә, реалистик һәм романтик күренешләрне, төрле стиль чараларын кушып, үреп баруда һ.б. юнәлешләрдә җитди табышлар ясый; фольклар үрнәкләренә, халыкның йолагадәтләренә, бию-уеннарына нигезләнгән драма текстында җитди фәлсәфи һәм эстетик ачышлар ясый, яңа театраль фикерләүгә нигез сала. Талантлы драматург, фәлсәфәче Кәрим Тинчурин пьесалары бүген дә заманча яңгырый, яңадан-яңа укучы һәм тамашачылар күңеленә мәңгелек кыйммәтләр орлыгы чәчә.

**Әдәбият**

*Арсланов М.Г.* К.Тинчуринның тормышы һәм иҗат этаплары // Кәрим Тинчурин: тарихи-документаль, әдәби һәм биографик җыентык / төз. И. Һадиев, Р. Батулла). Казан: Җыен, 2011. Б. 25–31.

*Әхмәдуллин А.Г.* Драматург – новатор // Сәхнә әдәбияты һәм тормыш. Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. Б. 153–165.

*Әхмәдуллин А.Г.* Кәрим Тинчурин стиле // Дөреслеккә ирешү юлында. Мәкаләләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. Б. 208–215.

*Галиева Э.Р.* 1920–30 еллар татар әдәби һәм театр тәнкыйтендә Кәрим Тинчуринга бәяләмә // Кәрим Тинчурин һәм татар сәнгате: Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе материаллары. Казан: ИЯЛИ АН РТ, 2007. Б. 32–43.

*Гыймранова Д.* Без белмәгән Тинчурин // Мәдәни җомга. 2002. 22 ноябрь.

*Загидуллина Д.Ф.* Модернизм в татарской литературе первой трети XX века. Казань: Татар. кн. изд-во, 2013. 207 с.

*Загидуллина Д.Ф.* Татарская литература и национальный театр: одна дорога на двоих // Театр XXI века и вызовы нового времени: материалы международной научно-практической конференции, посвященный 110-летию татарского театра / под ред. Э.М. Галимовой. Казань: ИЯЛИ, 2016. С. 4–13.

*Закирҗанов Ә.М.* Кәрим Тинчурин поэтикасында символлар // Рухи таяныч: әдәби тәнкыйть мәкаләләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. Б. 212–219.

*Игламов Н.Р.* Об одной «забытой» пьесе: «На Кандре» К. Тинчурина // Кәрим Тинчурин һәм татар сәнгате: Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе материаллары. Казан: ИЯЛИ АН РТ, 2007. С. 75–84.

*Игламов Р.М.* Жизнь во времени // Кәрим Тинчурин һәм татар сәнгате: Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе материаллары. Казан: ИЯЛИ АН РТ, 2007. С. 85–95.

*Ханзафаров Н.М., Закирҗанов Ә.М.* Драматургия // Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. IV т. Казань: Татар. кит. нәшр., 2016. Б. 353–365.

*Ханзафаров Н.М.* Кәрим Тинчурин // Татар әдәбияты тарихы: алты томда. IV т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. Б. 452–469.

***Закирҗанов Әлфәт Мәгъсүмҗан улы,***
*филология фәннәре докторы, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге мөдире*
*Alfat_zak@mail.ru*

УДК 821.512.145-2

*А.Р. Салихова*

# КӘРИМ ТИНЧУРИН ПЬЕСАЛАРЫНЫҢ СӘНГАТИ ҮЗЕНЧӘЛЕГЕ

Драматургия К. Тинчурина — яркое и самобытное явление в национальной культуре. Его пьесы на протяжении многих лет не сходят со сцены. В статье рассматриваются характерные особенности произведений К. Тинчурина. С одной стороны, он выступал как продолжатель традиций татарского театра, а с другой — как новатор и экспериментатор.

**Ключевые слова:** комедия, драма, сатира, сюжет, художественное своеобразие, зрелищность.

Кәрим Тинчуринны бик хаклы рәвештә иң талантлы һәм үзенчәлекле милли драматургларыбызның берсе дип саный алабыз. Менә йөз елдан артык инде аның әсәрләренең сәхнәдән төшкәне юк. Әле бүген дә алар популярлыгын югалтмый, үзләренең гадәти булмаган сюжетлары, җанлы образлары, чын халыкчан юморы, шигъри аһәңе һәм хисси рухы белән режиссерлар игътибарын җәлеп итәләр. К. Тинчуринның әдәби мирасы гаять киңкырлы. Аның тарафыннан иҗат ителгән утызга якын пьеса төрле жанрны – социаль-психологик драмалардан башлап, романтик музыкаль мелодрамалар һәм кискен сатирик комедияләрне колачлый.

Үзенең драматургия өлкәсендәге эшчәнлегенең башлангыч этабында ук К. Тинчурин әсәрләренең идея эчтәлеге ягыннан да, художество формасы буенча да мөстәкыйль иҗади эзләнүләр һәм табышларга ирешү сәләтен раслый. Ул әдәби иҗатын социаль-психологик жанрга мөрәҗәгать итүдән башлый. 1913 елда язылган «Беренче чәчәкләр» пьесасы шул заманның татар әдәбиятына хас юнәлешләргә йөз тотып эшләнсә дә, анда К. Тинчуринның эстетик фикерләү үзенчәлекләре бөтенләй аерылып тора. Ул, барыннан да бигрәк, әсәрдәге төп конфликтларны чагылдыруда авторның калыпланган схемалардан баш тартуында күренә. Анда уңай һәм тискәре геройларны турыдан-туры каршылыкка куя юк. Беренче планда аерым кеше күңелендә барган идеяләр бәрелеше, тормышка караш төрлелеге күтәрелә. К. Тинчурин драмаларында үзе дә хаталардан хани булмаган геройның эчке каршылыгы, игелеккә һәм гаделлеккә омтылуы, эзләнүләре һәм икеләнүләре үзәк урынны били. Драматург тирән психологизмга омтыла, реаль тормыштагы катлаулылыкларны һәм каршылыкларны ачыклауны максат итеп куя. Гадәттә аның пьесаларында яшәүнең чын фәлсәфи мәгънәсе эпизодик персонажлар ярдәмендә ачыклана. Әсәр эчтәлегенең эчке идея-тематик юнәлеше аларның каршылыклы характерлары аша яктыртыла.

К. Тинчуринның театраль фикерләү осталыгы тагын шунда, ул кешенең укып кына түгел, ә күреп кабул итү сәләтенә дә исәп тота. Бу – авторның тәэсирле тышкы детальләр (мәсәлән: үлем түшәгендә яткан Хәмит янына шиңеп барган кызыл чәчәк куелу) кулланыуында, әсәрдәге парлы образлардан берсенең, икенчесен күзаллавы аша, көтелмәгән нәтиҗәгә килүендә, шулай ук вакыйга барган урын яки вакытның роленә әһәмият бирүдә чагылыш таба. К. Тинчурин иҗатын өйрәнеп тикшерүче театр белгече Р. Игламов болай дип яза: «По сравнению с драматургией прежних лет место и время действия тинчуринской пьесы более содержательно участвует в судьбе героя. Место и физическое время действия в пьесах Г. Камала и Ф. Амирхана были эстетически нейтральными… У Тинчурина создается определенная гамма настроения, меняющаяся от акта к акту. Атмосфера в пьесах Тинчурина поэтическая, она укрупняет ситуацию. Создается драматическая содержательная игра противоречий пространства и времени с умонастроением и чувствами героев. Возникает лирический аккомпанемент, а где это нужно – пародийное снижение или ироническое преувеличение по отношению к притязаниям комедийных персонажей» [Игламов, с. 18–19.]. Ул К. Тинчурин әсәрләрен А. Чеховның «Яңа драма»сы белән чагыштырып, аларның «геройсыз» һәм «фабуласыз», шуның белән бергә театраль процесс белән бәйләнешсез хәлдә булырга да мөмкин түгеллеген ассызыклый. Әлбәттә, К. Тинчуринның инкыйлабка кадәрге драматургиясендә аның сәнгати үзенчәлекләренә актерлык тәҗрибәсе дә йогынтысыз калмый. Сәхнә әсәрләре хакындагы рецензияләрдән ачыкланганча, аның иң уңышлы рольләре рус классик әсәрләрен һәм Г. Исхакый, Ф. Әмирхан кебек татар язучылары драмаларын сәхнәләштергәндә гәүдәләнгән. К. Тинчурин нәзакәтле, белемле, күтәренке рухтагы, тирән хисле һәм камиллеккә омтылган зыялылар образларын аеруча оста уйный.

Октябрь инкыйлабыннан соң драматург сәләтенең яңа чикләре ачыла. Ул үзен кискен сатирик комедияләр остасы итеп таныта. «Йосыф-Зөләйха», «Сәяси сакал», «Америкаң», «Хикмәтле доклад» – бу әсәрләр ачыктан-ачык фарска корылган. Бер яктан, алар Камал һәм Кариев традицияләрен дәвам итсәләр, икенче яктан, татар театрына чын мәгънәсендәге яңа күренеш алып киләләр. Үзенчәлек шунда – алар турыдан-туры агитацион рухта булалар. Характерлар кырыс, бәяләүләр аяусыз, ярымтоннар бөтенләй юк – барысы да җитешсезлекләрне, искелекне, дошман элементларны фаш итүгә юнәлдерелә. Сүз дә юк, алар – язучы иҗат иткән заман таләпләре, шул ук вакытта авторның жанрлар сайлау үзенчәлеге дә. Шунысы гаҗәп, ул пьесаларның кайберләренә әле бүген дә ихтыяҗ кимеми. Моның сәбәбе – аларның демократик рухта язылуы, җиңел куелышлы булуы һәм гадилеге. Аларда күтәрелгән фикерләр ачык, аңлаешлы һәм төгәл итеп

бирелгән. Үткен һәм җылы тел белән язылган җанлы һәм көчле характерлар, гади, әмма мәзәк хәлләр тасвирланган спектакльләр киң катлау тамашачыда уңай тәэсир уяталар.

К. Тинчурин мирасында музыкаль драма һәм комедияләр дә зур урын тота. Нәкъ менә шулар драматургка зур танылу китерәләр дә. Милли мәдәниятебез өчен дә аларның әһәмияте гаять зур. Пьесаларда көнкүреш, этнографик материаллар, аерым алганда музыкаль фольклор куллану үзешчән һәм профессиональ сәнгатьнең җанлы бердәмлеген хасил итә. Шундый музыкаль спектакльләр өстендә эшләү милли композиторларыбыз иҗатын популярлаштыруда зур роль уйный. Аларны сәхнәдә башкаручыларның осталыгы камилләшә, алар вокалга, пластикага, хореографиягә бәйле синтетик пландагы актерлар дәрәҗәсенә ия булалар. Опера һәм балет театры труппасының да нигез ташын салучылар шулар арасындагы аеруча талантлы драма артистлары булды.

Шуны да әйтергә кирәк, нәкъ менә К. Тинчуринның Салих Сәйдәшев белән бергәләп куйган «Зәңгәр шәл», «Казан сөлгесе», «Сүнгән йолдызлар» спектакльләре әле бүген дә сәхнә түрендә. Аларда миллилек тә көчле, традицион татар киемнәре, кыю һәм үткен фикерле егетләр-кызлар, мәзәкләр һәм такмазалар, җыр-бию, музыкага бай халык бәйрәмнәре шуларда саклана.

«Зәңгәр шәл» – татар театрының визит карточкасы, үзенә бер кабатланмас спектакль. Әдәби эшләнеше ягыннан кимчелекләре булуга карамастан, ул сәхнәдә һәрвакыт зур уңыш белән бара. 1930 елда ук инде Муса Җәлил «Эшче» газетасында пьесада бернинди социаль көрәш бармавы, Булатның шахтер һөнәренә бәйләнеше юклыгы, пьесаның логик барышы артык озынга китүе хакында язган була. К. Тинчурин иҗатын өйрәнеп тикшерүче театр белгече Р. Игламов та аның фикерләре белән килешә. «Зәңгәр шәл» пьесасын анализлап, ул болай яза: «То обстоятельство, что на фабульном уровне драматург намеренно не прибегает к житейски достоверным оправданиям поступков героя, то есть сознательно идет по пути фрагментарной композиции, вызвано желанием не разочаровывать зрителя, в основе своей являющегося переселенцем из села в город. Если бы пьеса была написана в традициях психологического или даже бытового реализма, где главное условие последовательное, непрерывное и целеустремленное действие и жизненно достоверная природа лепки образа, Булат многое потерял бы в зрительских симпатиях… Ему, зрителю, принципиально не к чему доводы-мотивировки. Достаточно констатации: Булат страдает в разлуке, как позднее, Булат отомстил ишану, спас Майсару. Так что подчеркнутая нарочитость фрагментарного построения пьесы – своеобразный громоотвод, позволяющий поддерживать симпатии зрителя-мигранта к главному герою пьесы» [Игламов, с. 58–59].

Драматург Д. Вәлиев «Зәңгәр шәлнең сере» («Загадка голубой

шали») дигән мәкаләсендә шундый риторик сораулар куя: «И все-таки в чем секрет воздействия этой лубочной, в чем-то наивной мелодрамы? В блестках подлинного народного юмора, рассыпанного повсюду? В неповторимых сайдашевских мелодиях, ставших органичной, неотъемлемой частью спектакля и идущих, словно из глубин народного духа? В татарских народных танцах, которых так много в спектакле и которые, как и песни пробуждают в нас какие-то полузабытые картины детства, юности, будят сокровенные чувства, как чувства родины, своей земли?» [Валеев, 1970].

Сәнгать фәннәре докторы А. Анастасьев исә бу әсәр хакында болай дип яза: «У прочного успеха “Голубой шали” особая природа: перед зрителем возник родной театр в его детско-наивном выражении, песенно-обрядовые сцены ассоциировались, быть может, и с уходящими в прошлое, но близкими образами, заключенными в слово “Сабантуй”. При этом надо помнить, под грубо театральной оболочкой спектакля явственна мысль о свободе человека и резкая сатира на то, что и ныне заслуживает обличения» [Анастасьев, с. 89].

Минемчә, К. Тинчуринның музыкаль комедияләре «балаларчасамими чагылышы» белән әлегә кадәр режиссерлар игътибарыннан төшмидер. Кәрим Тинчурин үзенең пьесаларын сәхнәгә чыгарырга әзерләгәндә, автор буларак, аларга мюзикл элементлары да өсти, һәм шуның өчен партиячел караштагы вульгар тәнкыйтькә дучар ителә. Әмма совет театрының алга таба үсеше К. Тинчурин тарафыннан сайланган юнәлешнең өметле киләчәген раслый. Мюзикл, бүгенге сәхнә эшчәнлегендә иң демократик, зур осталык таләп иткән жанр буларак үзенең ныклы урынын алды. Шунысын дә әйтеп үтү урынлы булыр: К. Тинчуринның музыкаль сәхнә әсәрләре, җиңелчә яңгырашына, тирән фикерләр уятмавына, тамашачанлыгына карамастан, күңел ачуга гына хезмәт итмәде. Аларда кешене билгеле бер гамәлләргә өндәү-чакыру да көчле иде. Р. Игламов билгеләп үткәнчә: «Здесь нужно помнить не только о законных требованиях зрительской массы, которая хочет видеть в произведении свои взгляды, представления и чувства…, но, прежде всего, о стремлении автора идейно-художественно воздействовать на массу…» [Игламов, с. 53]. К. Тинчурин бу уңайдан туган фикерләрен 1923 елда «Татарстан» (хәзерге «Ватаным Татарстан») газетасында язып та чыга. Лозунглар, революцион сүзләр белән генә язылып, шәхси характерларны ачудан бөтенләй читтә булган әсәрләрне пролетар пьеса дип булмавын, киресенчә, авыллардагы искелек, хосусыйлык гадәтеннән арына алмаган затларны көлке хәлдә калдырып язылганнарны пролетар пьеса диярргә яравын ассызыклый.

Чыннан да, К. Тинчуринның ярым әкияти рухтагы сюжетка салынган музыкаль драмалары зур агитацион көчкә ия. Драматургның билгеле бер чорны тасвирлаган тарихи әсәрләрен

(«Җилкәнсезләр» яки «Кандыр буе») яңалык белән сугарылган дип бәяләсәк, музыкаль драмаларының инде иске дөньяны кире каккан гыйсьянчылык идеясенә нигезләнгәнен күрәбез.

К. Тинчуринның үз әсәрләрен театрда эшләү дәверендә язуы аның сәхнәви зәвыгына зур йогынты ясый. Алар аның күңелендә кайсы рольне кем уйнаячагын күзаллап, актерлык импровизациясе нәтиҗәсендә «өлгерәләр». Актер һәм режиссер К. Тинчурин үзенең пьесаларына спектакльне сәхнәләштерү барышында үзгәрешләр кертә торган була. Шуңа күрә дә аның әсәрләре үзенең заманчалыгы, җанлылыгы, җиңел кабул ителүе белән аерылып тора. Һәм, тагын шунысы мөһим, бу үзенчәлек авторның стилитик трансформацияләү сәләтен, аның пьесаларының сәхнәдә өр-яңа гәүдәләнеш алуын да дәлилләли. Драматург сәхнә формасы мәсьәләләренә дә зур игътибар бирә. К. Тинчурин үзе бу хакта «Татарстан» газетасында язып чыккан мәкаләсендә, тормыш бездән күңел кичерешләрендә дә, шәхси эшләребездә дә, көрәштә дә… хәрәкәт, тизлек таләп итә, дип яза. Шулай ук автор күчмә татар театрының кыска гына вакыт эчендә тамашачыга бай эчтәлекле, кызыклы һәм тормышның кайсы да өлкәсе буенча файдалы үрнәк булырдай спектакльләр күрсәтергә тиешлегенә басым ясый. Шул ук мәкаләсендә ул укучыга сәхнә бизәлешенә булган таләпләрен дә җиткерә. Аның заман таләбенә, тамашачы ихтыяҗына җавап булып яңгыраган бу фикерләре әле бүген дә актуальлеген югалтмый. К. Тинчурин бик хаклы рәвештә милли драматургларыбыз арасыннан иң югары дәрәҗәдәге сәхнә әсәрләре иҗат итүче, театр үзенчәлекләрен, тамашачы күңелен тирәнтен аңлый билүче буларак бәяләнә.

**Әдәбият**

*Анастасьев А.* На 45 языках. М., 1972.

*Валеев Д.* Загадка голубой шали // Советская Татария, 1970, 20 окт.

*Игламов Р.* Выдающийся драматург. Казань, 1987.

*Тинчурин К.* Татар театры нинди юл белән барырга тиеш // Татарстан, 1923.

*Тинчурин К.* Хәзерге театрның рәвешен-формасын үзгәртергә кирәк // Татарстан, 1923.

***Салихова Айгөл Рөстәм кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының театр һәм музыка бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

УДК 821.512.145-2:792.09

***Р.Ф. Фәйзерахманов,***
***А.Г. Әхмәтгалиева,***
***В.Ф. Макарова***

# КӘРИМ ТИНЧУРИН ӘСӘРЛӘРЕНЕҢ СӘХНӘ ЯЗМЫШЫ

В статье рассматривается история постановок пьес Карима Тинчурина на татарской сцене начиная с 1920-х годов и до наших дней. Названы режиссеры, актеры постановок, авторы музыкального сопровождения. Основанное внимание уделено выяснению причин такой популярности произведений К. Тинчурина как среди профессионального театрального сообщества, так и среди зрителей.

**Ключевые слова:** Карим Тинчурин, татарская драматургия, татарский театр, музыкальная комедия.

Татар театрын, аның тарихын, үсешен һәм репертуарын Кәрим Тинчурин исеменнән башка күз алдына да китереп булмый. Бу шәхеснең актер буларак та, режиссер һәм шул ук вакытта драматург буларак та эшчәнлеге бәяләп бетергесез. Шәкерт булып мәдрәсәдә укыган чорда – 1906 елда ук «Моназарә» исемле беренче сәхнә әсәрен язган Тинчуринның пьесалары Октябрь инкыйлабы алдыннан сәхнәгә куела башлый. Бу чорда Кәрим Тинчурин – «Сәйяр» труппасы артисты, берничә әсәр язган драматург, үз пьесаларын сәхнәгә куярга алынган режиссер булып җитлегә. Аның үз заманы татар тормышының яңарыш процессын күрсәткән, искергән тәртипләрне тәнкыйть иткән «Хәләл кәсеп» (1910), «Шомлы адым» (1910–1912), «Беренче чәчәкләр» (1913), «Назлы кияү» (1915), «Ач гашыйк» (1915), «Җилкуарлар» (1916), «Соңгы сәлам» (1917) кебек әсәрләре XX йөз башы татар әдәбиятының кыйммәтле хәзинәсен тәшкил итәләр. Беренче әсәрләре белән үк язучы драма төрен камилләштерүгә, баетуга, үзгәртүгә үзеннән зур өлеш кертә [Әдипләребез, б. 432, б. 433].

1917 елда язылган «Соңгы сәлам» драмасында Вахитны – К. Тинчурин, Олечканы – Ф. Ильская, Раузаны – Г. Болгарская, Мөхәммәтшаны – Г. Кариев, Сираҗины – Г. Мангушев уйный. Әсәрнең 1921 елда Семипалатинск татар театрында да куелуы мәгълүм [Арсланов].

Әлеге әсәрләрдән соң күп тә үтми, 1917 елның 25 августында Тинчуринның «Ятлар» драмасы да тамашачы хозурына барып ирешә.

Бу драма 1917 елның 8 сентябрендә «Сәйяр» труппасы тарафыннан уйнала. Әлеге спектакльдә Хәмит ролен – Тинчурин үзе, Кыямны – Г. Кариев, Сараны – Ф. Ильская башкара. Бу драма шактый бәхетле язмышка ия була, төрле елларда, төрле театрларда кат-кат сәхнәләштерелә. Әйтик, 1920 елда Оренбургтагы

татар театры куйган спектакльдә Хәмит ролендә – Ә. Мәҗитов, Сара – Ф. Тарханова, Кыямны – М. Әпсәләмов уйнаганы билгеле. 1934 елда драманы Академия театрында режиссер Риза Ишморат сәхнәләштерә. Тик бу куелышта, заман таләп иткәнчә, пьесага байтак кына үзгәрешләр дә кертелә. Чөнки инкыйлаби карашлар да шуны таләп итә (Хәмитне – Камал III, Хәйдәрне – Г. Зыятдинов, Хәкимҗанны – З. Солтанов уйный). Шушы ук Академия театры сәхнәсендә 1959 елда режиссер Г. Йосыпов тарафыннан драма кабат яңартылып куела. Хәмит ролендә – И. Гафуров, Сараны – Г. Ибраһимова, Кыямны – Ф. Халитов, Хәкимҗанны – Г. Зыятдинов уйный.

«Назлы кияү» спектакленең дә язмышы кызыклы. Ул 1916 елда ук язылса да, инкыйлабтан соң, 1918 елның 12 гыйнварында гына дөнья күрә. Бу комедиядә К. Тинчурин зур эшләргә дәгъва итеп тә, аларны тормышка ашырырлык белеме-әзерлеге булмаган яшьләр образларын мәйданга чыгара, аларны көлке объекты ясый. Шул рәвешле, К. Тинчуринның XX йөз башы драма әсәрләре милли әдәбиятка яңа геройлар, яңа символлар алып килә. Үзләрен милләтпәрвәрләр дип санаган яшьләр тормышына багышланган «Назлы кияү» комедиясен А. Әхмәдуллин, инкыйлабка кадәрге иң яхшы комедияләрдән, дип бәяли [Ахмадуллин].

Әсәрне Кәрим Тинчурин үзе сәхнәләштерә. Габдулла Кариев белән иңгә-иң куеп эшләгән, режиссурага аннан бик күп нәрсәгә өйрәнгән Тинчуринның да эш алымнары нигездә остазыныкы кебек була. Геройларның теле, кыланмышлары тормышчан булуы белән аерылып тора. Рәшитне автор үзе, Бибине – Ф. Ильская уйный. 2014 елның 3 июнендә «Назлы кияү» комедиясе К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры сәхнәсенә менә. Режиссеры – Рәшит Заһидуллин. Әсәрнең темасы теләсә кайсы чор тамашачысы өчен якын һәм таныш булганга, арада еллар киртәсе тормый. Яшь, әмма буйдак Рәшитнең өйләнергә йөрү хәбәрен ишеткәч, бай кияүгә кәләш сайлап, аны башлы-күзле итәргә теләүчеләр саны шундук күбәеп китә. Һәм «яңа дусларның» мәкерле планы инде тормышка ашам дигәндә генә, бер көтелмәгән сәбәп аркасында, бар да чәлпәрәмә килә. Әлеге явыз ниятләргә каршы торучы төп көч – ул чын мәхәббәт... Әлбәттә, бүгенге заман таләп иткәнчә, комедиягә байтак үзгәрешләр кертелә, ул яңартыла, баетыла. Композитор М. Имашев, шагыйрә Г. Зәйнашева хезмәте нәтиҗәсендә, мавыктыргыч водевильгә әверелә.

Рольләрне дә егерме беренче гасыр артистлары башкара: Рәшит – Б. Зиннәтуллин, И. Байназаров; Гөлбану – З. Хәкимҗанова, Нәгыймә – Җ. Әсфәндиярова, Рамазан – З. Закиров, Гайни – Р. Сәлахова, Җиһан – Г. Гарәпшина, Шәмси – М. Нәҗмиева, Ильяс – А. Пискунов, Сабир – И. Хафизов, Зөһрә – Г. Галиуллина, Биби – К. Галиева.

Әсәрләрнең язылу, сәхнәдә куелу тәртибенә кабат әйләнеп кайтсак, 1918 елда К. Тинчурин

«Һиҗрәт» исемле хикәясен яза, шуны ук «Тутый кош» исемле комедия итеп эшли. Әсәрдә Казаннан акларны куып чыгару, инкыйлабка каршылар арасында буталыш, аларның хурлыклы рәвештә көнчыгышка качулары – «һиҗрәткә сәфәр кылу»лары сурәтләнә. Катнашучыларның азлыгы, комедиянең җыйнак күләмле булуы, заманның актуаль сорауларын чагылдыруы – әлеге спектакльне шул чорда төрле сәхнәләрдә уйнарга мөмкинлек бирә.

«Йосыф-Зөләйха» комедиясе дә революция чорын чагылдырган сатирик сәхнә әсәре буларак үзенчәлекле. Ул 1918 елда язылып, шул ук елны «Сәйяр» труппасы тарафыннан сәхнәгә дә куела. Булдыксыз Сәфәргалине – К. Тинчурин, бай карчык Фәизәбикәне – Н. Арапова уйный. 1961 елда Академия театрында бу спектакльне режиссер Г. Йосыпов сәхнәләштерә, Сәфәргалине – И. Гафуров. Фәизәбикәне – Ф. Камалова уйный.

«Сакла, шартламасын!» комедиясе дә 1918 елда язылган, 1919 елда сәхнәгә куелган. Шакирҗан байны – Г. Кариев, приставны – Х. Колмәмәт уйный. Бу комедия 1928 елда Әстерхан халык театрында да куела. 1958 елда исә Татар күчмә театр сәхнәсенә дә менә. Аны режиссер К. Тумашева куя. Спектакльдә С. Мөхәряпов, Г. Гыйматов, Г. Нуруллин, Ф. Фарсин кебек артистлар катнаша.

Бу әсәр бүгенге көн тамашачысы өчен дә актуаль яңгырый. Әсәрдә төп образ – бозык күңелле бай улы. Ул, үзе шикелле дуслары белән бергәләп, бер татар баен таларга план корып йөри. Егетнең максаты – байны талап акчасын алу, ә аннан әлеге җинаятьтә яшь язучы егетне гаепләп калдыру. Әмма бай малаеның уйлары тормышка ашмый кала. Тинчуринның барлык әсәрләрендәгечә, яхшылык явызлыкны җиңеп чыга. Җинаятьче үз җәзасын ала. Спектакль җиңел карала. Чөнки әлеге әсәрдә мәхәббәт тә, җыр-бию дә, юмор да – барысы да бар. 2009 елның 26 октябрендә Кәрим Тинчурин театры сәхнәсендә комедиянең премьерасы дә була, аны режиссер Р. Заһидуллин сәхнәләштерә. Рольләрне З. Харисов, А. Фәтхуллин, З. Вәлиева, И. Хафизов, Г. Гайнуллина, Р. Гайзуллин һ.б. артистлар башкара.

Бүгенге көндә дә тамашачыны җәлеп итеп торган «Казан сөлгесе» – Тинчуринның беренче музыкаль әсәре. Ул 1922 елда языла, бик күп сәхнәләрдә уйнала. Әстерхан театрында, Татар дәүләт театрында гөрләп бара, анда беренче башкаручылар арасында Б. Тарханов, Р. Кушловская, С. Айдаров кебек талантлы артистлар уйный. Спектакльгә музыканы Салих Сәйдәшев иҗат итә. 1958 елда Академия театры сәхнәсендә комедия режиссер Р. Тумашев куелышында өр-яңа сулыш ала, анда мөәзинне – К. Бариев, Г. Шамуков, Саҗидәне – В. Минкина, Мөршидәне – Р. Хәйретдинова, Ильясны – И. Гафуров уйный.

Байтак вакыт узгач, безнең чорда, төгәлрәк итеп әйткәндә, 2003 елның 4 октябрендә «Казан сөлгесе» Г. Камал исемендә-

ге татар дәүләт академия театры сәхнәсенә янә менә. Аңа кадәр бу әсәр М. Сәлимҗанов тарафыннан сәхнәләштерелгән була инде. Ф. Бикчәнтәев куелышындагы музыкаль комедия заманча төсмерләр белән баетыла. Спектакльнең асылына бераз тукталып үтү урынлы булыр. Мөәзиннең ике кызы авылда чибәрлекләре белән дан тота. Казаннан туйга килгән яшь шәкертләрнең кызларны бик күрәселәре килә. Һәм Ильяс шәкертне, көтүче итеп киендереп, мөәзин йортына озаталар. Әлбәттә инде, ике кыз да телгә оста, тапкыр бу егеткә гашыйк булалар. Яшьләрнең мәхәббәт маҗаралары турындагы бу спектакль мюзикл жанрында сәхнәләштерелгән. Сәйдәш музыкасы, заманча хореография, «тере оркестр», зәвыклы сәхнә бизәлеше тамашачыны бик тиз үз дулкынына ияртә, аның игътибарын яулый. И. Әхмәтҗанов, И. Баһманов, Н. Гәрәева, Д. Нуруллина, И. Хәйруллин, Р. Бариев, Л. Рәхимова, А. Каюмова һәм башка бик күп талантлы артистларның уены тамашаны тагын да җанландырып җибәрә.

К. Тинчуринның оста һәм сатирик теленә корылган иң яхшы пьесаларының берсе булган «Американ» 1923 елда языла, шул ук елны сәхнәдә дә куела. Ул чагында төп герой Искәндәр ролен автор үзе башкара. Әсәр М. Сәлимҗанов куелышында Г. Камал театры сәхнәсендә дә уйнала. 1993 елда әлеге спектакль режиссер Фаил Ибраһимов тарафыннан Чаллы татар дәүләт драма театры сәхнәсенә күтәрелә. Бу комедия 2009 елда Р. Заһидуллин куелышында Кәрим Тинчурин театры сәхнәсендә премьера буларак тәкъдим ителә. Тарихи кыйммәткә ия кульязмаларга хуҗа булу өчен үзен Америка тарихчысы дип тәкъдим иткән, хәйләгә һәм ялганга оста яшь кеше образы тамашачыларны көлдереп, күңелләрен күтәрә. Рольләрне театрның әйдәп баручы артистлары Р. Гайзуллин, А. Фәтхуллин, З. Харисов, Р. Сәлахова, Р. Төхвәтуллина һәм башкалар гәүдәләндерә.

Тинчуринның иң көчле драмаларыннан саналган «Сүнгән йолдызлар» әсәренең дә язмышын бәхетле дип атарга мөмкин. Ул да 1923 елда языла, шул ук елны Татар дәүләт театрында сәхнәгә куелган. Надирны – К. Тинчурин, Исмәгыйльне – С. Айдаров, Сәрвәрне – Р. Кушловская (соңрак Г. Кайбицкая) башкара.

Мәхәббәт өчпочмагына корылган әсәр Беренче бөтендөнья сугышы, аның кеше язмышларын җимерүе хакындагы фәлсәфәгә нигезләнгән. Драматург аны төш күрү алымын кулланып тасвирлый.

Исмәгыйль өч тапкыр күргән төш – аждаһаның берәм-берәм йолдызларны сүндерүе – символик янәшәлек тудыра. Кешеләр арасындагы аңлашылмаучылык аерым берәүләр бәхетен җимерә ала, ләкин аны үз бәхетең өчен көрәшеп хәл итәргә мөмкин. Бу фикер мәхәббәт төене мисалында күрсәтелә.

Сугыш һичкемнең дә теләкомтылышын аямый: ул, гомумән, халыкны, илне бәхетсезлеккә төшерә. Сәрвәрнең, Исмәгыйльнең, Надирның үлемендә

язучы, ахыр чиктә, нәкъ менә сугышны гаепли.

Надир – татар драматургиясендә яңа, фаҗигале герой. Хәтта сугыш башлану хәбәре дә аңа мәхәббәт китерер кебек тоела. Исмәгыйль сугыштан калу өчен, колагына дару салдырып үлгәч, Сәрвәр акылыннан яза. Надир шушы хәлдәге Сәрвәр белән аралашуны бәхет саный. Биредә «ялгызлык үлемгә тиң категория итеп карала. Җәмгыятьнең кимчелекле кешеләрне кабул итмәве, читкә тибәрүе, аларның ялгыз калып усаллануы, аралашырга бөтенләй беркем булмаганда, үлемгә атлавы тормыш кануны төсен ала. Шуның белән янәшә, кешеләрнең үз бәхете өчен көрәшүен мөмкин дип санаган килеш, язучы сугыш яки язмыш кебек зуррак көчләрнең бу бәхетне җимерүен ассызыклый» [Заһидуллина, б. 181]. Әсәр геройларыннан «Надир мәхдүм кебек гаять киеренке тетрәнүләргә, көчле психологик кичерешләргә ия герой татар драматургиясендә юк иде әле. Бу, һичшиксез, Тинчуринның зур табышы, театр сәнгатенә керткән зур яңалыгы иде», – дип яза Ф. Бәширов [Бәширов, б. 11].

1998 елда бу пьесаны Чаллы татар драма театры сәхнәсендә режиссер Р. Әюпов «Йолдызлар сүнсә ни була?» дигән исем астында тамашачыга тәкъдим итә. Әсәрне романтик югарылыкка күтәрү ниятеннән, пьесага көтелмәгән ситуацияләр өстәлә, яңа һәм иске чор геройларын параллель планда уйный. Сәрвәр һәм Исмәгыйль образларын гәүдәләндерүдә режиссер үзенчәлекле алымнар куллана. Ә Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры сәхнәсендә спектакль М.Сәлимҗанов тарафыннан куела [http://kamalteatr.ru/].

Бу музыкаль трагедиянең 2013 елның 12 апрелендә Кәрим Тинчурин театрында Р. Гарипова тарафыннан да яңартылып куелуына гаҗәпләнергә кирәкми. Безгә – ягъни, XXI гасырның эре шәһәрләрендә көн итүчеләр өчен – XX йөз башы татар авылы яшәешенә хас булган көндәлек тормыш, гореф-гадәтләр, җыр һәм биюләр күптән инде үткәндә калды кебек. Кичә генә гадәти булган әйберләр бүген безгә ят кебек. Ләкин, «Сүнгән йолдызлар» спектаклендә һәркем чын, әмма гадәти булмаган мәхәббәтне күрә ала. Әлеге спектакль татар халкының көнкүреше, сугыш, кайгы һәм шатлык турында. Бу куелышта Сәрвәрне – Р. Сәлахова, Исмәгыйльне – Б. Зиннәтуллин, Надирны – З. Закиров кебек яшь, талантлы артистлар уйный.

Н. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе студентларының музыкаль төркем булып чыгыш ясаулары спектакльне тагын да тулы канлы итә.

Драматургның шулай ук иң көчле әсәрләреннән саналырга хаклы «Җилкәнсезләр» комедиясенә тукталыйк. Ул 1926 елда Октябрьнең тугыз еллыгын бәйрәм иткән көннәрдә Татар дәүләт академия театрында куела. Спектакльнең режиссеры да, төп рольне (Батырханны) уйнаучы да Тинчурин үзе була. Шулай ук З. Солтанов, Н. Сакаев, Н. Арапова, Ф. Ильская, Ш. Шамильский кебек шул чорның күренекле артистлары да сәхнә тота.

Камал театрында ул 1958 елда да куела. Сиксәненче елларда Әлмәт театрында да зур уңыш белән бара. 1960 ел ахырында Ширияздан Сарымсаков «Җилкәнсезләр»не русчага тәрҗемә итеп, В. Качалов исемендәге Казан зур драма театрында сәхнәләштерә.

Бу спектакль режиссер Р. Абдуллаев куелышында Әлмәт театры сәхнәсендә дә шактый уңышлы уйнала.

«Американ» комедиясендә драматургның комик ситуацияләр кору остасы булуын күрсәк, «Җилкәнсезләр» сәяси-сатирик комедиясе көлке белән фаҗигалелекне үреп бирүе белән үзенчәлекле.

Әсәрнең исеме инкыйлаблар алып килгән яңалыклар фонында үзләренең кыйбласын югалткан төрле катлау кешеләрен символлаштыра, аларның язмышын, көлүдән бигрәк, шәхес фаҗигасе кебек аңлау тоемлана.

Әсәрдә «җилкәнсезлек» – рухи кыйбла булмау татар югары катлавының төп сыйфаты итеп күрсәтелә. Әсәрнең кыйммәте дә заманга, андагы сәяси каршылыкларга колачлы бәя бирүе белән билгеләнә.

2016 елның 8 октябрендә «Җилкәнсезләр» кабат Камал театры сәхнәсен яулады. Әсәр бу сәхнәгә өченче мәртәбә күтәрелә, соңгысында ул тамашачыга Омск драма театры режиссеры Г. Цхвирава куелышында тәкъдим ителә. «Җилкәнсезләр» сатирик комедиясе инде күптән татар классикасы җәүһәрләре исемлегендә. Әсәр 1917 елның инкыйлабына кадәрге һәм аннан соңгы татар тормышын сурәтли. Азатлыкка, иркенлеккә омтылган татар тарихы башка милләт режиссерында да кызыксыну уята. Г. Цхвирава бу әсәрне үзе сайлый. «Спектакль татарлар өчен кызыклы, хәзерге заманда бигрәк тә. “Совет халкы” дигән милләт юк. Татар, чуваш, мари бар. Татарларга үз милли идеяләре мөһим. Тинчурин әсәрендә 1917 елны тасвирлый. Ул елда ил, дөнья, аның белән күп кенә милләтләр, шул исәптән татар милләтенең дә асты өскә килә. Пьесаны алырга дип миңа беркем дә тәкъдим итмәде. Минем Казан белән бәйләнешем бар, монда эшләгән идем, шуңа күрә татар драматургиясе белән таныш. Татар классикасы белән эшләргә теләгән идем һәм җай да чыкты. Бүгенге көндә тарихка борылып, киләчәк сорауларына җавап эзләргә кирәк», – дип сөйли «Җилкәнсезләр» режиссёры Г. Цхвирава үзенең «Азатлык» радиосына биргән интервьюсында [https://www.azatliq.org/].

1930 еллар урталарыннан К. Тинчуринның иҗат эшчәнлегендә төп урынны музыкаль драмалар били, һәм бу жанрда әдип аеруча зур уңышларга ирешә. Аның «Зәңгәр шәл» (1926), «Ил» (1927), «Кандыр буе» (1930) исемле мелодрамалары шул чор татар театрының төп репертуарына әверелә, аннан соң да кабат-кабат уйналып, ничәмә-ничә буын тамашачыларның тирән мәхәббәтен казана.

Әсәрләрнең сюжеты катлаулы түгел. Әйтик, «Казан сөлгесе»ндә яшь шәкерт Ильяснең мәхәббәт маҗаралары тас-

вирлана. «Зәңгәр шәл»дә Булат сөйгәне Мәйсәрәне ишан хәзрәт тоткынлыгыннан коткара. Бу инкыйлабка кадәрге татар җәмгыяте өчен гадәти вакыйгалар язучыга милли көнкүрешне мифлаштырырга, аны матурлык үрнәге буларак бәяләргә мөмкинлек бирә. Яшьләрнең саф мәхәббәт хисләре, милли җыр-уеннар, гадәт-йолаларны тасвирлау, аларның матур һәм самими характерда бирелеше, вакыйгалар эчендә үзара ярдәмләшү атмосферасы тудыру, яшьләрнең иске канун-кагыйдәләрне урап үтү җаен табуларын оста итеп сурәтләү әсәрләрне кызыклы һәм мавыктыргыч ясый. Ф. Бәширов фикеренчә, «халык җырларын, йолаларын, уен-биюләрен мул куллану бу әсәрләрне гомерле итә» [Бәширов, б. 11]. Д. Заһидуллина фикеренчә, шунысы да әһәмиятле: алар әдәбиятта үткәнне каралтып күрсәтү, аны тоташ караңгылыктан торган сәхифәләр рәвешендә тасвирлау тенденциясе активлашкан бер вакытта сәхнәгә чыга һәм элекке татар тормышына уңай караш тудырулары, татар романтик әдәбияты традицияләрен дәвам итүләре белән гомум әдәби барышта аерым урын тоталар [Заһидуллина, б. 182].

«Зәңгәр шәл» – Тинчурин драматургиясендә үзгә бер урын биләп торган әсәр. Ул беренче тапкыр татар театры сәхнәсенә 1926 елның 20 декабрендә күтәрелә. Әсәрне автор үзе куя, Булатны да үзе башкара. Мәйсәрәне – Р. Кушловская, ишанны – З. Солтанов уйный, шулай ук Н. Арапова, Ш. Шамильский, Х. Уразиков, Х. Сәлимҗанов кебек осталар катнаша. Шул ук чорда спектакль Мәскәү, Оренбург, Әстерхан театрларында куела. 1929 елда Академия театрында куелган вариантның режиссеры – В. Вәлиев-Сульва була, Булатны С. Айдаров башкара. Спектакльнең бу сәхнәдә өченче куелышы 1956 елда була, режиссеры – Ш. Сарымсаков. Булат белән Мәйсәрәне А. Аббасов һәм Р. Бәхтиева башкара. 1956 елда «Зәңгәр шәл» Минзәлә театрында да куела. 1970 елда М. Сәлимҗанов әлеге әсәрне Г. Камал театры сәхнәсенә яңа сулыш белән кайтара. Мәйсәрәне Ф. Хәмитова, Булатны А. Аббасов, М. Имашев (соңыннан Н. Әюпов), ишанны Ш. Биктимеров башкара. Ф. Бикчәнтәев куйган «Зәңгәр шәл» – тагын да тулы канлы булуы, яңа буын артистлар уйнавы белән үзенчәлекле. Әлеге спектакль күптән татар театрының символына һәм Камал театрының «визит карточкасына» әверелде. Тамашачыларның ташкыны кимеми, ә пьеса инде күптән легендар спектакль статусын алды.

«Зәңгәр шәл» – Г. Йосыпов режиссер булып эшләгән елларда Әлмәт театры сәхнәсендә дә уйнала.

К. Тинчуринның сәхнәдә уйналу бәхете тигән тагын берничә әсәренә тукталыйк. «Ил» драмасы 1927 елда языла, Тинчурин аны Әстерхан татар театрында эшләгән чагында үзе сәхнәгә куя. Рольләрне Х. Уразиков, Н. Арапова, Г. Булатова кебек артистлар башкара. 1929 елда драманы Академия театрында З. Солтанов куя, музыканы С. Сәйдәшев яза.

Бу спектакль Академия театрында 1932 елда яңартылып, яңа музыкага баетылып куела.

1928 елда язылган «Хикмәтле доклад» комедиясенең 1930 елда Академия театрында куелуы билгеле. Мортаза ролендә К. Тинчурин үзе уйнаган [http:// tinchurinteatr.ru/].

1940 елларда К. Тинчурин совет чынбарлыгын чагылдырган «Корыч орчык» (1930), «Кандыр буе» (1931), «Ударниклар бәйрәме» (1933), «Алар өчәү иде» (1935) кебек пьесаларын иҗат итә. Искелек һәм яңалык көрәшенә корылган әсәрләр заман алып килгән яңалыкларны, кешеләрнең аларга мөнәсәбәтен бәяләргә омтылып язылган. Әйтик, «Кандыр буе»нда егермебишмеңче коммунист Акбирдинның, «Кызыл йолдыз» колхозына рәис булып килеп, авыл кешеләре тормышын яхшыртуга юнәлтелгән эш-гамәлләре яктыртыла.

«Кандыр буе» – 1931 елда язылган, колхозлашу чорын сурәтләгән музыкаль әсәр. Аңа да көйне С.Сәйдәшев яза. Спектакль Академия театрында Тинчуринның үзе тарафыннан куела, рольләрне Х. Әбҗәлилов, С. Садыйкова, Х. Уразиков, М. Мутин, Г. Кайбицкая кебек талантлы артистлар башкара.

«Алар өчәү иде» комедиясе 1935 елда Татарстанның 15 еллыгына багышлап языла, шул ук елның язында Р. Ишморат тарафыннан Академия театры сәхнәсендә куела. Анда төп рольләрдә Ф. Ильская, Ш. Шамильский, Х. Сәлимҗанов кебек сәхнә осталары уйный. Әсәр 1935 елда Әстерхан театрында да уйнала.

Кәрим Тинчуринның әдәби мирасы бай. Драматургның XX йөз башында иҗат ителгән беренче драма әсәрләре үзгәрешләр чорындагы татар яшьләренең төрле катлау-төркемнәре тормышын, аларның рухи дөньяларын тасвирлый һәм шушы материалны символлар, укучы уйлап бетерәсе мотивларга юл күрсәтерлек ачкыч-сүзләр ярдәмендә гомумкешелек проблемалары дәрәҗәсенә куеп, зур гомумиләштерүләр ясый. Бу әсәрләр татар әдәбияты өчен яңа сурәтләү мәйданнары ача, прозада актив кулланыла башлаган эчтәлекне тирәнәйтү алымнарын драма төренә алып килә, шул рәвешле татар драмасының яңа баскычка күтәрелүен тәэмин итә. Инкыйлабтан соң, татар сәхнә әдәбияты шактый саеккан, примитивлашкан бер вакытта, драматург К. Тинчурин үз иҗатында шушы традицияләрне саклап кала, үстерә, аларны чор таләп иткән эчтәлек, халык мәзәкләре белән бәйләп бирүгә ирешә. Драматургның «Сүнгән йолдызлар», «Американ», «Казан сөлгесе», «Зәңгәр шәл» кебек әсәрләре татар сәхнә әдәбиятының инкыйлабка кадәр ирешкән биеклеген, дәрәҗәсен саклап калуга, аны тагын да үстерүгә хезмәт итә, милли сәнгатьнең классикасына әверелә. Аларның популярлыгына тукталып, Н. Ханзафаров болай яза: «К.Тинчурин азат халык рухи халәтен заман динамикасына якын яңа сәнгатьчә алымнарда чагылдыруы белән чын новатор булды» [Ханзафаров, с. 65].

Иҗат көче әле ташып торган Кәрим Тинчурин 1937 елның

17 сентябрендә кулга алына. Халык дошманы буларак гаепләнеп, 1938 елның 15 ноябрендә атып үтерелә. 1955 елның 14 октябрендә реабилитацияләнә.

1937 елның 17 сентябрь төнендә НКВД кешеләре килеп, әдипне кулга алалар һәм Казандагы Пләтән төрмәсенә илтеп ябалар. Ел да ике ай чамасы дәвам иткән «махсус тикшерүләр» нәтиҗәсендә К. Тинчуринга җиде пункттан торган гаепләү акты игълан ителә. Ул пунктлар арасында «буржуаз милләтчеләр оешмасында әгъза булып тору», чит илдә яшәгән һәм «советның явыз дошманы» булган Гаяз Исхакый белән элемтә урнаштыру, Япония файдасына шпионлык итү кебек кеше ышанмаслык уйдырмалар да бар. Төрмәдә кыйнау, мәсхәрә ителүләрдән тәмам саулыгын югалткан әдип бу нахак гаепләрнең берсен дә танымый әлбәттә. Шуңа карамастан, 1938 елның 14 ноябрендә җыелган өч кешелек Махсус киңәшмә (ОСО) К. Тинчуринны атарга дигән хөкем карары чыгара. Шул хөкем карары нигезендә 15 ноябрь төнендә, бер сәгать илле минутта әдипнең гомере өзелә. Бу вакытта аңа нибары илле бер яшь тулган була. К. Тинчуринның китаплары китапханә фондларыннан җыеп алына, яндырыла, юк ителә. Фәкать Сталин культы фаш ителеп, илдә берникадәр хөрлек, демократик тәртипләр урнаша башлагач кына, нахакка репрессияләнгән бик күп әдәбият-сәнгать әһелләре белән беррәттән, Кәрим Тинчуринның да абруйлы исеме һәм әдәби мирасы халыкка кире кайтарыла, пьесалары яңадан театр сәхнәләрендә куела башлый [http://tataredebiyate.ru/biography/170/].

Шунысы кызык: авторның вафатыннан соң да аның кульъязмалары, сәхнәгә менәргә өлгермәгән пьесалары табыла тора һәм яңа сулыш белән яши башлый. 2016 елның 17 ноябренда Минзәлә театры сәхнәсендә К.Тинчуринның шундый әсәрләренең берсе булган «Каракүз» музыкаль драмасы күрсәтелде (пьесаның кульъязмасы Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә саклана. 2015 елда Милли китапханә Кәрим Тинчуринның ике әсәрен – «Каракүз» һәм «Нәни абый» әсәрләрен аерым китап итеп бастырып чыгара; әсәрләрнең кульъязмаларын өйрәнүче, гарәп язуыннан гамәлдәге татар язуына күчерүче, җентекле фәнни мәкалә, аңлатмалар һәм искәрмәләр белән нәшриятка әзерләүче – Милли китапханәнең гыйльми хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты, археограф һәм текстолог Раиф Мәрданов).

«Вакыйгаларның төгәл вакыты һәм урыны ачыкланмый, – ди театр директоры Р. Шәймәрданов. – Анда гади халыктан чыккан кыю биюче кызның падишаһ тарафыннан куелган җитәкчене кулга төшерүе сурәтләнә. Мондагы төп каршылык – ул вакыттагы сыйнфый көрәш». Спектакльнең режиссеры – Әтнә театрының баш режиссеры Р. Фазлыев, композиторы – Э. Галимова, баш рольне Татарстанның халык артисты Р. Муллин башкара, Каракүз ролендә – Минзәлә театры артисткасы

Д. Акматова [http://maydan.tatar/minzele-teatry-kerim-tinchurinnyn-berkajchan-da-sexneleshtermegen-pesasyn-kuya/].

Йомгак ясап әйткәндә, Кәрим Тинчуринның әдәби мирасы, бигрәк тә сәхнә әсәрләре, үзләренең гуманистик идея-эчтәлекләре, тематик киңлеге, тасвирланган чынбарлык күренешләре һәм кеше образларының тормышчанлыгы, тел-стиленең сәнгатьчә камиллеге җәһәтеннән, аларны тудырган вакыт чикләрендә генә йомылып калмыйча, заман үткән саен тагы да тирәнрәк мәгънә төсмере ала баралар һәм сәхнәдә тулы җанлы тормыш белән яшәүләрен дәвам иттерәләр.

## Әдәбият

*Арсланов М.Г.* Татар театры: энциклопедик сүзлек-белешмә. Казан: Заман, 2014. 584 б.

*Ахмадуллин А.Г.* Татарская драматургия: истоки и формирование социалистического реализма. 1983.

Әдипләребез: библиографик белешмәлек: 2 томда. 2 т. / төз. Р.Н. Даутов, Р.Ф. Рахмани. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. 735 б.

*Бәширов Ф.* Ул кабызган утлар мәңге янар // Тинчурин К. Драмалар, комедияләр, хикәяләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2007.

*Заһидуллина Д.Ф.* XX гасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек/ Д.Ф. Заһидуллина, Н.М. Йосыпова. Казан: Казан ун-ты, 2011. 1 нче китап: XX йөзнең беренче яртысында татар әдәбияты.

*Ханзафаров Н.* Драматург-новатор // Традиции и новаторство в творчестве Карима Тинчурина. Казань, 1990.

http://kamalteatr.ru/

https://www.azatliq.org/

http://tinchurinteatr.ru/

http://tataredebiyate.ru/biography/170/

http://maydan.tatar/minzele-teatry-kerim-tinchurinnyn-berkajchan-da-sexneleshtermegen-pesasyn-kuya/

***Фәйзерахманов Рашат Фәесхан улы,***
*Чаллы татар дәүләт драма театры директоры, Россиянең һәм Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре*

***Әхмәтгалиева Айгөл Габдулла кызы,***
*язучы, Татарстан язучылар һәм журналистлар берлеге әгъзасы*

***Макарова Венера Фәйзи кызы,***
*филология фәннәре докторы, Чаллы дәүләт педагогия университеты профессоры*

УДК 782:821.512.145-2

***Э.М. Галимова***

# К. ТИНЧУРИННЫҢ ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ ҮСЕШЕНӘ МУЗЫКАНЫҢ ЙОГЫНТЫСЫ:
## «Каракүз» музыкаль кыйссасы мисалында

Статья раскрывает эстетическую специфику музыкальных драм Карима Тинчурина, в которых главную роль играют музыка и сценическое действие. В татарской музыкальной культуре первый успешный пример соединения музыки и литературного наследия Карима Тинчурина мы видим в творчестве Салиха Сайдашева, который в течение короткого периода создал новую эстетическую систему в искусстве. В данной статье определяются важные тенденции современной режиссуры спектаклей в жанре музыкальной драмы, а также раскрываются практические вопросы, касающиеся создания музыкальной фабулы. На примере музыкальной легенды «Каракуз» в постановке Мензелинского государственного татарского драматического театра им. С. Амутбаева попытаемся определить роль музыки и аспекты её влияния на развитие драматического действия.

**Ключевые слова:** Карим Тинчурин, музыкальная драма, Салих Сайдашев, музыкальная легенда «Каракуз».

Кәрим Тинчурин – татар драматургиясен яңа биекләргә күтәргән олуг әдипләребезнең берсе. Аның иҗаты белән милли драматургиядә саллы бер дәвер башлана. Билгеле ки, аның драматургия, сәхнә сәнгате өлкәсендәге тәүге иҗат тәҗрибәләре XX гасырның унынчы елларыннан ясала башлый. Алга таба әлеге өлкәләрнең мәшһүр шәхесе булып танылу вакыты 1920–1930 елларга туры килә. Ул милли драматургия һәм татар театры сәнгате үсешендә Г. Камал, Г. Кариевлар мәктәбе традицияләренә таянып, шуларны алга таба уңышлы иҗади яктан үстереп алып киткән, шул нигездә үзе дә гаҗәп оригиналь, үзенчәлекле, кабатланмас иҗат әһеле булып танылуы белән билгеле.

Кәрим Тинчурин иҗатын, күпкырлы эшчәнлеген 1920–1930 еллар татар әдәби, мәдәни хәрәкәтеннән аерып карап булмый. Бу елларда әдәбият һәм сәнгать белемендә, театр тәнкыйтендә аның иҗатына мөнәсәбәт алгы планга чыга. Нәтиҗәдә драматургия, театр мәсьәләләре белән бәйләнештә аңа бәя бирү игътибар үзәгендә була. 1934 елда Мәскәүдә Совет язучыларының Беренче бөтенсоюз съездында Кави Нәҗми татар әдәбияты турында доклад белән чыгыш ясый. Чыгыш нигезендә ул Кәрим Тинчурин иҗатының сәнгатьчә оригинальлеген һәм үзенчәлеген билгеләп: «Аның иҗатында зур урынны фольклор – халык җырлары, уеннар, биюләр һәм музыка ала. Тамашачыга ул аны мастерларча күрсәтеп бирә белә», ди. Бу чорда тәнкыйтьчеләр, шул исәптән К. Нәҗми дә, К. Тинчуринның революция сәясәте, социалистик чынбарлык темасына язмавын аның кимчелеге итеп күрсәтәләр,

«иҗатында революция бурычларын аңлауда өстән йөзү» хакында сүз алып баралар. Шулай ук байларны һәм дин әһелләрен тискәре яктан ача белмәүдә гаеплиләр. К. Нәҗми һәм башка тәнкыйтьчеләр татар буржуазиясе һәм интелегенциясенең йөзен бик дөрес күрсәтүче иң уңышлы әсәре итеп, К. Тинчуринның «Җилкәнсезләр» пъесасын саныйлар.

Игътибар итсәк, мелодрама жанры – татар тамашачысы өчен драматургиянең иң сәнгатьчән, сәхнә өчен нык яраклашкан төрләреннән, дип әйтергә кирәк. Мелодрамада сәнгати чаралар, театраль эффектлар тамашачыны тәэсирләндерү өчен махсус кулланылалар. Аның әһәмиятле үзенчәлеге – драма, җыр сәнгате, пантомима, балет һәм сынлы сәнгатьнең һәр төре аерымлыкларын бергә уңышлы тоташтырылуда. Декорация байлыгы һәм аның еш алмашынуы, яктылык эффектларының күп кулланылуы да мелодраманың иң сәнгатьчән төр булуына ишарә. Мелодрамада сөйләмнән тыш (экстралингвистик) чаралар: яктылык, тавыш, музыкаль бизәлеш, пантомима, бию – жанр өчен бик әһәмиятле драматизмны үстереп, көчәйтеп җибәрү өчен кулланыла. Әлбәттә, бу очракта үрнәк буларак без К. Тинчуринның «Зәңгәр шәл» мелодрамасын атый алабыз.

Бүген исә, сезнең игътибарыгызны Кәрим Тинчуриның «Каракүз» мелодрамасына юнәлтәсем килә. Әлеге яңа әсәр яшь режиссёр Рамиль Фазлыев тарафыннан зур үзгәрешләр кичерде һәм, нәтиҗәдә, «музыкаль кыйсса» буларак дөнья күрде. Ни өчен дигәндә, режиссёр фикерен аңлатып үтәсе килә. Әкият яки риваять булсын, мелодрама жанрындагы зур күләмле драматик әсәр булсын, аларда хыялый, һәр яктан камил җәмгыять корырга омтыла торган рухият үзенчәлеге чагылыш таба. Шулай ук фабула ягыннан карасак та, аның төзелешенең ахыры ни белән бетәсе билгеле була һәм сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре ачык күренеп тора. Капма-каршы күренешләрнең киеренкелек тудыру өчен кулланылуы, уңай каһарманның аңа каршы булган явыз каһарман тарафыннан эзәрлекләнүе, корткычлыкның, явызлык-үчлекнең кабатлануы күзәтелә.

Минзәлә татар дәүләт драма театры әлеге әсәрне сәхнәләштерергә уйлагач, әлбәттә, эчтәлекне ачып бирә торган лирик җырлар, такмаклар, төп геройлар башкаруындагы дуэтларга игътибарны юнәлтергә мәҗбүр була. Автор үзе ук әлеге әсәрнең куелышында музыка төп рольне алып торачагын көн кебек ачык белгән дигән фикер туа.

Композитор буларак, Минзәлә татар дәүләт драма театры миңа музыка язырга тәкъдим ясагач, һичшиксез, бу әсәргә зур кызыксынуым барлыкка килде. Әлбәттә, музыка язарга керешкәнче, әлеге жанр кысаларында автор тарафыннан әйтелгән фикерне ачыкларга кирәк. Композитор буларак, музыка теле ярдәме белән син аны дөрес итеп җиткерә белергә тиеш. Гомумән, музыка, ысулларга бай булганга күрә, актёрларга илһамланып уйнарга һәм төрле яктан образны ачарга мөмкинчелек бирә. Нәтиҗәдә, әсәр кысаларында һәр-

бер образга музыкаль характеристика бирү, әлеге фикернең бер дәлиле булып тора. К. Тинчурин композицион фабула кысаларында кайда нинди җыр яки бию булачагын алдан ук күзаллап төзегән. Мелодекламация кулланган урыннары да шактый. Димәк, автор опера яки оперетта либреттосын күздә тотып язган. Билгеле ки, драма артистлары опера кануннарына туры китереп ария, ариозоларны башкарып чыгар өчен зур әзерлек кирәк һәм күп кенә театрларда бу бик сирәк күренеш. Шуңа күрә, музыкаль яктан җыр жанрларын гадиләштерү, әмма бию, мелодекламация урыннарын саклап калу – әсәрне сәхнәләштергән вакытта төп бурычларның берсе булып калды. Нәтиҗәдә, тылсымга ия булган драматик эпизодларның әһәмияте, образларның күп булуы һәм әсәрнең эзлекле эчтәлеге «кыйсса» жанрына бик якын булуын исбатлады.

Әсәрне Минзәлә татар дәүләт драма театры үзенең 80 еллык юбилей уңаеннан яңа премьера буларак тамашачы хозурына 2016 елның 17 ноябрендә зур уңыш белән тәкъдим итте. Нигездә, К. Тинчуринның әлеге әсәре бик озын һәм, гомумән алганда, дүрт сәгатьлек тамаша булырга тиеш икәнлеге ачыкланды. Аны кыскарту һәм тамашачыга эчтәлеген ачу, шулай ук авторның фикерен җиткерү нияте белән режиссёр, яңа образ буларак, ике дәрвиш рольләрен кертә. Чөнки бүгенге көн режиссура башка вакыт кысаларында чагыла. Тамашачы драматургия һәм режиссура ягыннан кертелгән кирәкмәгән тынлык билгеләрен бик тиз сизә. Шул нисбәттән, күп режиссёрлар кыскалык та осталык дигән гыйбәрәдән чыгып эш итәләр.

«Каракүз» музыкаль кыйсса әсәре өчен 28 музыкаль номер иҗат ителде. Кыйссаның төп лейтмотивы итеп – дәрвишләр темасын атар идем. Әлеге тема тамашачыга әсәрнең рухын тоярга һәм алга таба буласы вакыйгаларны сиземләү өчен ярдәм итә.

Әсәрнең эчтәлегенә тукталсак, вакыйга Шәрыкның бер шәһәрендә бара. Хәерче кыз Каракүз зур мәйданнарда һәм сәүдә базарларында җырлап, биеп көн күрә. Җырларында ул халыкның авыр тормышы, замананың чынбарлыгы, дөреслекнең юлын һәм чарасын күрү хакында җырлый.

Тинчурин шулай ук сатира рәвешендә Җанбәк ханның өч хатын белән бимазаланып яшәве, аңа кечкенә генә булса да бәхет хисе бирүче бытбылдыклар ярышлары үткәрүе, Җанбәк ханның сараенда яшь чуриләрнең кол булып яшәүләре, халыкның баш калкытмавы һәм бүген дә сәүдәгәрләр өчен актуаль булган зур салым булуы хакында – көнкүреш проблемаларның берсе турында яза. Җанбәк ханның зур сараен һәм үзенең эчке халәтен тасвирлый торган төп лейттеманы карап узыйк.

Әсәрнең эчтәлеген алга таба дәвам итсәк, Каракүзне очраклы рәвештә күргән Җанбәк хан аңа гашыйк була. Ханнан котылу чарасы итеп, Каракүз аңа әйләнмәле бакча ясарга куша. Шул ук вакытта Каракүз сөйгәне Иделбай белән ханны алдарга юл эзлиләр. Туй буласы көнне Идел-

бай утларны аерырга тиеш була. Халык арасында гауга килеп чыккач, егет кызны күтәреп кача.

Гомумән, тәнкыйтьчеләр тарафыннан К. Тинчуринның драматургиясенә карата әйтелгән фикерләр әлеге әсәрдә ярылып ята. Ә менә Кәрим Тинчуринның драма әсәрләре үсешенә музыканың йогынтысы нинди соң? Һичшиксез, музыка ысуллары бик көчле әһәмияткә ия. Чөнки музыкаль драма жанрын күздә тотсак, драматургия үзенчәлекләре нәкъ менә музыканың сихри көче һәм аһәне аша ачыла дигән нәтиҗәгә килә алабыз.

Каракүз образы 4 лейттема аша ачыла. Беренче лейттеманы без карап үттек инде. «Ардаклы бала» дип исемләнгән икенче лейтмотив Каракүзнең ятимлеге хакында һәм шул вакытта халыкның чиксез авыр тормышын сурәтли. Ләкин Каракүз барыбер күңелен төшерми, җырын шәрык биюе белән дәвам итә һәм нык рухлы кыз икәнен әсәр барышында исбатлый. Өченче лейтмотив Каракүзнең Иделбайга мәхәббәтен чагылдыра торган тема. Музыка ысуллары ярдәмендә ул тылсымга ия булырга тиеш, дип аңлатты режиссёр. Канон һәм полифония серләре ярдәмендә сихри тема «Зынла-зынла» җыры язылды. Дүртенче лейттема Каракүз Җанбәк белән кискен сөйләшүен тәмамлагач мелодекламация буларак яңгырый. Каракүз туры сүзле булуы белән Җанбәкне шаккатыра һәм ачуын чыгара.

Әлбәттә, спектакльнең икенче бүлеге ахырында яңгырый торган Иделбай белән Каракүз башкаруындагы мәхәббәт дуэты – әсәрнең иң төп лирик эпизодларының берсе. Гомумән, спектакльда биюләр, күмәк эпизодлар һәм фон буларак яңгыраган лейттемалар бихисап. Чөнки һәрбер образ һәм эпизод музыка аһәңе аша тамашачы алдында ачыла. Иң уңышлы күмәк эпизодлардан «Чуриләр биюен», «Сәүдәгәрләр биюен» һәм, әлбәттә, Каракүз үзенең образын шәрык биюе аша исбатлавын, әйтеп үтәргә кирәк.

Нәтиҗәдә, К.Тинчурин драма әсәрләрен барлагач һәм шул ук вакытта мәгънәви мотивларын, конфликт, фабула алымнарын, эчтәлек структурасын һәм сәнгатьчәлеген тикшереп карагач, аларның нигезенә театраль яктан көчле тәэсирлелек салынганын аңлыйсын. Минем өчен «Каракүз» әсәренең музыкаль бизәлеше өстендә эшләү зур тәҗрибә булды. Һичшиксез, бөек әдибебез К. Тинчурин драматургиясе бүгенге көндә дә эчтәлеге белән шулкадәр актуаль икәнлеген, әлеге әсәр тагын бер кат исбатлады.

***Галимова Эльмира Мөнир кызы,***
*сәнгать фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының театр һәм музыка бүлеге мөдире*

УДК 821.512.145-2

***Ф.Х. Миңнуллина***

# К. ТИНЧУРИН ДРАМАТУРГИЯСЕНДӘ ШӘХЕС ФАҖИГАСЕ

В статье поднимается вопрос отражения прошлого татарского народа в произведениях К. Тинчурина. Особое внимание уделено изучению драм автора «Сүнгән йолдызлар», «Зар», «Ил», где отражается трагедия человека, на долю которого выпали суровые жизненные испытания.

**Ключевые слова:** драма, судьба татарского народа, конфликт, трагическое, личность.

Кәрим Тинчурин катлаулы, кискен борылыш елларында иҗат итеп, татар совет драматургиясен, театрын үстерүгә зур өлеш керткән каләм иясе. XX гасырның 10 нчы елларында каләм тибрәтә башлап, 30 нчы еллар уртасына кадәр дәвам иткән иҗат юлында ул бай мирас калдырган шәхес. К. Тинчурин, күпкырлы әдәби һәм иҗтимагый эшчәнлек алып барса да, киң җәмәгатьчелеккә, беренче чиратта, татар драматургиясенең иң күренекле вәкиле буларак билгеле. Ул берберартлы «Хәләл кәсеп» (1910), «Шомлы адым» (1912), «Беренче чәчәкләр» (1913), «Назлы кияү» (1915), «Ач гашыйк» (1916), «Җилкуарлар» (1916), «Соңгы сәлам» (1917), «Йосыф белән Зөләйха» (1918), «Сакла, шартламасын!» (1918), «Казан сөлгесе» (1923), «Американ» (1924), «Хикмәтле доклад» (1928), «Сүнгән йолдызлар» (1923), «Зәңгәр шәл» (1926), «Җилкәнсезләр» (1925) «Ил» (1927) пьесаларын әдәбият мәйданына чыгара. Драматург иҗатында илне якты киләчәккә өметләндергән көрәш рухы, халыкның яшәү рәвеше, гореф-гадәтләре, авыл кешесенең өмет-хыяллары чагылыш таба. К. Тинчурин пьесаларында тормышта үз урыныңны табу, халыкка хезмәт итү, искелек белән яңалыкның, өлкән буын белән яшьләрнең, шәхес белән җәмгыятьнең үзара каршылыгы үзәк урынны били. Авторның «Беренче чәчәкләр», «Зар», «Ил», «Соңгы сәлам» әсәрләре заман белән бәйле фикри-әхлакый кыйммәтләр, дөньяга карашлар үзгәрешен, татар кешесенең киң борылышлар чорындагы гыйбрәтле дә, шул ук вакытта фаҗигале дә язмышын тарихи контекстта тергезүе белән үзенчәлекле. Драматург иҗатында даими рәвештә халкыбызның милли язмышы белән бәйле булган актуаль мәсьәләләр күтәрелеп тора. Мәсәлән, «Беренче чәчәкләр» драмасының үзәк герое Хәмит, мәдрәсәдә алган белем, тәрбия белән канәгатьләнмичә, русча укырга алына. Киләчәктә халыкка хезмәт итү теләген тормышка ашыру максаты белән университетка укырга керә, врач булырга тели. Кызганыч ки, укуы өчен түли алмый, шул сәбәп белән уку йортыннан

куылачагын белгәч, авыруы көчәеп, туберкулездан үлә. Гомумән, К. Тинчурин пьесаларында шәхес иреге, социаль тигезсезлек, мәхәббәт һәм бәхеткә хокук, милләт язмышы, үткән тормышның фаҗигале яклары тасвирлана.Татар кешесенең гаять авыр шартлардагы яшәеше, кыерсытылуы алгы планга чыга. М. Арсланов билгеләгәнчә: «Күпкырлы иҗади шәхес буларак, аны иң беренче милли проблемалар, татар кешесенең эше, яшәеше, Руссия җирлегендәге башка милләт вәкилләре белән мөнәсәбәте кызыксындыра» [Арсланов, 2007, б. 9]. Мәсәлән, әдипнең «Соңгы сәлам» (1917) драмасында яшь сәүдәгәр Вахит рус кызы Ольгага гашыйк була. Ольганы сайлау – аның өчен гаиләсеннән китү генә түгел, ә милли яшәешеннән, милләтеннән ваз кичү белән бер. Ләкин герой тормыш иптәшен, авыру баласын, карт анасын, үзен чорнап алган милли яшәешне ташлап китми. А. Әхмәдуллин сүзләре белән әйткәндә, драмада хис һәм акыл бәрелешендә шәхес ялгызлыгы калкып чыга [Әхмәдуллин, 2002, б. 92 ]. Ике ут арасында калган, яшәү мәгънәсе хакында уйланган, әрнү, газаплану кичергән Вахит рухи газапта – килеп туган каршылыкны чишә алмау, якыннарыннан читләшү, үз эченә йомылу аны үз-үзенә кул салуга этәрә. Биредә шәхес, гаилә трагедиясе милләт фаҗигасе буларак ачыла. Әсәр башында драматург тарафыннан телгә алынган Вахитның авыру баласы да, егет күңелендә барган хисләр бәрелешен, әрнү, газаплану халәтен белдерә.

К. Тинчуринның мәхәббәт өчпочмагына нигезләнгән «Сүнгән йолдызлар» фаҗигале драмасында вакыйгалар Беренче бөтендөнья сугышы вакытында бара. Ф. Бәширов сүзләре белән әйткәндә: «Драматург бу әсәрләрендә үзенең геройларын катлаулы тарихи шартларда тасвирлый. Шуңа да әлеге әсәрләрне халык драмасы дип атау, һичшиксез, дөрес булачак» [Бәширов, 2007, б. 7]. «Сүнгән йолдызлар»да геройлар фаҗигасе ил фаҗигасе белән бергә үрелеп бара. Бу вакыйга Җиһанша карт сүзләрендә дә чагыла: «Кемгә кирәк соң бу сугыш, кемгә кирәк?..» [Тинчурин, 2007, б. 188]. Автор бөтендөнья сугышының халыкка никадәр чит булуын, кешеләргә нинди фаҗигаләр китерүен ача. Авыл егетләренең бер өлеше сугышка алына, икенче төркеме исә төрле юллар белән солдаттан калу юлларын эзли. Әлеге вакыйгаларда авыл яшьләре Исмәгыйль белән Сәрвәрнең бәхетсез мәхәббәте, һәлакәте сурәтләнә. «Сүнгән йолдызлар» пьесасының исеме дә – геройларның үлемен аңлата. Драмада Исмәгыйль күргән төш тә булачак фаҗигале вакыйгаларга ишарә итә: «...аждаһа төсле бернәрсә сызгырды да, йолдызларны сүндерә башладылар. Минем йолдызым да сүнде, мәхдүмнең дә, синең йолдыз да сүнде...» [Тинчурин, 2007, б. 86]. Мәгълүм ки, мифологик ышанулар нигезендә төш киләчәк язмышны күрү, яисә теге яки бу вакыйгаларны хәл итү чарасы буларак карала. К. Тинчурин пьесасындагы Аждаһа, болыт – сугыш, йолдызлар – бәхет

ролен башкара. Шул рәвешле әсәрдә матур хыяллар белән яшәүче, бәхеткә тулы хокуклы геройларның вакытсыз үлеменә сәбәпче булган сугышка, тормыш гаделсезлегенә басым ясала. Драмада табигать тарафыннан кимсетелгән, бөкре, ямьсез кыяфәтле мәхдүм Надир образы да игътибарга лаек. Пьесада ул рухи яктан көчле, горур, саф күңелле, әмма үзенең гариплегеннән авырлыклар, күңел газабы кичерүче шәхес буларак ачыла. Надирның төп эчке конфликты, фаҗигасе – аның теләге һәм чынбарлык арасында. Авылның иң чибәр кызы Сәрвәрне ярату аңа яшәү көче бирә, тормыш мәгънәсенә әйләнә. Герой хыялында туган бәхетен акылдан язган Сәрвәр белән аралашуда таба. Хыялында гына булса да бәхетле булу өметен җимергән чынбарлыкка карата протестын Надир үлеме белән раслый. Шул рәвешле, К. Тинчурин укучыга тирән газапланулар кичергән фаҗигале язмышлы ялгыз кеше образын тәкъдим итә. «Надир мәхдүм кебек гаять киеренке тетрәнүләргә, көчле психологик кичерешләргә ия герой татар драматургиясендә юк иде әле. Бу, һичшиксез, Тинчуринның зур табышы, театр сәнгатенә керткән зур яңалыгы иде» [Бәширов, 2007, б. 11].

Драманың һәр герое үз бәхетенә омтыла, ләкин аларның барысын да реаль тормышның кырыс чынбарлыгы чолгап алган. Күренә ки, К. Тинчурин мәхәббәт, гаилә мәсьәләсен ярлылар һәм байлар каршылыгы аша бирми, ә гашыйклар фаҗигасе ил күләмендә барган вакыйгаларга бәйләп аңлатыла. Иҗтимагыйсәяси шартлар хыялларны тормышка ашырып яшәргә ирек бирми. Татар яшьләренең бу хәлен драматург фаҗига буларак бәяли. Әлеге мәсьәләләр К. Тинчуринның «Ил» (1927) драмасында да күтәрелә. Вакыйгалар ерак үткәнне – алпавытлар, мирзалар хөкем сөргән, гади халык кол хәлендә яшәгән заманны үз эченә ала. Сыйнфый каршылыкларга корылган бу әсәрдә гомумкешелек кыйммәтләре, заман фаҗигасе бирелә. Мәхәббәт өчен көрәш сыйнфый тигезсезлеккә үрелеп китә, югары катлам вәкилләренең гади халыкны ни рәвешле җәфалавын ачуга юнәлтелә. Халык азатлыгына, матур киләчәккә омтылу, ил бәхете өчен көрәшү әсәрнең үзәген тәшкил итә. Автор гади халык азатлыгы, бәхете, бәйсезлеге өчен акрынлап көрәшкә күтәрелүче геройларга өстенлек бирә. К. Тинчурин ил агасы Туктамыш карт, Юлаучы Айтуган, Касыймхан образларына Җиһангир, Гаделгәрәй мирза кебек мәрхәмәтсез хаким сыйныфларны каршы куя. Драмада Туктамыш күпне күргән, акыллы, зирәк, кискен сүзле, шул ук вакытта изелү һәм төрлечә мәсхәрәләүләрне кабул итә алмаган ил агасы буларак тәкъдим ителә. Туктамышның бал кортларының тынычсызлануы, корт иленең күчеп китүе турындагы хәбәре крестьяннар арасында башланган уянуга, күтәрелүгә ишарәле. Сыйнфый көрәшне тирәнәйтеп күрсәтү өчен автор Юлаучы образын файдалана. Ул үзенең «чалгы хикәясе»ндә изелгән авыл халкына кораллы көрәш

тәртипләрен, ил күләмендә азатлык өчен башланган хәрәкәтләрнең активлашуын аңлата, кораллы күтәрелешкә чакыра. Пьесада Габделгәрәй мирзаның, аның приказчигы Җантимернең төрлечә мәсхәрәләүләренә протест рәвешендә Касыймханның алпавыт утарына ут төртүе геройны бунтарь-көрәшче дәрәҗәсенә күтәрә. Шушы хәлләрдән соң авыл кешеләре сыйнфый изүгә каршы оешкан төстәрәк протест белдерә башлыйлар. Бу бәрелешләр халык арасында социаль көрәшнең тууын хәбәр итә, ул дөньяга караш, әхлакый кыйммәтләр яссылыгында да бара. Айтуган, Касыймхан кебек ярлы халык вәкилләре, үзләрендә көрәшкә җитәрлек көч булмавына карамастан, кыю рәвештә гаделсезлеккә каршы чыгалар. Ләкин Туктамыш карт кулга алына, Айтуган күтәрелеш вакытында үтерелә. Биредә фаҗигалелек очраклы рәвештә, аерым бер шәхескә бәйле генә түгел, ә гаделлеккә каршы куелган явызлыкның көчлерәк булуыннан килеп туа. Айтуганның үлеме тормыш һәм язмыш изүе, байлык хуҗаларының гаделсезлеге нәтиҗәсе буларак бәяләнә. Әлбәттә, протест пассив характерда. Социаль киртәләрнең билгеле бер моментта көчлерәк булуы геройның фаҗигасен тудыра. Драматург аерым кешеләрнең шәхси язмышлары аша халык тормышының давыллы елларын, өмет чаткыларын, хезмәт кешесенең хыял-омтылышларын табигый җирлектә сурәтли.

К. Тинчуринның шигъри формада язылган бердәнбер сәхнә әсәре «Зар» (1922–1923) трагедиясендә яшәеш, яшәү мәгънәсе турында фәлсәфи караш тәкъдим ителә. Үз вакытында Г. Гали әсәргә «идеологический яктан зарарлы» дигән мөһер суга [Гали, 1924]. Әсәрдә Газраил, Газазил, Әҗәл, Һава, Адәм кебек образларга яңа мәгънә салына. Трагедиядә, мәсәлән, Газазил – иреккә, бәхеткә омтылыш символы буларак тәкъдим ителсә, Дәҗҗал аңа каршы куела.

«Г а з а з и л.
Янсын гомергә
Чын дуслык, ирек!
Һәм саф матурлык
Яшәгән чакта,
Яшәмәс коллык», –

ди ул [Тинчурин, 1986, б. 420].

Шәйтан исә җиһанда золым өстенлек итүен тели, Бәдбәхеткә бәла-казалар, хәсрәт, байлыкка табынучы Яэҗүҗгә (Капиталга) тәхет кирәк, Мәхәббәт иреккә омтыла, матурлыкны юкка чыгаручы Мәэжүҗ (Милитаризм) сугыш тели, Ирек исә азатлык сорый.

Шул рәвешле, оҗмах халкы ике төркемгә – Газазилны куәтләүчеләргә һәм Дәҗҗал яклыларга аерыла. Адәм яратылгач исә хакимлеккә омтылган Дәҗҗал белән Газазил арасындагы каршылык тагы да кискенләшә. Дәҗҗал һәм аның тарафдарлары Адәмне үз максатларында файдаланып, явызлыкка өндиләр. Газазил Алла яраткан Адәмгә ак мәрмәрдән эшләнгән, матурлык символы булган Һаваны каршы куя. Мәхәббәтләре өчен Адәм белән Һава оҗмахтан куылгач, җирдә ачлыктан җәфа чиккән Адәм, Шәйтан котыртуына бирелеп, кыр кәҗәсенең башына таш белән бәрә, кан коя. Кан коюның

нәтиҗәсе буларак, кешеләрнең гомере чикләнә. Кызганыч ки, җирдә дә матурлык табылмый. Адәмнәрне бер-берсенә каршы котыртып, Шәйтан йөри. Фән һәм техника казанышлары да Дәҗҗалга хезмәт итә. Әйләнә-тирәдә коллык, ачлык хөкем сөрә. Акрынлап җир өстендә «Төрле шахта һәм приискаларның галәмәтләре күренә. Уртада адәм сөякләреннән өелгән зур тау. Газраил шул тауның башында басып тора» [Тинчурин, 1986, б. 502].Техника белгече Мөһәндис «бер сулышта йөз мең адәм кыра торган» корал уйлап таба. Әмма Мөһәндиснең яңа коралы җирне юк итәргә өлгергәнче, изелгәннәр хакы өчен көрәшүче Газазил халыкны явызлыкка каршы көрәшкә күтәрә. Трагедия ахырында бары Шәйтан гына богаулы урынын калдырып кача. Димәк, азатлык, ирек өчен көрәш дәвам итә. А. Әхмәдуллин билгеләгәнчә, әсәрнең беренче өлешендә шәхеснең азатлыкка омтылышына, аның фәлсәфи якларын барлауга игътибар ителсә, икенче өлештә изелүчеләрнең изүчеләргә каршы көрәше алга чыга [Ахмадуллин, 2012, б. 223]. Авторга мифологик образларга таяну отышлы нәтиҗәләр бирә: иҗади фикерләү колачын киңәйтә, чор үзенчәлекләрен үтемлерәк бәян итү мөмкинлеген ача. Трагедиядә инкыйлаб мотивлары конкрет чагылыш таба.

К. Тинчурин заман кешеләрен, чорга хас үзенчәлекләрне эволюцион үсештә сурәтли. Тема һәм күтәрелгән мәсьәләләрнең күп булуы әдипне төрле жанр формаларына мөрәҗәгать итүгә, аларның мөмкинлекләрен иҗади файдалануга этәрә. Аның иҗатында якты киләчәккә өметләндергән көч, халык рухының үлемсезлеге алгы планга чыга. Әсәрләрендә шәхес һәм ил фаҗигасе җәмгыятьтәге тәртипләр аша ачыла. Пьесалар үзәгендә аерым бер кеше яшәеше генә түгел, ә халык, милләт язмышы.

**Әдәбият**

*Арсланов М.Г.* К. Тинчуринның тормышы һәм иҗат этаплары // Кәрим Тинчурин һәм татар сәнгате: Бөтендөнья фәнни-гамәли конференциясе материаллары. Казан, 2007.336 б.

*Ахмадуллин А.Г.* Татарская драматургия: история и проблемы. Казань: Татар. кн. изд-во, 2012. 329 с .

*Әхмәдуллин А.* Офыклар киңәйгәндә. Казан: Татар. кит. нәшр., 2002, 239 б.

*Бәширов Ф.* Ул кабызган учаклар мәңге янар // Тинчурин К.Г. Драмалар, комедияләр, хикәяләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. Б. 3–12.

*Гали Г.* Зар // Кызыл Татарстан. 1924. 29 май.

*Тинчурин К.* Әсәрләр: 3 томда. Т. 1. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. 472 б.

*Тинчурин К.Г.* Драмалар, комедияләр, хикәяләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. 351 б.

*Шәехов Л.М.* Татар шигъри трагедиясе. Казан: ТӘһСИ, 2016. 160 б.

***Миңнуллина Фатыйма Хәлиулла кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*
*minnullina77@mail.ru*

УДК 821.512.145-2

*Д.Р. Фәрдиева*

# К. ТИНЧУРИН ПЬЕСАЛАРЫНДА ПСИХОЛОГИЯ ҺӘМ ГЕРОЙЛАРНЫҢ ЭЧКЕ ДӨНЬЯСЫН ЧАГЫЛДЫРУ (**«Соңгы сәлам» һәм «Сүнгән йолдызлар»**)

Творчество К. Тинчурина составляет гордость и славу татарского народа. Его можно поставить в ряд первостепенных драматургов как создателя неувядаемых шедевров, оказавших влияние на развитие татарской драматургии. Время не стерло с произведений Тинчурина свойственных им красок, их общечеловеческую сущность, неумирающую идейно-эстетическую ценность. В его пьесах изображаются обычные ситуации с обыкновенными людьми, драмы которых уходят в быт и человеческую психологию.

**Ключевые слова:** пьеса, психология, герой, внутренний мир, характер.

Кәрим Тинчуринның драматургия өлкәсендәге эшчәнлеге 1911 елда башлана. Сәхнә әсәрләре буенча иҗади казанышлар, яңа юнәлешләр һәм жанрларның күбесе аның исеме белән бәйле. Сәхнәгә яңа темалар һәм образларны башлап күтәрүче дә ул. Аның яңалыкка омтылышы татар театры үсешендә зур урын алып тора, ә К. Тинчурин үзе татар сәхнә сәнгатенә җаны-тәне белән бирелгән фидакарьлек үрнәге булып санала. К. Тинчурин иҗаты халыкчанлык белән сугарылган, шуңа күрә аның сәхнә әсәрләре әле бүген дә татар тамашачысы күңеленә ләззәт, хозурлык өсти. К. Тинчурин пьесаларына жанрлар төрлелеге хас. Шул ук вакытта аны әхлакый-психологик проблемалар да кызыксындыра. Ул үз геройларының язмышын чынбарлыкка якын итеп, тирәнтен тасвирлый.

Әлбәттә, драматург һәм режиссер К. Тинчурин үзе тудырган образларның эчке кичерешләрен сәхнәдә ачуның әсәрдә урын алган эш-хәрәкәтләр, көрәш, конфликтлар аша гына тормышка ашырылуын яхшы аңлый. Аның үзенчәлеге шунда, ул үз заманы тормышына үтеп кергән һәр яңалыкны бик тиз тотып ала һәм аны үз пьесаларындагы образлар, аларның каршылыклы мөнәсәбәтләре ярдәмендә яктыртуга ирешә.

Үз персонажларының шәхси дөньясын ачуда К. Тинчурин игътибарын аларның хисси халәтләренә, эчке кичерешләренә һәм психологиясенә юнәлтә. Аның геройлары калку һәм күпкырлы. Психологик яктан киңкырлы социаль типларны сурәтләүдә драматург төрле чаралардан файдалана, ягъни алар персонажларның монологлары, сөйләме, интонацияләре, үзара әңгәмәләре һәм үз-үзләрен тоту нормалары аша яктыртыла. Ул үз геройларын чор таләпләреннән чыгып кына түгел, ә кешеләргә хас шәхси үзенчәлекләрне дә истә тотып гәүдәләндерә.

К. Тинчурин кеше психологиясен, аның эчке дөньясын,

күңелендә барган катлаулы каршылыкларын дөрес итеп күрсәтә белә. «Соңгы сәлам» (1916) һәм «Сүнгән йолдызлар» (1923) пьесаларында ул үзәк персонажлар итеп көчле характерлы, кеше хәлен аңлаучы һәм гаделсезлеккә, хыянәткә, ялганга, кешелек дәрәҗәсен кимсетүгә һ.б.га каршы көрәшергә сәләтле, тирән хисле образларны күтәрә. Бу әсәрләрдә геройларның эчке конфликтлары беренче планга куела. Автор, икенең берсен сайлау зарурлыгы килеп туган катлаулы шартларда, геройларын хәлиткеч сынауларга дучар итә.

«Соңгы сәлам»дә коммерсант Вахит Мансуровның рус кызы Ольга Вахрушинага гашыйк булуын һәм бу аның күңелендә тирән кичерешләр, эчке каршылыклар тууга сәбәп булуын автор бөтен тулылыгы белән ача. Пьесада баш геройның эчке дөньясы бөтен тирәнлеге белән тасвирлана. Вахит ике башлангыч – Ольгага карата уянган мәхәббәт хисе һәм үз гаиләсе (ул өйләнгән була) каршында җаваплылыгы – көрәшә. Бу көрәш геройда шәхси азатлыкка омтылыш уята. Театр белгече Э. Гафарова бу хакта болай яза: «Вахит поразительным образом отчужден от мира, в котором он живет, он полностью и без остатка предоставлен самому себе, и никакие успехи не в силах разлучить Вахита Мансурова с самим собой – тревожным и мающимся от непостижимой маеты. В тайну героя нет ходу никому, даже самым близким» [Гафарова, с. 11]. Мансуровның психологиясе аның үз гаебен тануы һәм үз хисләрен йөгәнләү процессында – пьесаның чишелеш ноктасына җиткәч – аның тәүбәгә килүендә ачыклана.

Әлбәттә, К. Тинчуринның герое катлаулы һәм каршылыклы характерга ия, ул үзенең яшәү мәгънәсен югалта. Драматург үз героеның газаплы кичерешләре ярдәмендә драматик конфликтлар тудыра һәм аның чишелешен дә хәл итә. Герой йомшак характерлы, ул туктаусыз икеләнү халәтендә. Болар аның котычкыч ярсулы кыланышларында чагыла. Аңлашыла ки, Вахитның каршылыклы характеры аның фаҗигасенә сәбәп була. Геройның трагедиясе шунда: ул килеп чыккан хәлләр белән я килешергә, я тормыштан китәргә тиеш була. Драматург героеның килеп туган вазгыятьтән кая барып сыенырга белми бәргәләнүен бик оста сурәтли. Ниһаять, Вахит өметсезлекнең соңгы чигенә җитә, язмышына буйсынып, үз-үзенә кул сала. Сюжеттан аңлашылганча, Вахит образы фаҗигале чишелеш өчен бирелгән. Аның аша драматург яшь, сәламәт ир кешенең мәхәббәттә үзенә үзе хуҗа була белмәгән җиңел карашлы булуын хөкем итә.

«Соңгы сәлам» пьесасы – көчсез шәхеснең фаҗигасе. Драмада аның әхлакый яктан зәгыйфьлегенең сәбәпләрен эзләү омтылышы ясала. Катлаулы эчке бәрелешләр, образларның ялган уңышлары артына яшерелгән сәбәпләрне ачыклау геройның үз-үзен юк итүенә китерә. Пьеса шәхеснең әхлакый яктан бозылуын һәм рухи таркалуын кисәтә. К. Тинчурин герое исә берничә тапкыр үзгәрергә, ба-

рысын да яңадан башларга тырышып карый. «Соңгы сәлам» пьесасының мотивы баш геройны рухи икеләнүләрдән айнырга, яңа тормышка чакыра. Автор героеның психологик халәтен сентименталь калыпта бирә. Вахит килеп туган хәлләрне җиңеп чыга алмый, үз-үзенә кул сала. Нәкъ менә рухи каршылыклар һәм икеләнү аны шушы адымга этәрә.

«Соңгы сәлам» пьесасында герой үзенең хисси үзенчәлекләренә бәйле эчке дөньясы белән шәхескә мөнәсәбәтле тышкы дөнья арасындагы каршылыкка керә. К. Тинчурин шуны таныган хәлдә, әлеге пьесасында шәхеснең эчке мөмкинлекләрен файдалану проблемасы хөкем сөргән дөнья белән кеше арасында яңа мөнәсәбәтләр урнаштыру мөмкинлекләрен табарга омтыла.

К. Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар» пьесасында персонажларның рухи кичерешләре сурәтләнә. Геройларның һәркайсы ачык яки яшерен максатларын күздә тота, аларның һәркайсында бик тирәндәге кешелек хисләре көрәшә. Образлар тулы бирелгән, һәр персонажның психологик чикләре аерым-аерым гәүдәләндерелгән. «Сүнгән йолдызлар»ның төп темасы – кеше бәхете. Әсәрдәге баш геройлар, индивидуаль психологик тип буларак, дөрес сурәтләнгән.

Надир мәхдүм образы авторның зур казанышы дип бәяләнергә хаклы, К. Тинчурин аның эчке кичерешләрен бик тирәннән ача. Надир мәхдүмгә тынгысызлык, хыялыйлык сыйфатлары хас. Ул – гадәти булмаган романтик шәхес, үзе яшәргә мәҗбүр булган заман, дөнья тарафыннан кабул ителмәгән зат. Ул изге күңелле, әмма аны үзенең физик халәте борчый. Шул ук вакытта ул горур да: үзенә кызганып караучыларны дошманы итеп күрә. Бөкре, ялгыз, дөньяга ачулы егет яшәү мәгънәсен Сәрвәргә мәхәббәтендә күрә. Яшәү белән үлем Надир өчен үз мәхәббәтенең көчлелегендә чагыла. Аның эчке матурлыгы, күңел байлыгы тышкы кыяфәте астына яшерелгән. Нәтиҗәдә Надир мәхдүм образы ярсулы һәм эчкерсез ярата белүе белән сокландыра.

К. Тинчурин Сәрвәр образы аша гаделсезлеккә каршы көрәшкә күтәрелергә җөрьәт иткән кыю татар кызын гәүдәләндерә. Шул ук вакытта Сәрвәрнең дә күңеле эчке каршылыклар белән тулы. Бер яктан, аны Надиргә димлиләр, ә икенче яктан, Исмәгыйльне сөя, үзенең бәхетен аның белән бергә булуда күрә. Шуңа күрә дә ул үз бәхете өчен көрәшергә карар кыла һәм тәвәккәлләп кискен адымга бара. Ул йөрәге кушуы буенча яши һәм сөйгәне белән бергә булырга хыяллана. Героиня, бәхетенә өмет тотып, якты хыялларга бирелә, әмма аның бу хыялларына кырыс чынбарлык каршы баса. Аны уратып алган тирәлек кызның ихтыярын, эчке дөньясын җимерә.

К. Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар»ында Исмәгыйльнең дә эчке дөньясы катлаулы итеп сурәтләнә. Ул ягымлы, игелекле, әдәпле, әмма шул ук вакытта натурасы белән кыюсыз, йомшак характерлы. Исмәгыйль күргән төшенә ышана, ә аның төшен

бәхетсезлеккә юрыйлар, шуңа күрә егет сөйгәне Сәрвәр белән бәхетле тормышка ышанычын тәмам югалта. Аңа үз бәхете хакына көрәшү өчен кыюлык да, тәвәккәллек тә җитми. Пьесада Исмәгыйльнең эчке каршылыгы нәкъ менә шунда чагыла.

К. Тинчурин үзенең пьесаларында милли йола-гадәтләргә һәм яшәү рәвешенә яраклашып формалашкан характерларны тасвирлый. Әсәр геройлары хыялый һәм хисчән. К. Тинчурин «Сүнгән йолдызлар»дагы образларын катлаулы, каршылыклы итеп һәм шактый киң яктырткан. Автор алар үрнәгендә төрле типтагы кешеләрнең төп сыйфатларын үзара чагыштыру, тормышка карашлары ярдәмендә сурәтли һәм аларның йомшак якларын калкуландырып күрсәтә.

Әсәрләреннән аңлашылганча, К. Тинчурин характерлар гәүдәләндерү остасы. «Соңгы сәлам» һәм «Сүнгән йолдызлар» пьесаларында катлаулы һәм психологик яктан күпкырлы сыйфатларга ия кешеләрнең характерын ул яңача сурәтли. Автор геройларының күңел каршылыкларын да, үз-үзен тотышы белән эчке дөньялары тәңгәл килмәгән очракларны да оста тасвирлый.

Шул рәвешле, К. Тинчурин реалистик персонажлар дөньясын күз алдына бастыра һәм аларның күңелләрендә туган хисләрен, дөньяга карашларын тирәлектәге вакыйгаларга бәйләп яктыртуга ирешә.

**Әдәбият**

*Гафарова Э.* Пять вечеров в театре Фарида Бикчантаева // Петербургский театральный журнал. 1997. № 13. С. 11–13.

***Фәрдиева Динара Радий кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының театр һәм музыка бүлеге фәнни хезмәткәре*

УДК 372.878:821.512.145-2

***Н.Х. Нургаянова***

# К. ТИНЧУРИННЫҢ ИҖАДИ МИРАСЫН САКЛАУДА ҺӘМ ПРОПАГАНДАЛАУДА МУЗЫКАЛЬ БЕЛЕМНЕҢ РОЛЕ

Творческое содружество драматурга К. Тинчурина и композитора С. Сайдашева открыло широкие возможности для использования национальной музыки на сцене татарского драматического театра. Тесное взаимодействие литературы и музыки привело к созданию нового для татарской музыкальной культуры XX века жанра музыкальной драмы. Сохранение и передача новым поколениям творческого наследия выдающихся деятелей культуры и искусства – важнейшая задача современного художественного образования.

**Ключевые слова:** музыкальная драма, художественная культура, композитор, драматург, духовно-нравственное воспитание.

Соңгы вакытта Россия медиакиңлеген «поп-культура» дип аталган, бүгенге заманның музыкаль дөньясын, телевизион тапшыруларын һәм кинофильмнарны колачлаган түбән эшләнешле үрнәкләрнең зарарлы йогынтысы сизелә башлады. Бу күренеш үсеп килүче буынның милли мәдәниятебез, аның үткәне белән кызыксынуын әкренләп сүндерә бара. Ә бит, һәркайсыбызга мәгълүм булганча, киләчәкне үткәннәрдән башка күзаллау мөмкин түгел. Мәдәният өлкәсендәге милли казанышларыбызны саклау процессының бозылуы нәтиҗәсендә алдагы буыннарга рухи кыйммәтләрне (барыннан да бигрәк, туган телне, милли фикерләү сәләтен, музыкаль-эстетик зәвыкны, үзара мөнәсәбәтләр культурасын) табигый юл белән тапшыру өзеләчәк.

Үз халкының әдәби-сәнгати казанышларын үзләштерү юлында кеше өчен иң мөһиме – шушы өлкәдәге күренекле осталарыбыз иҗатын өйрәнү. Фәкать алар – язучылар, композиторлар, рәссамнар элек-электән милли мәдәниятебез нигезләрен баета килгәннәр. Күпме генә гомерләр кичсә дә, аларның әсәрләре үзләренең художество кыйммәтен югалтмаган, ничәмә-ничә буыннар зәвыгын һәм эстетик омтылышын кичеп, әле дә булса тамашачының да, укучының да, тыңлаучының да хисләрен кузгатуны, аларны дулкынландыруны дәвам итәләр.

Татар халкының милли мирасы киңлегендә язучы, шагыйрь, драматург, режиссер, артист Кәрим Тинчурин иҗаты якты сәхифә булып санала. Аның моннан йөз ел элек язылган пьесалары бүген дә татар театры сәхнәләре түрендә.

Татар драма театры формалашуның башлангыч чорында ук (1911 елдан «Сәйяр» труппасында, 1922 елдан – театрның художество җитәкчесе) бу талантлы

шәхес үз тирәсенә республиканың милли горурлыгын тәшкил итәчәк сәләтле актерлар һәм драматурглар плеядасын туплый. Кәрим Тинчурин чакыруы буенча яшь музыкант һәм дирижер Салих Сәйдәшев Оренбургтан Казанга күчеп килә. К. Тинчурин аны театрның музыкаль бүлеге җитәкчесе итеп билгели, шулай итеп аңа композиторлык эшчәнлеген яңа юнәлешләрдә дәвам итү мөмкинлеге тудыра.

К. Тинчурин, алдан күрә белүчәнлеге нәтиҗәсендә, татар мәдәниятенә иҗаты белән милли профессиональ музыка тарихын баетучы шәхес – С. Сәйдәшевне бүләк итә. Яңа җитәкченең бурычы симфоник оркестр өчен халык көйләрен эшкәртү булса, ул инде татар сәхнә сәнгатенә яңа форма – музыкаль-драматик спектакльләр өстендә дә эш башлый.

Шуны искә алып китәргә кирәк, әдәбият белән музыканың үзара бәйләнеше татар милли сәнгате үсеше тарихының барлык дәверләрендә дә күзәтелә. 1916 елда, мәсәлән, татар сәхнәсендә Г. Исхакыйның «Зөләйха» пьесасы күрсәтелә, аңа музыканы С. Габәши яза. Бу – профессиональ музыка ярдәмендә сәхнәләштергән беренче спектакль була. Ә инде ике күренекле шәхес – драматург К. Тинчурин белән композитор С. Сәйдәшев бердәмлеге ул башлангычны яңа баскычка күтәрә, татар сәнгатенең яңа жанрына – музыкаль драмага нигез сала.

С. Сәйдәшев белән К. Тинчурин иҗаты хакындагы фәнни тикшеренүләрдә «музыкаль драма», файдаланылган сюжетлар, пьесаның эчтәлеге, музыкаль тел сыйфаты төшенчәсенең асылы буенча төрле фикерләр очрый [Салитова, 1988]. С. Сәйдәшев иҗатын тирәнтен өйрәнеп тикшерүче Ф.Ш. Салитова «сюжеты пьес К.Тинчурина, к которым писал музыку С. Сайдашев, достаточно условны и этим перекликаются с произведениями музыкального театра. Авторы создавали поистине синтетические спектакли, учитывающие специфику музыкальной сцены, которой изначально присущи условность сюжета и поэтизация бытовых коллизий», – дип яза [Салитова, 2007, с. 143].

К. Тинчурин белән С. Сәйдәшев музыкаль спектакльләрдә, халык авыз иҗатындагы ачыктан-ачык каршылыкка нигезләнгән игелек һәм явызлык категорияләрен кулланып, милли йола-гадәтләребездән кыю файдалананалар. Аларның 1023–1926 елларда, совет җәмгыяте тормышы өчен кирәксез санап, үткәннәргә тискәре караш, тупланган мәдәни кыйммәтләрне кире кагу шартларында сәхнәләштерелгән музыкаль әсәрләрен чын мәгънәсендәге яңарыш, халык тормышы энциклопедиясе дияргә мөмкин.

Утызынчы елларда авторларны пролетариат тематикасына игътибарсызлыкта гаепләлиләр, музыкаль драмалардан – тормышчанлыкны, сәхнә әсәрләренең көнкүреш драмаларына нигезләнгән булуын таләп итәләр.

Чыннан да, К. Тинчуринның музыкаль драмаларында

социалистик хезмәт геройлары бирелми, әмма драматург ул чор өчен мөһим бер күренешкә: спектакльдә гәүдәләнгән образлар һәм күптән түгел авылдан шәһәргә күчеп килгән тамашачы арасында җанлы элемтә урнаштыруга ирешә, чөнки автор халыкка рухи-әхлакый тәрбия бирүдә драма театрының мөмкинлекләрен һәм әһәмиятен яхшы аңлый.

Композитор С. Сәйдәшев катлаулы хәлгә дучар ителә: халыкка якын һәм аңлаешлы музыка иҗат итәргә дә кирәк, шул ук вакытта ул тамашасы зәвыгы дәрәҗәсендә бөтенләй гадиләштерелгән дә булмасын; татар рухына чит европачыл формалар һәм композиция алымнары куллану зарурлыгы да таләп ителә. Драматург белән композитор, шул чор татар милли аудиториясенең ихтыяҗын тирәнтен аңлаган хәлдә, татар сәхнәсендә шигъри-музыкаль иҗатның иң яхшы үрнәкләрен гәүдәләндерәләр.

К. Тинчурин һәм С. Сәйдәшев тарафыннан сәхнә өчен иҗат ителгән яңа жанрның тарихи-педагогик әһәмияте шунда, узган гасырның 20 нче еллары башында театр залларын тутырып җыелган тамашачы дирижер җитәкчелегендәге оркестр башкаруында шул чор өчен гадәти булмаган татар көйләрен ишетә; ария, дуэт, хор кебек яңа вокаль жанрлар һәм хореографик чыгышлар, шул ук вакытта дөньякүләм музыкаль культура казанышлары белән таныша.

Милли драматургия барлыкка килү профессиональ музыкаль сәхнә сәнгате үсешенә мөмкинлек тудыра. Әмма музыкаль белемгә нигезләнгән татар музыкаль драмасы жанры формалашуда композиторның әйдәүче роле, еш кына, зур күләмле әдәби әсәрнең әһәмиятен киметә. Шуңа күрә, К. Тинчурин үзенең музыкаль-драматик рухтагы пьесаларын иҗат иткәндә ария, хор өчен җыр текстларын спектакльнең кайсы өлешендә һәм кайчан башкарылачагын бик җентекләп билгели, репетицияләр вакытында җитди төзәтмәләр кертә [Игламов, с. 82].

К. Тинчурин исемен әйтү дә тыелган елларда аның иҗади мирасы татар мәдәниятеннән читләштерелә; аның драма әсәрләреннән алынган музыкаль өзекләр, профессиональ җырчылар репертуарындагы җырлар радио аша тапшырылганда авторның исеме әйтелми. Моның ачык үрнәге итеп, аның «Кандыр буе» пьесасындагы «Без кабызган утлар» җырын С. Сәйдәшевнең фольклор текстына язылган музыкасы дип кабул итүне әйтеп үтәргә була [Игламов, с. 81]. Шуңа да карамастан, шигъри текст белән музыканың бер-берсенә үрелеп яңгыравы язучының музыкаль сәнгатьне үстерүдә нинди зур көчкә ия булуын раслый, аның иҗаты буыннан буынга күчеп яшәвен дәвам итә.

Хәзер К. Тинчуринның иҗади мирасын саклау һәм аны пропагандалау өлкәсендә художество, шул исәптән музыкаль белем системасына зур мөмкинлекләр бирелде. Музыкаль белем бирү си-

стемасының роле туган якның мәдәни казанышларын пропагандалауга алынган (ә бу – милли-төбәк үзенчәлекләрен файдалануга әзерлекле якын килүне таләп итә) белгечләр тәрбияләүдән гыйбарәт.

Татарстанда профессиональ музыкантлар әзерләү Н. Җиһанов исемендәге консерваториядә, Мәдәният һәм сәнгать институтында, музыкаль көллиятләрдә тормышка ашырыла. Татар милли мәдәниятен саклау һәм пропагандалауда, гомуми һәм өстәмә музыкаль белем бирү учреждениеләрендәге татар теле һәм әдәбияты укытучылары белән беррәттән, педагог-музыкантлар да зур роль уйный. Ә аларны әзерләү Казан (Идел буе) федераль университетының Лев Толстой исемендәге филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында тормышка ашырыла.

Булачак музыкантлар татар музыкаль драмасы жанры формалашу тарихын (анда К. Тинчурин пьесаларына иҗат ителгән музыкаль әсәрләрне өйрәтүгә зур урын бирелгән) да үз эченә алган «Татар музыкасы тарихы» фәнен өйрәнү процессында С. Сәйдәшев иҗаты белән дә танышалар [Дулат-Алиев].

Музыкантларны һөнәри әзерләү барышында С. Сәйдәшев әсәрләренең 1957, 1980 елларда басылып чыккан ноталы җыентыклары (җырлар, арияләр, дуэтлар, хор өчен язылган хезмәтләре, музыкаль драмалардан өзекләр, инструменталь пьесалары. Төзүчесе – З. Хәйруллина) файдаланыла [Сәйдәшев, 1957; Сәйдәшев, 1980]. Мәсәлән, программага түбәндәге әсәрләр кертелгән: «Зәңгәр шәл»дән Булат җыры, Мәйсәрә җыры, «Кара урман»; «Ил» драмасыннан Зифабану ариясе, кызлар җыры «Сандугач», «Ал чәчәкләр» (хор), чалгычылар җыры; «Кандыр буе»ннан Кандыр турында җыр, Гөләндәм ариясе, Фәридә ариясе, Фәридәнең ике җыры, монтерлар җыры «Без кабызган утлар»; шулай ук баян өчен язылган әсәрләреннән «Сүнгән йолдызлар» драмасына кереш; «Кандыр буе» пьесасына куелган «Уңыш бәйрәмендә» биюе көе. Бу әсәрләр барысы да булачак җырчылар, музыка коралларында уйнаучылар, дирижерлар һәм теоретиклар өчен уку материалын тәшкил итәләр. Татар сәнгате традицияләренә нигезләнгән музыкаль белем һәм тәрбия бирү уку йортларын тәмамлаучылар милли мәдәниятебез мирасын үзләреннән соңгы буынга да калдырырлык дәрәҗәдәге әзерлеккә ия булырлар дип, зур ышаныч белән әйтә алабыз.

**Әдәбият**

*Дулат-Алеев В.Р.* Татарская музыкальная литература: учебник. Казань, 2007. 491 с.

*Игламов Н.Р.* Об одной «забытой» пьесе: «На Кандре» К. Тинчурина. Карим Тинчурин и татарское искусство: материалы Всероссийской научно-практической конференции. Казань, 2007. С. 75–84.

*Салитова Ф.Ш.* Музыкальные драмы Салиха Сайдашева (роль жанра в становлении татарской профессиональной музыки). Казань: Таткнигоиздат, 1988. 180 с.

*Салитова Ф.Ш.* Традиционная татарская музыка и национальная литература и драматургия. Карим Тинчурин и татарское искусство: материалы Всероссийской научно-практической конференции. Казань, 2007. С. 139–144.

*Сәйдәшев С.* Без кабызган утлар (җырлар, арияләр, дуэтлар, инструменталь әсәрләр) / төзүчесе З. Хәйруллина. Казан: Татар кит. нәшр., 1980. 311 б.

*Сәйдәшев С.* Сайланма әсәрләре: җырчылар, хор һәм фортепиано өчен. Казан: Татар кит. нәшр., 1957. 212 б.

***Нургаянова Наилә Хәбибулла кызы,***
*педагогика фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының театр һәм музыка бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 398:177

*И.Г. Закирова*

## ТУГАН ТЕЛДӘ КЫЛГАН ДОГАМ

В татарском фольклоре есть жанры, которые до сих пор остаются вне поля внимания исследователей. К таким жанрам относятся *багышлау* (посвящения), *изге теләк* (благопожелания). Цель исследования – ввести эти жанры, которые являются источником для изучения нравственных ценностей народа, его национального этикета, в научный оборот.

**Ключевые слова:** благопожелания, татарский фольклор, верования, нравственные ценности.

Ислам динен рәсми рәвештә Х гасырда ук кабул иткән татар халкының рухи кыйммәтләре дә ислам кануннарына нисбәттә формалашкан. Халык гасырлар дәвамында шушы кануннар нигезендә җанын-рухын мәкердән-яманлыктан саклап, тәнен, киемен-йортын һәм бигрәк тә уй-фикерләрен пакь тотып, изге ният кылып яшәргә омтылган.

Хәзерге вакытта уй-фикерләрнең һәм ниятнең дә зур көчкә ия булуы фән тарафыннан да исбатлана башлады. Бу теләкниятләрнең беренче чиратта кешенең үз тормышына тәэсире бәхәссез. Дөньяны яратып кабул иткән, бар кешеләргә яхшы теләктә булган, хәерхаһлы кеше, әлбәттә, сәламәт була, үзенең нерв системасын саклый. Икенче яктан, теләсә нинди теләк кешенең үзенә кире кайта. Шуңа күрә дә кешегә начарлык түгел, үзеңә яхшылык теләргә кирәк. Бүгенге көндә психологлар дошманыңа да, сиңа начар мөнәсәбәттә булган кешеләргә дә яхшы уйда калырга, яки бу начарлыкны онытырга кушалар. Яхшы теләк төгәл формалашкан булырга тиеш. Шуңа күрә дә «тели белсәң – теләк, тели белмәсәң – имгәк» диләр.

Татар халкында яхшы уй-фикер, изге теләкләрнең калыплашкан бик матур үрнәкләре бар. Бу – багышлаулар, алкышлар, төрле эш-гамәлләргә һәм вакыйгаларга бәйле рәвештә Аллага мөрәҗәгать иткән шигъри текстлар. Алар барысы да татар телендә. Информантлар бу текстларны дога дип тә атыйлар. Габдулла Тукайның «Туган тел» шигырендәге юллар нәкъ шушы текстларның асылын ача:

И туган тел! Синдә булган иң элек кыйлган догам:
Ярлыкагыл, дип, үзем һәм әткәмәнкәмне, Ходам!

Сезнең игътибарыгызга әлеге теләкләрнең татарлар яшәгән төрле төбәкләрдә язып алынган кайбер үрнәкләрен тәкъдим итәбез. Ул текстларда татар халкының ислам һәм мәҗүсилек белән бәйле күп кенә ышанулары, изге саналган күп кенә шәхесләрнең исемнәре саклана. Текстлар-

да мәгънәләре аңлашылмаган сүзләр дә очрый. Әмма аларны да төшереп калдыру дөрес түгел. Бәлки укучылар арасында бу сүзләрнең мәгънәсен, каян килеп чыгуларын белүчеләр булыр.

Беренче текстны 2003 елда Свердловск өлкәсендә узган экспедиция вакытында, Красноуфимский районы Табанлы Күл авылында яшәүче Миңнеәхмәтова Фатыйма апа Гафи кызы биргән дәфтәрдән алдык. Бу – Коръән укудан соң багышлау. Текстта гарәп теленнән кергән сүзләр, ислам мифологиясе белән бәйле исемнәр, терминнар күп сакланган. Текст, мәдрәсәдә белем алган, гарәп телен яхшы белгән кешеләр тарафыннан төзелеп, буыннан буынга күчеп сакланган күрәсең. Һәр шәхес яки термин турында мөмкин булган кадәр аңлатма биреп барырга тырыштык.

**Багышлау**

Ошбу укылмыш аятьләрне тапшырдым тәрбияче бер Аллам үзеңә. Үзең разый булып, укуымда булган хаталарымны гафу кылгыл. Җир йөзенә нур итеп җибәрелгән пәйгамбәребез Мөхәммәт саллэллаһу галәйһи вә сәлләмнең рух шәрифләренә ирештер. Әһле әүлядларына[1], әһле бәйтенә[2], әнбияләр[3]-әүлияларыңа[4], чаһрияр-лар[5], җиде газизләргә[6], мәшаехләргә[7], сәхабәләргә[8], ил иманнарына, ил остазларына, әхмәтләр[9], солтаннар рухларына әҗер савапларын ирештер, и Ходаем.

Барча рәхим фәрештәләребезгә, газап фәрештәләребезгә, өч йөз алтмыш алты гаип ирәннәренә[10], караеш яланга[11], кыйтмир көчекләргә[12] ирештер, әй Ходаем. Барча үзеңнең тиешле урыннарыңа ирештер. Атабыз Адәм белән анабыз Хәүва рухларына, анабыз Мәрьям рухларына, анабыз Гамбәр[13] рухларына, унбер җәннәт әнкәләребезгә[14], мәгъриптән мәшрикъка хәтле пәйгамбәрләребез рухларына, Рәсүлебезнең сигез зәүҗәт мотаһһәраларына[15], Фатыйма[16] разыйаллаһу ганһага, Хуҗа Баһаветдин[17],

---

[1] Әүляд – Мөхәммәд саллэллаһу галәйһи вә сәлләмнең балалары.

[2] Әһле бәйт – Мөхәммәд саллэллаһу галәйһи вә сәлләмнең гаилә әһелләре.

[3] Әнбия – пәйгамбәр.

[4] Әүлия – изге.

[5] Чаһрияр –дүрт дус, Мөхәммәд саллэллаһу галәйһи вә сәлләмннән соң идарә иткән дүрт тугры хәлифә.

[6] Газиз – изге, пәйгамбәр.

[7] Мәшаех – шәех сүзенең күплек саны.

[8] Сәхабә – Мөхәммәд саллэллаһу галәйһи вә сәлләмне күреп белгән аркадашлары, фикердәшләре.

[9] Әхмәт – кайдан килеп чыгуын белә алмадык. Хуҗа Әхмәт Ясәви (?).

[10] Гаип ирәне – күзгә күренми торган изге.

[11] Караеш ялан – кайдан килеп чыгуын белә алмадык

[12] Кыйтмир көчек – җәннәткә керәчәк хайваннарның берсе.

[13] Гамбәр ана – Урал яны татарларында бала табучы хатыннарга ярдәм итүче изге.

[14] Ислам динендә пәйгамбәрләрнең аналары, хатыннары һәм якыннары булган унбер хатын-кыз. Шулар арасында Хәүва ана, Мәрьям ана да бар.

[15] Зәүҗәт мотаһһәралары – никахлы хатыннары.

[16] Фатыйма разыйаллһу ганһа – Мөхәммәд саллэллаһу галәйһи вә сәлләмнең кызы

[17] Хуҗа Баһаветдин – суфиХуҗа Баһаветдин Нәкышбәнди (1318–1389).

Зәнки бабайга[1], Чулпан атага[2], Мөшкил-шад кызга[3], барча якыннарына, Сөләйман, Идрис, Хызыр галәйһиссәламнәргә ирештер, Ходаем.

Газиз әти-әниемнәргә, кайнана-кайнаталарыма, ата-бабаларыбызның, җиде буынга кадәр булган кыз туганнарыма, ир туганнарыма, исемсез киткән, кан белән киткән сабыйларымның рух шәрифләренә кабул кыйл.

Барчасының бәндәчелек белән кылган гөнаһларын ярлыкыгыл. Җаннарын изге кыл, тулы-нурлы иманнарын мәңге бакый юлдаш кыйл. Кабер газапларыннан коткар. Үзеңнең рәхмәтле урыннарыңа ирештер.

Үзебезнең калган гомерләребезне бәрәкәтле кыйл. Иманнарыбызны таза кыйл. Тоткан уразаларыбызны, кылган гамәлләребезне кабул кыйл, заядан кыйлма.

Изгелекләребезнең хәерле әҗерләрен насыйп ит. Шатлыклы-тыныч изге бәхет капуларыбызны ач. Әй Раббым, тулы сәламәтлекләребезне биреп, хәерле шатлыклар, тыныч көннәргә ирештереп, уйламаган җирләрдән, гаип хәзинәләреңнән исәпсез-хисабсыз хәерле, хәләл ризыклар, нигъмәтләр, киң дәүләт насыйп кылып, үзеңә изге гамәлләр кылырга насыйп кыйл, Ходаем.

Барчабызның камил гакылларыбызны, күркәм сабырлыкларыбызны, күркәм холыкларыбызны, тулы зиһеннәребезне насыйп кыйл.

Истикамәт[4], һидаять[5], тәүфикъ, миһербан-шәфкатьләребезне насыйп кыйл. Кешеләр арасында мәхәббәтле, сөйкемле кыйл. Йөргән юлларыбызны уң кыйл, сөйләшкән сүзләребезне өстен кыйл.

Барча хәрәм ашлардан, нәфесләлекләрдән үзең тый, Ходаем. Тоткынлыкларга дучар итмә, караңгылыкларга, тарлыкларга, хурлыкларга салма.

Шайтан шәреннән[6] үзең сакла.

Дошманнарга ирек бирмә, үз дошманлыкларын үзләренә кайтар.

Барча хәвеф-хәтәрләрдән, бәла-казалардан үзең сакла. Үзеңнең рәхмәтеңнән ташлама. Күңел шатлыкларыбызны, җан тынычлыкларыбызны насыйп кыйл, тигезлек-бәхетләребездән аерма.

Балаларыбызның иман-тәүфикъларын бир. Ислам динен мәхәббәтле кыйл. Игелекле балалар булсыннар. Барысы да тулы бәхет, мәхәббәт белән яшәсеннәр, тигез бәхетләрен ач.

Икенче текст Татарстанның Кама Тамагы районы Олы Бортас авылында Шаһиева Асия Харис кызыннан 2006 елда язып

---

[1] Зәнки бабай –төрки халыкларда изгеләштерелгән образ. Эре терлекләрне саклый торган изге.

[2] Чулпан ата – төрки халыкларда изгеләштерелгән образ. Сарыкларны саклый торган изге.

[3] Мөшкил-шад кыз – Биби-Мүшкилкуш, авырлык килгәндә ярдәмгә килә торган изге. Ислам мифологиясе буенча суфый Хуҗа Баһаветдин Нәкышбәндинең апасы санала.

[4] Истикамәт – турылык, дөрес юнәлеш

[5] Һидаять – туры юл.

[6] Шайтан шәре – шайтан явызлыгы, зарары.

алынды. Бу текст мәҗүсилектән калган шактый гына ышануларны саклый, еш кына мөселман һәм мәҗүси культлар кушылып китәләр. Шул ук вакытта ул Болгар дәверен, Шәһри Болгарны, аның халкын изгеләштерүе, ягъни татар халкының Болгарга мөнәсәбәтен күрсәтү ягыннан да кыйммәтле чыганак.

**Багышлау**

И Ходаем, ушбу укыганнарымны багышладым үзеңнең ризалыгың өчен, Мөхәммәт галәйһиссәлам хакы-хөрмәте өчен, өч йөз сәхабәләр хакы-хөрмәте өчен, атабыз Адәм, анабыз Һәува хакы-хөрмәте өчен, әүвәле Әбү Бәкер Сыйддикъ, аннары Гомәр, өченчесе Госман, дүртенче Гали[1] разыйаллаһу ганһләр хакы-хөрмәте өчен. Ушбу укыганнарымны багышладым унбер ана, Әхмәт хакы-хөрмәте өчен, су атасы Сөләйман, су анасы Сылубикә[2] хакы-хөрмәте өчен, җирдәге вә күктәге фәрештәләр өчен, өч йөз алтмыш изгеләр хакы өчен, өч йөз алтмыш биш гаип ирәннәре өчен, өч йөз унөч мөрсәл[3]-пәйгамбәрләр хакы өчен, җиде әүлияларга, җиде әнбияләргә, җиде султаннарга, туксан тугыз мәшаехләргә, кырык бер кабер әһелләренә, көн ирәннәренә, төн ирәннәренә, гаип ирәннәренә, нигез хуҗаларына, киртә хуҗаларына, гарипләргә, зәгыйфьләргә, заһидләргә-заһидәләргә[4], кыр ирәннәренә, су ирәннәренә, Кабан күлендәге Фәйзулла әфәнде белән Галиәкбәр хуҗаларга[5], Чабыр тау изгеләренә[6], Шәһри Болгар изгеләренә.

Өченче һәм дүртенче текстлар 2012 елда Удмуртия республикасында узган экспедиция вакытында Глазов районы Татар Парҗысы авылында Бузикова Фәйрүзә Гайнан кызы биргән язмадан алынды. Бу текст эчтәлеге белән мөнәҗәтләргә якын, информантлар дога дип атый торган әсәрләрнең бер үрнәге.

И Ходаем, үзең сакла
Сән безләрне бәла белән казадин.
Мәхрүм кылмаса безләрне ата
берлән анадин.
Дәһил[7] берлән дәрман бир,
Тәүфикъ берлән иман бир,
Хәерле эшкә хәрәкәт бир,
Ашыбызга бәрәкәт бир,
Малыбызга өлеш бир,
Җаныбызга тынычлык бир,
Бездән борын үткәннәргә,
Дога өмет иткәннәргә
Бер «әлхәм» белән өч «колһуаллаһ»
савабын бир.
Амин!

[1] Әбү Бәкер Сыйддикъ, Гомәр, Госман, Гали – дүрт хәлифә.

[2] Су атасы Сөләйман, су анасы Сылубикә – татар мифологиясендә су хуҗаларының исемнәре дә саклана.

[3] Мөрсәл – пәйгамбәр.

[4] Заһидләр һәм заһидәләр – аскетлар, дөнья рәхәтлекләреннән ваз кичеп, гомерләрен гыйбадәттә үткәрүчеләр, изгеләр.

[5] Кабан күлендәге Фәйзулла әфәнде белән Галиәкбәр хуҗалар – Кабан күлендәге изгеләр санала.

[6] Чабыр тау изгеләре – Кама Тамагының Келәнче авылы янындагы тау. Анда Болгар чорында илне саклап шәһид киткәннәрнең – изгеләрнең каберләре булган дигән ышану бар.

[7] Дәһил сүзе фарсы яки гарәп теленнән кергән сүз булырга мөмкин. Мәгънәсен таба алмадык.

* * *

Бисмилләһир-рахмәәнир-рахиим.
И Ходаем, ошбу фани дөньяда,
дус-дошманым арасында
Мән мескенне хур итмә,
Бәхетемне ким итмә.
Көннин-көнгә тәүфикъ бир.
Барча мөселманнарның ахыр
сулышына кадәр иман бир,
Алар белән мән колыңны бергә кыл.
Бу дөньядан күчәрбез,
башсыз атка менәрбез.
Башсыз атка менгәндә
иманымны баш әйлә,
намазымны юлдаш әйлә.
Тар кабергә кергәндә,
сorугылар сурганда[1] җавабымны
үзең бир.
Тар каберем киң ит,
караңгысын якты ит.
Таразыга[2] сурганда җавабымны
авыр ит,
гөнаһымны җиңел ит.
Сыйрат күперен кичкәндә аягымны
тайдырма.
Атабыз Адәм илә анабыз Хәүва
йөзен күргез,
Гайшә илә Фатыйма йөзен күргез.
Я Рабби, рәхмәтең илә гөнаһыла-
рыбызны ярлыка.
Рәхмәт кылсаң, рәхмәтең бар,
Каһәр кылсаң, кодрәтең бар,
Рәхмәтеңнән өметем бар,
Каһәреңнән куркуым бар.
Колларыңа кол итмә,
Дошманыңа хур итмә,
Шайтаныңа яр итмә.
Изге колларыңнан аерма.
Яман сагыш тотмактан күңлем
сакла,
Җиде әгъзамны сакла, я Рабби.
Иманымны үзең сакла.
Шөкер кыламын барлыкка,
Төшермә безне тарлыкка,
Барчабызны ярлыка,
Яраткучы Җәббар[3]
Сән саклаучы Саттар[4],
Сән сакла, Ходам.

2017 елда Казактанның Семей (Семипалатинск) шәһәрендә узган экспедиция вакытында да шактый гына материал язып алынды. Семей шәһәрендә яшәүче Ибраһимова Рәйхангөл Закир кызы да әбисеннән өйрәнгән дини эчтәлекле шигъри әсәрне яхшы белә. Бу догаларны әбием сөйли иде, без кабатлап ята идек, дип искә ала Рәйхангөл апа. Әлеге текст Удмуртия тексты белән аваздаш булса да, һәр икесенең дә үзенчәлекле строфалары да күп. Шуңа күрә икесен дә бирүне урынлы дип саныйбыз.

Илаһым, хур кылма,
Талигымны[5] ким кылма.
Көннән-көнгә бәхет бир,
Көннән-көнгә тәүфикъ бир.
Каһәр кылсаң, каһәрең бар,
Каһәреңнән куркарым бар.
Рәхмәт кылсаң, рәхмәтең бар,
Рәхмәтеңнән өметем бар.
Колларыңа кол итмә,
Шайтаныңа яр итмә.
Туби агач[6] төбиндин,

[1] Соругылар сурганда – сораулар сораганда (архаик вариант).
[2] Таразы – үлчәү, кешенең яхшылыгы һәм яман эшләре салыначак үлчәү, мизан.
[3] Җәббар – кодрәтле, Аллаһының күркәм исемнәренең берсе.
[4] Саттар – гафу итүче, Аллаһының күркәм исемнәренең берсе.
[5] Талигъ – бәхет.
[6] Туби агач – туба агач, оҗмах агачы.

Тудәиңнең[1] туендин
Мәхрүм кылма илаһым.
Таразыга барганда,
Гамәлемне авыр ит,
Гөнаһымны җиңел ит.
Сыйрат күперен кичкәндә
Аягымны тайдырма.
Фатыймага юлдаш кыл,
Илаһым, шөкер иттем барлыгыңа,
Төшермә мине тарлыгыңа.
Дәүри[2] белән дәүран[3] бир,
Бакый белән иман бир,
Хәерле эшкә хәрәкәт бир,
Башыбызга бәрәкәт бир,
Бездән борын үлгәннәргә,
Бездән дога көткәннәргә
Бер Әлхәм, өч Колхуалланың
савабын бир.

Семей шәһәрендәге икенче информантыбыз Насыйрова Гөлфия Хәбибрахман кызы яздырган текст та татарлар яши торган төбәкләрдә популяр әсәрләрдән булган. Гөлфия апа бу текстларны әбисеннән өйрәнүен әйтә. Әбинең әйтә торган сүзләре бар иде: «Ары дөньяга барганда сорак бирерләр. Шул соракларга син җавап бирергә тиешсең, – дип. – Шул соракларга син җавап бирергә өйрән», – дип әйтә иде. Шулай җавап бирергә тиешсең, дип әйтә торган иде миңа әби.

– Бердән ни дип beләсең?
– Бер Аллам дип беләмен.
– Икедән ни дип беләсең?
– Ике иңемдәге фәрештә дип
беләмен.
– Өчтән ни дип беләсең?
– Өч витрны дип беләмен.
– Дүрттән ни дип беләрсең?
– Дүрт бурычлы Коръән дип
беләмен.
– Биштән ни дип беләсең?
– Биш мизгеллек намаз дип
беләмен.
– Алтыдан ни дип беләсең?
– Ата-ана хакы дип беләрмен.
– Җидедән ни дип беләрсең?
– Җиде тәмуг дип беләрмен.
– Сигездән ни дип беләрсең?
– Сигез җомах дип беләрмен.
– Тугыздан ни дип беләрсең?
– Туксан тугыз мәриб белән
мәшрикъ дип беләрмен.
– Уннан ни дип беләрсең?
– Уңлы-суллы сәлам дип беләрмен.

Семей шәһәрендә Абдулкәримова Галия Хәмит кызыннан язып алынган текст та әби-бабаларыбыз барыбызга да өйрәткән әсәрләрдән.

Башым куйдым ястыкка,
Күңлем бирдем Аллага.
Алла-Алла дигәндә
Караңгы гүрем яктырсын.
Сөбханалла дигәндә
оҗмах ишеге ачылсын!

Семей шәһәреннән ерак түгел Аккүл авылында яшәүче Измаилова Гөлчирә Сәетәхмәт кызыннан язып алынган текст та күбебезгә таныш.

Яттым, я Аллаһ!
Торырмын, иншааллаһ!
Иман белән ятаем!
Ислам белән тораем.
Бу җатканнан торалмасам,
Иман байлыгын бир, Аллаһ!

---

[1] Тудәи – мәгънәсен таба алмадык.
[2] Дәүри – бай, җитеш.
[3] Дәүран – чор, гомер.

Алтай өлкәсе Угловский районы Бөкер авылында Баһавиева Фатыйма Нургата кызыннан да яхшы теләкләр – алкышлар язып алынды. Хәзерге вакытта татар фольклорында бу жанр өйрәнелмәгән.

**Алкышлар**

Гомерлек мәхәббәт бирсен,
Бетмәс дәүләт бирсен,
Акылларыгыз ашсын,
Бәхетләрегез ташсын,
Һич яманлык булмасын,
Аман булсын йорт-җирләрегез,
Алла Тәгалә диннәрегезгә саулык бирсен,
Дәстәрхәнегезгә байлыгын бирсен,
Ахирәттә иман бирсен,
Терелектә тәүфикъ бирсен,
Бирәхмәтикә
Йә әрхәмәр рахимиин.
Илаһи, амин! Илаһи, амин!
Аллаһ әкбәр, амин,
Аллаһ әкбәр, амин.

Чәегез кызыл булсын,
Гомерегез озын булсын,
Дәүләтегез таша бирсен,
Дошманыгыз кача бирсен,
И Ходаем, үзегезгә озын гомер яза бирсен.
Илаһи, амин! Илаһи, амин!
Аллаһ әкбәр, амин,
Аллаһ әкбәр, амин.

Бисмилла ирахман ираһим,
Йа раббы Ходаем,
Безнең хушыбызга керешеп,
Безнең арабызда йөрерлек булсын,
Йа рабби Ходаем,
Тынычлык белән, хәерле ризык белән,
Хәерле тормыш белән,
Йа рабби үзләребезгә,
Мал туарларыбыз аман булып,
Йортларыбызга сәламәтлек биреп,
Сабырлык белән яшәргә насыйпка ирештерсен,
Илаһи, амин! Илаһи, амин!
Аллаһүммәгъфирли,
Фәгъфирли,
вәли-вәлидәйнә,
вәли җәмигол мөэмининә
вәл мөэминәт,
вәл мөслиминә, вәл мөслимәт,
вәл моңзиләл бәрәкәт,
вә рафигад-дәрәҗәт,
вә казиел-хәҗәт.
Амин.
Бирәхмәтикә йә әрхәмәр рахимиин. Илаһи, амин.
Илаһи, амин, илаһи, амин!
Аллаһ әкбәр, амин,
Аллаһ әкбәр, амин.

Бу текстларны бер үзенчәлек берләштерә: аларның барысында да кеше үзенә, якыннарына, туганнарына изге теләкләрен юллый, Алладан бу кешеләргә итагатьле-шәфкатьле, иманлы, әхлаклы булып яшәргә юл күрсәтүен, мәрхүмнәрнең рухларын шат итүне, урыннарын җәннәтле итүне, гөнаһларын ярлыкауны сорый. Аларда халыкның кешелекнең иң зур кыйммәтләре турындагы карашлары саклана. Бу – гаделлек, кешелеклелек, ярдәмчеллек, юмартлык, тугрылык, тырышлык, белемгә омтылыш, инсафлылык, олы җанлылык кебек әхлакый сыйфатлар.

Барыбызга да изге теләктә, яхшы уй-фикердә булып яшәргә язсын!

***Закирова Илсөяр Гамил кызы,***
*филология фәннәре докторы, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре*

УДК 398.4

*Л.Х. Дәүләтшина*

# ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ МИФОЛОГИК СИСТЕМАСЫНА БЕР КАРАШ

В статье рассматриваются мифологические представления татар как часть общетюркской мифологии, проводится последовательный анализ источников и научной литературы для описания персонажей высшей и низшей мифологии, привлекается богатый полевой материал для характеристики современного состояния мифологической системы татар. Народная демонология рассматривается автором как многосоставная система, включающая не только ряд персонажей, но и весь круг основных мотивов и сюжетов, связанных со сферой «низшей» мифологии.

**Ключевые слова:** традиционная культура, мифология, персонаж, высшая мифология, народная демонология, поверье.

Төрки-татар мифологиясенең тарихын һуннардан башлау кабул ителгән. Һуннарның тарихын, мәдәниятен, мифологик карашларын чагылдырган чыганаклар нигездә кытай, грек, әрмән авторларына карый. Кытай хроникалары XIX гасырда Н.Я. Бичурин (Иакинф) тарафыннан рус теленә тәрҗемә ителә [Бичурин, 1950, т. 1], текстологик тикшеренүләр үткәргән Н.В. Кюнер [Кюнер, с. 7–8] билгеләвенчә, әлеге мирас бүгенге көндә дә иң төгәл хезмәтләрнең берсе булып кала. Кытай чыганакларында төрки кабиләләрнең килеп чыгышына бәйле генеалогик легендалар, дәүләт төзелеше, йола-гадәтләренә бәйле мәгълүматлар теркәлсә, әрмән чыганаклары (Лазарь Парбский, Малала, Феофан Исповедник, Мовсес Каланкатуаци, VII гасыр әрмән географиясе һ.б.) V–VII гасырларда Төньяк Кавказ һәм Каспий буйларын иңләгән «гун иленең» тарихын һәм мәдәниятен ачыклый. «Гун иле»нең мифологик күзаллауларын чагылдырган хезмәтләр арасында иң бай мәгълүмат туплаганы – әрмән тарихчысы Мовсес Каланкатуациның «История страны алван» хезмәте. 682 елда христиан миссиясе белән Каспий буе территориясенә килгән тарихчы язып алган мәгълүматлар борынгы төрки аллалар пантеонын, төркиләрнең дини-мифологик карашлар системасын реконструкцияләргә мөмкинлек бирә [Гмыря, с. 5].

Тарих фәнендә һуннар ике исем астында йөри: Азия һуннары (хунн/хунну) һәм Европа һуннары (гунн) [Гумилев, 1998, кн. 1, с. 266]. Хуннар дип б.э.ның II гасырына кадәр Үзәк Монголия һәм Байкал арты далаларында яшәгән этноска әйтәләр. Ә гуннар дип Бөек халыклар күчеше вакытында Каспий буе Дагстан территориясенә килеп чыгып, шунда бер-ике гасыр яшәп, угыр, сармат кабиләләре белән аралашып, шуның нигезендә физик кыяфәтләрен үзгәртеп, асыл-

да яңа этноска әверелгән, әмма төрки телләрен саклап калган кабиләләрне күздә тоталар [Дәүләтшин, б. 17]. Һуннар һәм Борынгы Төрки каганлыгындагы дин, мифологик карашлар хакында шактый язылган инде [Гумилев, 1993; Кляшторный, 1964; Кляшторный, 1977; Потапов, 1991; Стеблева, 1972]. Һуннар затка әйләндерелгән галәмгә, күккә табынганнар. Бу чордагы чыганакларда әле Тәңре исеме очрамый, әмма Төрки каганлыгында киң таралыш алачак тәңречелек диненең оешып килүе инде билгеле була. Һуннарда чыгып килүче кояшны каршы алуның махсус ритуалы да булган. Алар иртән чыгып килгән кояшны баш иеп сәламләгәннәр [Гумилев, 1967, с. 59].

Кытай чыганакларында («Хань-шу»да) күрсәтелгәнчә, һуннар гадәт буенча елына өч мәртәбә Лун-цы храмында (лун – аждаһа) беренче, бишенче һәм тугызынчы айларда, Сюй дигән көндә, күк, җир һәм үзләренең рухлары хөрмәтенә корбан чалу йоласы үткәргәннәр. Һуннарның иң зур бәйрәме кытай календаре буенча бишенче айга, якынча май ахырына һәм июнь башына туры килгән [Бакиров, б. 20; Алексеев, с. 214]. Һуннарга кагылышлы кытай чыганакларына караганда, «шаньюй (һуннар башлыгы) һәрчак шаманнардан аяклары бәйләнгән атлар белән ырым ясата торган булган» [Бакиров, с. 21; Материалы..., вып. II, с. 15].

VI гасырда Каспий буе Дагстан территориясенә килеп чыккан көнбатыш гуннары да Тәңрихан (Тенгри-хан), яшен алласы Гуар/Куар һәм җир рухы хөрмәтенә корбан чалу йоласы үткәрә торган булганнар. Тәңре-ханга корбан чалу йоласы аның үзен гәүдәләндерә торган биек агачлар үскән изге урманнарда (роща) үткәрелгән. Биредә аңа багышлап атлар чалганнар, аларның каны белән җирне туендырганнар, башларын һәм тиреләрен агач ботакларына элгәннәр, ә гәүдәләрен учакта яндырганнар [Каланкатуаци, с. 193–194, 200–201]. Шул ук вакытта Төньяк Кавказ гуннарының пантеонында Куар алласы булуы да билгеле. Тәңре-ханнан кала икенче рангтагы әлеге алла кояш/яшен алласы буларак күзалланган, һәм яшен суккан кешене яки хайванны гуннар Куар алласының корбаны дип исәпләгәннәр [Каланкатуаци, с. 200–201].

Һуннарның мифологик карашларында чагылыш тапкан пантеон VI–VII гасырларда Алтай, Көнбатыш Себер һәм Төньяк Монголия җирләрендә яшәгән Төрки каганлыклар дәверендәге Орхон-Енисей язмаларында ачыкланган дини-мифологик система белән тәңгәл килә. С.Г. Кляшторный фикеренчә, гунн – борынгы төрки – праболгар пантеоннарының тәңгәллеген һәм праболгар кабиләләренең (теле кабиләләре союзы) Үзәк Азия территориясеннән V гасырдан да калмыйча китүләрен исәпкә алганда, фәндә «борынгы төрки пантеон» дип исемләнгән катлаулы дини-мифологик системаның б.э. I меңьеллыгының уртасына кадәр формалашып бетүе шик тудырмый [Кляшторный, 1978, с. 62].

Борынгы төркиләр күзаллавында, Себер-Урта Азия мифо-

логияләрендәге кебек үк, дөньяның вертикаль моделе Югары, Урта һәм Җир асты өлешләреннән гыйбарәт. Урта дөнья белән Изге Җир-Су («Ыдук Йер-Суб») хакимлек итсә, Җир асты дөньясы «кешеләрне бер-берсеннән аеручы» һәм аларга «үлем хәбәрчеләрен җибәрүче» Эрлик-ханга буйсынган [Кляшторый, 1979, ч. 2, с. 91–95]. Югары дөньяның хуҗасы һәм борынгы төрки пантеонның югары алласы – илаһи Күк буларак кабул ителгән Тәңре кешеләр язмышы белән идарә итә, «күк түркләрнең яшәү рәвешен билгели», каганнарга акыл һәм хакимлек сыйфатларын бүләк итә һ.б. Төрки дәүләтләрдән мирас булып калган ташъязма истәлекләрдә, бигрәк тә Күлтәгингә багышланган Кече һәм Зур язмаларда, Тоньюкукка атап язылган язмада Тәңренең вазифалары ачыкланып бетә. Күк, Тәңре белән бәйле борынгы төркиләрдән калган карашлар Идел болгарларында да дәвам итә. Аның исеме Кол Галинең монгол яуларына кадәр язылган «Кыйссаи Йосыф» поэмасында һәм болгарларның XIV гасырга караган каберташ язмаларында очрый [Урманчеев, б. 42–43]. Тәңре культы төрки һәм төрки-монгол халыклары яшәгән киң территориядә таралыш таба, хәтта XI гасыр галиме М. Кашгари әле ислам динен кабул итмәгән төркиләрнең «биек тауларны», «олуг агачларны» «Тәңре» дип атауларын яза [Дәүләтшин, б. 76].

IX–X гасырларда ислам дине рәсми рәвештә кабул ителеп, халык арасында да таралгач, Тәңре исеме, әкренләп, Алла исеме белән алыштырыла. Ислам белгечләре фикеренчә, «Тәңре төрки телләрдә Аллаһ сүзе белән бер үк мәгънәдә кулланыла» [Ислам, б. 151], вазифаларының уртаклыгы тәңречелек тәгълиматының ислам дине белән органик рәвештә керешеп китүенә китерә.

Югары дөнья алиһәсе Умай хатын-кыз башлангычын гәүдәләндерә һәм Тәңренең илаһи хатыны дип исәпләнә. Ул «кеше улларының» тууы белән идарә иткән, яңа туганнарның, сугышчыларның яклаучысы булган, аның белән бәйле ышанулар төрки халыкларның күбесендә бүгенге көнгә кадәр килеп җиткән. Л.П. Потапов мәгълүматларына караганда, сагайлар, шорлар һәм билтерләрдә Умай – сабыйның, туган көненнән башлап, өч яшенә кадәрге җаны [Потапов, 1973, с. 271]. Татар халык мәдәниятендә Умайга бәйле ышануларның берничә кыйпылчыгы гына сакланып калган: Казан татарларында умай дип хатын-кызның аналыгын яисә бала урынын атыйлар [Брусько, с. 204]; Себер татарларында Умайны баланың кендеге белән тиңләштерәләр [Урманчеев, б. 44].

Урта дөньяның төп алласы Җир-су – җир, су культы белән бәйле булган һәм төркиләрнең яклаучысы, гөнаһ-гаепләре өчен җәза бирүче дип каралган. Византия тарихчысы Феофилакт Симокатта «борынгы төркиләр җиргә дан җырлыйлар» дип язган [Дәүләтшин, б. 59], кытай чыганакларында төркиләр тарафыннан илаһи дип кабул ителгән тау «җир алласы» дип аталган. Алтайлылар карашынча,

Җир-Су – 17 ярдәмчел рухалланың гәүдәленеше; алар карлы тау башында һәм елгаларның башланган җирендә гомер кичерәләр [Татар мифологиясе, б. 65]. Гомумән алганда, Җир-Су – табигать күренешләренең (тау, урман, елга, күл һ.б.) хуҗасы. Төрки халыклар мифологиясендә мондый рухлар ияләр дип атала, алар рух-хуҗа функциясен башкарып, төрле табигать объектларын саклап торалар. Идел буе, Урта Азия, Төньяк Кавказ, Көнбатыш Себер, Алтай һәм Саян таулары буенда яшәгән төрки телле халыклар мифологиясеннән дә бу күренешкә мисаллар табарга мөмкин [Мифологический словарь, с. 672].

Татар традицион мәдәниятендә югары мифологиягә кагылышлы күзаллаулар системасы көндәлек яшәештән төшеп калса да, бүгенге көндә татар халкының мифологик ышануларын реконструкцияләү өчен кызыклы чыганак ролен «түбән мифология», ягъни алла статусына ия булмаган ияләр, кара көчләр, рухлар, йола-гадәтләр, ышанулар, кешенең көндәлек яшәеше белән бәйле мифологик мәгълүмат үти. Ияләр табигать объектларының, кеше яши торган торак урыннарының хуҗасы буларак кабул ителәләр һәм, күңелләрен күрә белсәң, кешегә файдалы затлар буларак күзалланалар. Җен, албасты, убыр, өрәк, шүрәле һ.б. шундый түбән рухлар адәм баласының тормышында туган күңелсезлек, бәхетсезлек, акылдан язу кебек күренешләрнең сәбәпчесе буларак тасвир ителәләр. Түбән мифология персонажлары турындагы текстлар татар халкының төрле этник традицияләрендә күптөрле локаль вариантларда бүген дә саклана, бу төр текстлар экспедицияләр барышында күпләп язып алына.

Түбән мифология персонажларының бер өлешен тәшкил иткән ияләр табигать объектларына һәм кешенең торак-яшәү урынына бәйле, ягъни шуларның хуҗалары рәвешендә фараз ителәләр. Әлеге персонажлар белән бәйле текстлар рус фольклористикасында мифологик проза кысаларында өйрәнелә. Бу өлкәдә беренчеләрдән булып, Э.В. Померанцева түбән мифология персонажларына бәйле мөһим мәсьәләләрне күтәрә, рус фольклористикасында мифик зат белән очрашу мотивына корылган «быличка» һәм «бывальщина» (татар фольклористикасында – сөйләк, мифологик хикәят; башкортларда – хорафати хикәяләр һ.б.) дип аталган жанрларның хасиятләрен билгели һәм тематик классификациясен төзи. Галимә йорт тирәсендәге рухлар, табигать рухлары һәм черт дип исемләнгән өч тематик категориягә күрсәтә [Померанцева, с. 4]. Россия территориясендә яши торган халыклар фольклористикасында әлеге юнәлеш киң үсеш ала: мифологик хикәятләр кергән фольклор җыентыклары басыла (В.П. Зиновьев, Н.А. Криничная, К.Э. Шумов, О.А. Черепанова); билгеле бер этник традициянең мифологик күзаллауларын өйрәнүгә багышланган махсус хезмәтләр языла; мифологик сүзлекләр төзелә (М.Н. Власова, Ф.Г. Хисаметдинова, Ф.И. Ур-

манче); мифологик мотив күрсәткечләре эшләнә (С.М. Лойтер, Д. Климова); мифологик лексиканы анализлаган этнолингвистик хезмәтләр басыла (Н.И. Толстой, О.А. Черепанова, Е.М. Назарова, Е.Е. Левкиевская, Н.А. Архипенко, Ф.С. Баязитова һ.б.).

Йорт-каралты белән бәйле рух-хуҗалар арасында өй (йорт), абзар һәм мунча ияләрен атарга кирәк. Әлеге хезмәттә төп игътибар, йорт (өй) һәм абзар хуҗаларына юнәлтелә, чөнки алар функцияләре ягыннан бүгенге көндә иң актив персонажлар буларак тасвир ителәләр, ә мунча иясе турындагы карашлар бик аз һәм аны тулы бер мифик зат буларак күз алдына китерерлек түгел.

Йорт-каралты хуҗаларына (*йорт иясе, җорт хуҗасы, җорт бабай, өй анасы, Гамбәр ана, Дәсимә тути, кырсут, ызба иясе* һ.б.) ышану — татар халкының төрле этник төркемнәрендә киң таралган күренеш. Бу ияләшелгән, гадәти персонаж әллә ни куркыныч хәлләр белән бәйләнмәгән, шуңа күрә аның турындагы текстлар катлаулы, киңәйтелгән сюжетка корылмый. Бу төр персонажның төп гамәлләре – хуҗалыкта иминлекне саклау, үзе яраткан йорт хайваннарына ярдәм итү яки, киресенчә, яратмаган тереклек иясенә зыян салу, йортка бәла киләсе булса, алдан хәбәр бирү һ.б. Йорт иясе өйне бәла-казадан саклый, төннәрен чыгып, ихатаны карап йөри, йоклап калган хуҗаларны уята, кайгы-хәсрәт киләсе булса, алдан кисәтә [Давлетшина, 2015, с. 1023]. Әгәр дә төнлә йон эрләгәнне ишетсәң, бай булырсың, чабата үргәнне ишетсәң, хәерчелеккә төшәрсең, ди халык. Йорт иясе белән яхшы мөнәсәбәт урнаштыру өчен, аны ашатырга, аның белән сөйләшеп йөрергә, даими сәдака бирергә кирәк. Хуҗалар яңа йортка күченсәләр, йорт иясен дә үзләре белән алырга тиеш. Бу йола төрле төбәктә төрлечә башкарыла: йорт иясен я җәяүләп, я ат арбасына утыртып алып баралар, яңа нигезгә күченгәч, аңа атап аш үткәрәләр һ.б.

Татарларның традицион күзаллавы буенча хуҗалыкта өй иясе белән янәшә мөстәкыйль персонаж буларак күзалланган мал-туар хуҗаларына да (*хайван хуҗасы, Мәхүбә тути, абзар хуҗасы, ат иясе, аран иясе, киртә иясе* һ.б.) урын бар. Кайбер информантлар, һәр хайванның үз хуҗасы бар, диләр, әмма моңа мисаллар бик аз, күпчелек очракта аерма исемнәрдә генә күзәтелә. Әлеге персонажның тышкы кыяфәте хакындагы сыйфатламаның аз булуы «абзар иясе белән очрашсаң, аны качырасың һәм бәхетсезлеккә юлыгасың» дигән ышануга бәйле булса кирәк. Информантлар фикеренчә, һәркөн иртән абзарга кергәндә, хуҗа кеше, абзар иясенә качарга мөмкинлек бирер өчен, тамак кырырга тиеш. Шул ук вакытта аңа ниятләп дога уку һәм сәдака бирү дә гадәткә кергән. Гомумән алганда, мал-туар хуҗасы кешеләргә карата тискәре мөнәсәбәт белдерми, ул мәрхәмәтле, изге рух.

Мал-туар хуҗалары турындагы күзаллаулар комплексында татарлар арасында киң таралыш алган Зәнги бабай атамасы

игътибарны җәлеп итә. Себердә яшәгән татарлар хәтерендә саклanучы мөселман изгеләре культын тикшергән галимнәр Зәнги ата турындагы ышануларның Урта Азия һәм Идел буенда киң таралыш табуын дәлиллиләр. Әлеге персонажның асылында XIII йөздә яшәгән һәм С. Бакырганидан соң аның хатыны Гамбәр анага өйләнгән легендар зәнки дәрвиш [Яхин, б. 125] яки суфи шәехләрнең чынбарлыктагы тарихи прототибы Зәнги ата булырга тиеш. Риваятьләрдә ул Ташкент якларында көтү көткән, йөзгә-биткә тупас чалымлы, кара тәнле кеше буларак сурәтләнә. Аерым риваятьләр буенча, Зәнги ата һәм аның фикердәшләре Алтын Урдада ислам динен таратуда хәлиткеч роль уйнаган дип исәпләнелә [Культ святых, с. 85–86].

Халык телендә бу персонажны «Зәнки бабай» дип йөртәләр. Татар халкы малларның күпләп үрчүе, көр һәм сөтле булуы әлеге рухка бәйле дип әле дә ышана. Мал суйганда, «Зәнки бабай хөрмәтенә» дип әйтәләр, маллар көтүдә исән-сау йөрсен дип, Зәнки бабай рухына хәер бирәләр, аңа дип махсус ипи пешереп абзарга куялар һ.б. 1995 елда дини календарьда басылган юл догасында Зәнки бабай яклаучы буларак телгә алына: «И раббым! Бу сәфәремә мин сиңа ышанып, үземне сиңа тапшырып чыгам. Син миңа үзеңнең рәхмәтеңне сал, Хозыр галәйһиссәламне юлдаш кыл, Зәнки бабайны сакчы кыл» [Гыйльманов, б. 223]. Татарлар арасында Зәнки бабайга бәйле ышанулар ислам дине, суфичылык тәгълиматына бәйле рәвештә таралыш тапса да, тарихи персонажның функцияләре бу очракта үзгәреш кичереп, татар халкының мифологик күзаллаулар системасына органик рәвештә кереп китә һәм яңа ракурста ачыла.

Табигать культлары белән бәйле рух-ияләргә килгәндә, татарлар арасында төрле вариантларда аталып йөртелгән Хозер Ильяс (*Хызыр, Хозер, Хозер бабай, Хызыр Ильяс* һ.б.) хезмәттә функциональ яктан борынгы төрки традициядә җир һәм су стихиясе белән идарә итә торган персонаж, һәм ислам тәгълиматы аша килеп кергән Хозер / Ильяс пәйгамбәрләрнең кушылуы нәтиҗәсендә барлыкка килгән мифик зат буларак тәкъдим ителә. Хозер исеме Коръәндә аталмаган, әмма Рабгузи һәм Коръән тәфсирләрендә аңлатылганча, 18 нче сүрәнең 64 нче аятендә сүз Хозер хакында бара [Садекова, с. 133]. Халык ышануларында Хозер Ильяс юлчыларга юлдаш, адашкан кешеләргә ярдәм итә торган ак сакаллы карт буларак ачыклана. Татар халкында киң таралыш тапкан шундый риваять бар: бервакыт хәлле кешеләр яши торган авылга таякка таянган, ап-актан киенгән бер бабай килеп керә. Ул йортларга кереп, ризык сорый, әмма аны куып чыгаралар, этләрдән талаталар. Карт авылдан көч-хәл белән чыгып котылгач, бөтен йортлар да су төбенә китә. Авыл кешеләре куып чыгарган картның исеме Хозер Ильяс булган, дип сөйли халык. Бу сюжет Татарстанда гына түгел, башка регионнарда да очрый.

Экспедиция вакытында Хозер Ильясның эш-хәрәкәтләре буенча табигать күренешләрен фаразлаганнарын да ишетергә туры килде. Ульяновск өлкәсе Иске Кулаткы районында яшәүче татарлар арасында «Хозер канатын җилпегәч, чәчүгә чыгарга ярый» дип исбат ителә. Татарстанның Яшел Үзән районында 19 апрельдә кичтән карга таяк кадап калдыралар, иртән исә кар кимегән булса, яз иртә килә дип фаразлыйлар, әгәр кимемәгән булса, «Хозер әле таягын кырга ташламаган» диләр. Төмән өлкәсенең Ялутор районында салават күперенең бер башында Хозер, бер башында Ильяс утыра дип әйтәләр [Давлетшина, 2011, с. 780].

Хозер Ильяс төрки халыклар традициясендә дә киң таралыш таба. Төрекләр 23 апрельне язның беренче көне буларак билгелиләр һәм шуннан соң өч көн бәйрәм итәләр. Беренче көнне кырда учак ягыла, икенче көнне тозсыз икмәк пешерәләр дә, аны, көчле булсын дип, үгезгә ашаталар, өченче көнне исә капкага он сибәләр һәм анда Хызырның эзләре барлыкка килүен көтәләр [Cetin, s. 28–29]. Азәрбайҗаннарда да бу көн зур бәйрәм буларак исәпләнә. Алар 23 апрельдә чәчүгә чыгалар һәм көтү куалар. Үзбәкләрдә исә, инде игеннәрне җыеп алганнан соң, келәткә салынган ашлык өстенә җир кисәге салып, аны «Хызыр кесаки» дип атау гадәте бар [Садекова, с. 135]. Күрүебезчә, Хозер Ильяс, гаять катлаулы, борынгы төрки мифологик карашлар традициясе һәм ислам идеологиясе белән бәйле күзаллау системасының синтезы буларак, татар халкының традицион мәдәниятендә бүген дә әһәмиятен югалтмаган мифик персонажларның берсе.

Традицион халык мәдәниятендә таралыш тапкан түбән рухлар хакындагы ышанулар системасына килгәндә, ислам мифологиясенә кагылышлы җен, пәри, шайтан; үлгән кешеләргә мөнәсәбәтле барлыкка килгән утлы елан, өрәк, убыр, татар халык ышануларында киң таралыш тапкан бичура, шүрәле, албасты кебек персонажлар турында әйтергә кирәк. Әлеге персонажлар кешегә зарарлы яки битараф затлар итеп карала һәм чыгышлары белән иран мифологиясенә (дию, аждаһа һ.б.), ислам тәгълиматына (җен, пәри, шайтан һ.б.), төрки халыклар традициясенә (албасты, өрәк һ.б.), угор-фин халыкларының күзаллауларына (убыр, бичура, шүрәле) барып тоташа.

Татар халкының бүгенге көн мифологик күзаллауларында иң актив персонажларның берсе – җен. Ислам дине өйрәтүләре аша татар традицион мәдәниятендә үз урынын яулаган әлеге персонаж белән бәйле ышанулар Гарәбстан территориясендә VI–VII гасырларда яшәгән халыклар арасында ислам динен кабул иткәнче үк киң таралыш тапкан булган. Мөселман традициясе буенча, Аллаһы Тәгалә җеннәрне уттан яраткан һәм аларга аң биргән, дип исәпләнелә. Җеннәрнең күбесе Иблис белән бәйле булса да, кайберләре ислам динен кабул иткән булып санала [Мифы народов мира, с. 374], шуңа күрә халык ышануларында алар «шәйтани» һәм «мөселман» җеннәренә аерыла.

Татар халкының бүгенге көн мифологик күзаллауларында җен, бер яктан, кешегә зыян китерердәй персонажларны алыштырып килә, икенче яктан, аның үзенә генә хас функциональ кыры да оеша. Экспедиция барышында язып алынган текстларда информантлар әлеге персонажны *җен, чин, чин-сәхмәт, җен-зәхмәт, шайтан, зәхмәт* дип атыйлар. Җен көндәлек тормышта күзгә күренеп йөрми, ул гаиләсе белән параллель дөньяда яши, әмма, үзенә кирәк булганда, кеше, берәр әйбер, табигать күренеше һ.б. кыяфәтләргә керергә мөмкин. «Без аларны күрмибез икән, алар безне күрә. Сукыр тип әйтәтеләр җеннәр кешеләрне» (Төмән өлкәсе Ялутор районы Ревда ав.). Җеннең яшәү урыны буларак халык телендә иң еш искә алына торган урын – мунча, анда тамак кырып керү кабул ителгән, кояш баегач, көн уртасында һәм төн уртасында керү тыелган.

Җен белән бәйле фольклор текстлары иң күп өлешне тәшкил итсә дә, алар нигездә берничә сюжетка кайтып кала. Җен кешенең яши торган йортына үтеп кереп, йортка бәла-каза алып килергә мөмкин, шуңа күрә дә әлеге персонаждан саклану чаралары бүгенге көндә дә актив кулланыла (ишек өстенә ат дагасы, артыш таягы кую; ишекләрне, ризык өсләрен бисмилла әйтеп ябу, тәрәзә төпләренә ризык куюны тыю һ.б.). Әлеге мифик затның зәхмәте кешегә йорт эчендә генә түгел, ә бәлки юлда, җиде юл чатында, пычрак урында, ташландык нигезләрдә дә тияргә мөмкин. Бу очракта җен зәхмәтен кайтару белән бәйле гамәлләр башкарылырга тиеш.

Җеннең эшчәнлеге күп очракта бала алыштыру белән бәйле. Адәм баласын җен юкка гына урламый. Урланган бала үсеп җиткәч, җеннәр арасында имче функциясен башкара, чөнки кешегә җен зәхмәте кагылган шикелле, җеннәргә дә адәм зәхмәте йогарга мөмкин икән. Персонажның әлеге функциясе баланы саклау белән бәйле гамәлләр комплексын да барлыкка китерә (баланы һәм көмәнле хатын-кызны ялгыз калдырырга ярамый; ялгыз калдырырга туры килгән очракта тимер әйбер, сарымсак, артыш таягы, миләш ботагы куярга кирәк һ.б.).

Гомумән алганда, халык телендә җен дип аталып йөртелгән персонаж ислам дине өйрәтүләре нигезендә таралыш тапкан булса да, бүгенге көндә исемнәре, генезисы, тышкы кыяфәте ягыннан мөселман традициясенә якынлыгын саклаган хәлдә, функциональ яктан татар халкының мифологик күзаллауларына бәйле рәвештә шактый баеган һәм үзгә персонажга әверелгән.

Татар халкы һәм башка халыклар мифологиясе дә мифологик персонажлар турындагы күзаллауларны гына түгел, ә бәлки алар белән бәйле функцияләрне (куркыту, адаштыру, яклау, бастыру, зәхмәт җибәрү һ.б.), мифологик образларга бәйсез мотивларны (абага чәчәген эзләү, хәзинә эзләү һ.б.), мифологик лексиканы үз эченә алган катлаулы система буларак билгеләнә [Виноградова, Толстая, с. 16–44].

Өйрәнү объектын тәгаенләштерү материалның чикләрен дә киңәйтеп җибәрә. Мифологик персонажларга бәйле традицион рәвештә өйрәнелә торган жанрлардан (мифологик хикәят, легенда) тыш, эзләнүләр барышында ырым текстларын, йолагадәтләрен (йорт иясен яңа йортка күчерү, йорт иясенә ризык кую, җен алыштырган баланы кайтару, йорттан җен куу һ.б.), көндәлек тормыш белән бәйле гадәтләрне (су аркылы чыкканда җеп ташлау; мунчада әйбер калдырып чыгу, җен төкермәсен өчен ризык өсләренә ябу һ.б.), ышану, тыю, юрау кебек жанр формаларын исәпкә алу да бик мөһим.

Үз эчендә бай мифологик мәгълүмат туплаган ышанулар функциональ яктан сынамышларга якын тора, алар да нәрсәдер булачагын хәбәр итү, юрау өчен әйтеләләр. Әмма ышанулар практик тәҗрибәгә, табигать күренешләре белән бәйле күзәтүләргә түгел, ә бәлки мифологик фикерләү калыпларына корылган. Кеше хәтерендә мифологик мәгълүмат «менталь матрицалар» рәвешендә саклана [Неклюдов, с. 77–80], аларның һәрберсе коммуникация вакытында я тарайтылгын, я киңәйтелгән кыяфәттә чагылыш таба. Беренче очракта сүз ышану хакында барса, икенче очракта сүз мифологик хикәят турында бара. Бу күзлектән карагында, ышанулар мифологик мотивлар фонды буларак күзалланырга мөмкин.

Ышануларның эчтәлеге еш кына халыкның борынгы үткәненә, аның йола-ритуалларына барып тоташа. Көтү килгәндә, алдан кызыл сыер килсә, көн кояшлы булыр, әгәр дә кара сыер килсә, болытлы булыр дигән ышану бар. Бу фикерләү калыбы борынгы заманнарда яңгыр теләгәндә, корбанга кара сыер, аяз һава теләгәндә кызыл сыер чалу гадәте белән бәйләнгән. Ышанулар һәрвакыт халыкның мифологик-дини күзаллауларына нигезләнә, кешеләрнең магик тәҗрибәләре нигезендә барлыкка килгән фикри сөземтәләр рәвешен ала. Ышануларның байтагында мәҗүси һәм ислам мифологиясе белән бәйле карашлар бер-берсе белән үрелеп, еш кына бер-берсен баетып тора: «Җомга көн кер, идән юарга ярамый», «Аш-суның өстен ябарга кирәк – шайтаннар юына», «Артыш агачыннан җен курка» һ.б.

Халык ышанулары инде күптән кешенең көнкүрешеннән, яшәешеннән чыгып киткән төшенчәләрне, мифологик карашларны реконструкцияләргә дә мөмкинлек бирә. Себер татарларында соңгы елларда язып алынган информациягә караганда, яңа туган баланың бишеге тирәли «Алас, Алас» дип артыш агачын яндырып йөрү гадәте саклана. Информантлар аңлатуынча, әлеге гадәтнең нигезендә «Алас, Алас» дисәң, балага кара көчләр тими дигән ышану ята. Әгәр дә татар халкының мифологиясенә мөрәҗәгать итсәк, Аласның ут алласының исеме булуын күрербез. Себер татарларында туй вакытында, шушы сүзләрне әйтеп, атны ут аша сикертү йоласы булган [Валеев, с. 87]. Татар халкында «Эт тыны сөяк сындырыр» дигән кызыклы

ышану да бар. Н. Исәнбәт аңа түбәндәгечә аңлатма бирә: «элекке заманнарда тамакка кылчык я сөяк утырганда, авызга эт тыны җибәргәннәр» [Татар халык мәкальләре, б. 586]. Шулай итеп, ышанулар уйдырма яки хорафатларга корылган сүзләр генә булмыйча, татар халкының борынгыдан килгән дини-мифологик карашларының чагылышы, инде көндәлек тормыштан төшеп калган күренешләрнең саклану урыны буларак та күзалланалар.

**Әдәбият**

*Cetin I.* Nevruz kutlamalarında ortak ve benzer pratikler / Uluslararası Nevruz Sempozyumu bildirileri: 21–23 Mart 2000, Ankara. Ankara: Kültür Bakanlığı, 2000. S. 28–29.

*Алексеев Н.А.* Общее в ранних формах религии якутов и тувинцев // Этнография народов Алтая и Зап. Сибири. Новосибирск: Наука, Сибирское отделение, 1978. С. 209–220.

*Бакиров М.Х.* Пратөрки бабаларыбыз иҗаты // Татар әдәбияты тарихы. I том. Казан, 2014.

*Бичурин Н.Я. [Иакинф].* Собрание сведений о народах, обитавших в Средней Азии в древние времена. М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1950. Т. 1. 382 с.

*Брусько З.М.* В круге жизни. Казань: Ихлас, 2014. 224 с.

*Валеев Ф.Т.* Западно-сибирские татары во второй половине XIX – начале XX веков (Историко-этнографические очерки). Казань: Татар. кн. изд-во, 1980. 232 с.

*Виноградова Л.Н., Толстая С.М.* К проблеме идентификации и сравнения персонажей славянской мифологии // Славянский и балканский фольклор. Верования. Текст. Ритуал. М.: Индрик, 1994. С. 16–44.

*Гмыря Л.Б.* Религиозные представления населения Прикаспийского Дагестана в IV–VII вв. (По данным письменных источников). Махачкала: Наука ДНЦ, 2009. 540 с.

*Гумилев Л.Н.* История народа хунну: в 2-х книгах. Кн. 1 / сост. и общ. ред. А.И. Куркчи. М.: Институт ДИ-ДИК, 1998. 448 с.

*Гумилев Л.Н.* Древние тюрки. М.: Наука, 1967. 504 с.

*Гумилев Л.Н.* Хунну. Степная трилогия. СПб.: Тайм-Аут – Компасс, 1993. 224 с.

*Гыйльманов Г.* Татар мифлары: иялəр, ышанулар, ырымнар, фаллар, имтомнар, сынамышлар, йолалар. Ике томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. 388 б.

*Давлетшина Л.Х.* О перевоплощениях духов-хозяев домашнего пространства (на материале татар Заказанья начала XXI века) // Вестник Башкирского университета. 2015. Т. 20. № 3. С. 1022–1025.

*Давлетшина Л.Х.* «Хызыр Ильяс» в традиционной культуре татар // Вестник Башкирского университета. 2011. Т. 16. № 3. С. 779–781.

*Дәүләтшин Г.М.* Төрки-татар рухи мәдәнияте. Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. 512 б.

Ислам. Белешмә-сүзлек. Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. 192 б.

*Кляшторный С.Г.* Древнетюркская мифология: к постановке проблемы // Письменные памятники и проблемы истории культуры народов Востока. Ч. 2. М.: Наука, 1979. С. 91–96.

*Кляшторный С.Г.* Древнетюркская цивилизация: диахронические связи и синхронические аспекты // СТ. 1987. № 3. С. 67–72.

*Кляшторный С.Г.* Древнетюркские рунические памятники как источник по Средней Азии. М.: Наука, 1964. 214 с.

*Кляшторный С.Г.* Мифологические сюжеты в древнетюркских памятниках // ТС. 1977. М.: Наука, 1981. С. 117–138.

Культ святых в сибирском исламе: специфика универсального / А.Г. Селезнев [и др.]. М.: Изд. дом Марджани, 2009. 216 с.

*Кюнер Н.* В. Китайские известия о народах Южной Сибири, Центральной Азии и Дальнего Востока. М.: Изд-во Восточной литературы, 1961. 392 с.

Материалы по истории сюнну (по китайским источникам). Вып. II / Предисловие, перевод и примечания В.С. Таскина. М.: Наука, 1973. 168 с.

Мифологический словарь / гл. ред. Е.М. Мелетинский. М.: Советская энциклопедия, 1990. 709 с.

Мифы народов мира: Энциклопедия: в 2 т. / под ред. С.А. Токарева. М.: Большая Российская энциклопедия, 2003. Т. 1. 671 с.

*Мовсес Каланкатуаци.* История агван Мойсея Каганкатваци, пис. X в. / пер. К. Патканьян. СПб.: Императорская Академия наук, 1861. 376 с.

*Неклюдов С.Ю.* Стереотипы действительности и повествовательные клише // Речевые и ментальные стереотипы в синхронии и диахронии. М., 1995. С. 77–80.

*Померанцева Э.В.* Мифологические персонажи в русском фольклоре. М.: Наука, 1975. 194 с.

*Потапов Л.П.* Алтайский шаманизм. Л.: Наука, 1991. 203 с.

*Потапов Л.П.* Умай – божество древних тюрков в свете этнографических данных // ТС. 1972. М.: Наука, 1973. С. 265–286.

*Садекова А.Х.* Идеология ислама и татарское народное творчество. Казань: Фикер, 2001. 206 с.

*Стеблева И.В.* К реконструкции древнетюркской религиозно-мифологической системы // ТС. 1971. М.: Наука, 1972. С. 213–226.

Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда. 2 т. Казан: Мәгариф, 2009. 360 б.

Татар халык мәкальләре: 3 томда / төз. Н. Исәнбәт. Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. 1 т. 623 б.

*Урманчеев Ф.И.* Татар халык иҗаты. Казан: Мәгариф, 2002. 172 б.

*Яхин Ф.* Сөләйман Бакыргани // Татар әдәбияты тарихы. I т. Казан, 2014.

***Дәүләтшина Ләйлә Хәсән кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*
*leyla.davletshina@yandex.ru*

УДК 94(47)

***Р.И. Беккин***

# ГАТАУЛЛА БАЯЗИТОВНЫҢ СОҢГЫ ГОЗЕРЕ

Предлагаем вниманию читателей два документа – письмо генерал-лейтенанта Губайдуллы Чингисхана к М.А. Гамазову от 23 сентября 1888 г. и письмо Атауллы Баязитова к иранисту В.А. Жуковскому. Второе письмо уникально тем, что представляет собой возможно последний документ, написанный или, если быть точным, продиктованный Баязитовым. Само письмо, датируемое 19 апреля 1911 г., написано рукой писаря, но под ним стоит автограф ахуна. А. Баязитов скончался после неудачно проведенной операции в ночь на 22 апреля. Автор письма предвидел такой исход, и эти мысли послужили поводом обратиться к Жуковскому с письмом.

**Ключевые слова:** Атаулла Баязитов, Губайдулла Чингисхан, М.А. Гамазов, В.А. Жуковский, мусульмане Петербурга.

Россиядә ислам тарихын өйрәнә торган һәр тикшеренүче өчен иң кызыклы мәсьәләләрнең берсе – мөгаен, мөселманнарның рус җәмгыятендәге күренекле шәхесләр белән элемтәләре. Ләкин бу мәсьәлә өстендә эшләгән галим өчен иң кыены – материал җитмәү. Хатлар, истәлекләр һәм башка чыганакларда мөселманнарны сирәк кенә телгә алу картинаны ачып бетерми. Ә сүз бит, башлыча, мөселман халыклы регионнар турында бара (мәсәлән, Кырым, Кавказ, Идел буе, Урта Азия). Империянең башкаласы, XIX–XX гасырлар чигендә 5 меңнән артык мөселман яшәгән Петербург турында әйтсәк, анда мөселманнарның шәһәрдәге башка милләт вәкилләре белән багланышлары турында мәгълүматны бөртекләп җыярга кирәк. Әлбәттә, бу күбрәк рус телле чыганакларга карый, ләкин мөселман халыклары телләрендә булган документларда да шундый ук хәл күзәтелә.

Мәгълүматның аз булуы кайбер авторларның расланган фактларга нигезләнми генә, дәлилләнмәгән мәгълүмат, уйдырмалар куллануына китерә. Нәтиҗәдә мифлар барлыкка килә; алар исә, бернинди аңлатма, шәрехләрсез генә, компилятор тикшеренүчеләрнең бер хезмәтеннән икенчесенә күчеп йөри.

Шундый мифларның берсе – Петербург ахуны Г. Баязитов һәм философ Вл. Соловьев арасында булган якын дустанә мөнәсәбәтләр турындагысы – безнең бер мәкаләдә җентекләп тикшерелгән иде [Беккин, б. 88–104]. Бу ике фикер иясе арасындагы мөнәсәбәтләрне тикшерү белән генә чикләнмичә, без шул ук мәкаләдә Баязитовның Петербург җәмгыятенең башка вәкилләре белән дә бәйләнешен карап узган идек. Ахун озак еллар буе тыгыз элемтәдә торган шәхесләрнең берсе – аның турыдан-туры җитәкчесе, Тышкы эшләр

министрлыгының Азия департаменты Шәрык телләрен укыту бүлеге башлыгы, шәрык белгече Матвей Авелевич Гамазов[1].

1880 елда Г. Баязитов Тышкы эшләр министрлыгына тәрҗемәче (драгоман) буларак чакырыла, ә 1888 елда, М.А. Гамазов тәкъдиме белән, коллеж регистраторы чинында төрки телләр мөгаллиме итеп билгеләнә. Шулай итеп, Г. Баязитов Петербургның икенче мөселман мәхәлләсе имамы эшләрен дәүләт хезмәте белән бергә алып бара.

Генерал-лейтенант Гобәйдулла Чынгызханның М.А. Гамазовка язган хаты нәкъ шул чорга карый. Хат 1888 елның 23 сентябрендә язылган. Бу документ эчтәлеге һәм машинкада бастырылуы белән дә кызыклы. 1888 елда андый бастырылган хатлар әле сирәк күренеш була. Шуңа күрә дә хат башында Чынгызхан аңлатма биреп китә: «Басма хәрефләр белән язуыма гаҗәпләнмәгез, бүген шундый машина уйлап чыгарганнар, тиз язарга була, һәм ул мине инде күпмедер вакыт юата» [Письмо Чингис-хана Тору М.А. Гамазову].

Эчтәлеге һәм интонациясе ягыннан дусларча язылган әлеге хат, әлбәттә, безнең игътибарны бу факт белән генә җәлеп итмәде. Баязитов фамилиясе ачыктан-ачык әйтелмәсә дә, күптән түгел генә билгеләнгән мөгаллим турында сүз барганда, Чынгызханның ахун турында сөйләве бәхәссез: «Сез сайлаган кеше – мөгаллим турында. Хаталанмадыгыз, ул сезнең ихтирамны яулар өчен күп көч куяр дип өметләнәм» [шунда ук][2]. Чыңгызханның, күпчелек тормышын Петербургта яшәгән мөселман кешесе буларак, Баязитовны белми калуы мөмкин түгел. Бу бәхәссез. Бәлки тәрҗемәче һәм Азия департаментына мөгаллим буларак ахунны да Гамазовка ул тәкъдим иткәндер.

Матвей Авелевичны Г. Баязитовның мөгаллим буларак хезмәте канәгатьләндергәндер дә, ләкин аның фәнни тикшеренүләре шәрык белгечендә яклау тапмый. Аннан тыш, Баязитовның галим-тикшеренүче буларак чыгышларын Гамазов ачыктан-ачык көлкегә дучар итә [бу турыда тәфсилләбрәк кара: Беккин, б. 96–97].

Г. Баязитовка, ислам канунnarын, шәрык телләрен әйбәт белү өстенә, европача белемлелек җитми. Европа белеме фән өлкәсенә юлны киңәйтә, андый белемгә ия кеше колониаль галимнең җирле халык арасыннан булган кече ярдәмчесе генә түгел, ә тулы хокуклы партнеры була ала. Мәшһүр татар галиме Хөсәен Фәезханов мисалы бу хакыйкатьне яхшы раслый. Әгәр дә Баязитовның амбицияләре башкаланың бер мөселман мәхәлләсе җитәкчесе булу белән генә чикләнсә, аңа үзендә булган әйбәт дини белем бик

[1] Гамазов Матвей Авелевич (1812–1893) – Россия дипломаты, шәрык белгече, Тышкы эшләр министрлыгының Азия департаменты Шәрык телләрен укыту бүлеге башлыгы (1872–1893).

[2] Югарыда күрсәтелгәнчә, 1888 елда Г. Баязитов Тышкы эшләр министрлыгының Азия департаменты Шәрык телләрен укыту бүлегендә төрки телләр мөгаллиме итеп билгеләнә.

җиткән булыр иде. Россия империясе шартларында имамнарның, Тышкы эшләр министрлыгының Азия департаменты хезмәткәрләре кебек үк, дәүләт чиновниклары булуын да истә тотарга кирәк. Ләкин Баязитов имам булу белән генә канәгать түгел. 1871 елда Петербургка килгәннән бирле ул хезмәт юлын акрынлап һәм зур тырышлык куеп киңәйтә, руханилык роле белән генә чикләми. Ләкин биредә аннан инде белемлелекның бөтенләй башка дәрәҗәсе таләп ителә. Г. Баязитов моны яхшы аңлый һәм улы Мөхәммәдсафага киләчәктә мөхтәрәм дин башлыгы гына түгел, ә дөньяви яктан да хезмәт юлын уңышлы ясарлык белем бирергә омтыла.

Г. Баязитовның мәкаләдән соң китерелгән хаты Тышкы эшләр министрлыгының Азия департаменты Шәрык телләре бүлеге башлыгы Валентин Алексеевич Жуковскийга[1] язылган.

Хатның эчтәлеге турында сүз башлаганчы, аның уникаль документ булуын әйтеп китәргә кирәк: бу хат Баязитов тарафыннан язылган, төгәлрәге, әйтеп яздырылган хатларның соңгысы булуы да ихтимал. 1911 елның 19 апрелендә язылган бу документ хаттат кулы белән язылган, ләкин ахырында Ахун автографы бар[2]. 21 апрельдә уңышсыз узган операциядән соң ахун бакыйга күчә. Хат авторы бу хәлнең булу мөмкинлеген яхшы аңлый, шуңа күрә дә Жуковскийга хат аша гозер белән мөрәҗәгать итә: «Ходайга тапшырдым, мин икенче тапкыр операциягә тәвәккәлләдем. Бу операциянең минем өчен соңгысы булуы да бар» [Письмо А. Баязитова к В.А. Жуковскому].

Хатта Г. Баязитов җитәкчесеннән улы Мөхәммәдсафа турында кайгыртуын сорый. Балалары үзеннән соң матди яктан тәэмин ителмичә калалар дип язса да, хатта сүз матди кайгырту турында бармый. Беренчедән, Мөхәммәдсафага әтисе үлгәндә 33 яшь була, һәм ул вакытта инде ул мөстәкыйль кеше. Икенчедән, яшәү өчен матди чаралар җитмәсә, М. Баязитов Касыйм татарлары арасыннан Петербургта яшәүче сәүдәгәрләргә мөрәҗәгать итә алыр иде (мәсәлән, Фатыйх Бәйрәшевкә). Ф. Бәйрәшев белән ул озак еллар дустанә мөнәсәбәттә була, хәтта алга таба бергәләп «Сират әл-мөстәкыйм» («Туры юл») уң партиясен оештыра. Г. Баязитов вафатыннан соң Петербургның икенче мөселман мәхәлләсе имамы урыны аның улына кала. Г. Баязитов, Жуковскийга гозер белән мөрәҗәгать итеп, Валентин Андреевич аның улына рус җәмгыятендә үз урынын алырга ярдәм итәр дип ышана. Бу эштә Мөхәммәдсафага бары тик Г. Баязитовны яхшы белгән рус чиновниклары гына ярдәм күрсәтә ала. Ахунның ышанычы чынга аша. Улына үзеннән соң мөселман мәхәлләсе һәм Россиядә беренче татар газе-

[1] Жуковский Валентин Алексеевич (1858–1918) – шәрык белгече, иранист, Санкт-Петербург университетының Шәрык телләре факультеты деканы (1902–1911), Тышкы эшләр министрлыгының Азия департаменты Шәрык телләрен укыту бүлеге башлыгы.

[2] Ахунның русча язылган күпчелек хатлары хаттат тарафыннан язылган һәм аларда Баязитов имзасы гына тора.

тасы «Нур» гына түгел, ә матди булмаган, әмма Гатаулла Баязитов өчен аеруча мөһим һәм кадерле «байлык» кала: рус җәмгыятендә элемтәләр. Бу элемтәбагланышлар киләчәктә Мөхәммәдсафа Баязитовка Петербург һәм империянең башка ислам дин әһелләре арасында алга чыгарга мөмкинлек бирә. 1915 елда ул, мөселманнарның шактый өлеше тарафыннан яклау тапмаса да, Оренбург Диния нәзарәте мөфтие итеп билгеләнә.

**Әдәбият**

*Беккин Р.И.* Бер дуслык тарихы: Г. Баязитов һәм В.С. Соловьев // Фәнни Татарстан. 2016. № 3. Б. 88–104.

Письмо Чингис-хана Тору М.А. Гамазову // ОР РНБ. Ф. 172. Д. 121. Л. 1.

Письмо А. Баязитова к В.А. Жуковскому // АВ ИВР РАН. Ф. 17. Оп. 2. Д. 6. Л. 1.

**Чынгызхан Торуның М.А. Гамазовка язган хаты[1]**

Симферополь 23 сентября 1888 г.

Сейчас принесли с почты Ваше дорогой мне, Матвей Авелиевич, письмо от 5-го сего месяца. Искренно тронут вниманием и очень Вас благодарю.

Неудивляйтесь, что я пишу печатными буквами, ныне придумали такую машину, что можно скоро писать и притом она забавляет меня на некоторое время…

Очень рад, что Вы вводите у себя курс татарского языка, которым пользуется вся русская татария до Бухары. Что же касается до несочувствия одной личности, то этим тупоумием выскочки Вы не огорчайтесь. Результаты Ваших трудов в этом полезном деле, скоро его приведут в разумение…

От души желаю Вам полного успеха. Относительно избранника Вашего – учителя, он же вновь испеченный чин я надеюсь Вы неошиблись в нем, он будет очень стараться заслужить Ваше спасибо».

Погода у нас – великолепная – просто лето. Такой теплыни здесь, незапомнят и старожилы… За то вы? На севере холода говорят проезжающие на южный берег лица ежедневно с курьерскими поездами, которых я встречаю ежедневно в 8 ч. утра… Все они стремятся в Ялту, Гурзуф и тому подобн. российским курортным местам, но увы? там их ждет полный грабеж местных кулаков-хозяев… Так что холод севера иным приезжим показывается краше южных «экономических» апетитов Ялтинских дач и домо-владельцев. Короче для примера – винограда 1 фунт стоит в Ялте – 25 коп. тогда как Виноградары продают пуд за 1 р. 75 к. на базаре тем же ялтинским вампирам… Исключение быть может, но совсем на других основаниях…

Если Вы напр. Занимаете видное положение в ПБГ[2] и на вас можно расчитывать по делам такого проприетера то Вам все будет за даром…

[1] Хатлар оригинал орфографиясен һәм пунктуациясен саклаган хәлдә тәкъдим ителә.

[2] Санкт-Петербург күздә тотыла.

Недурна ведь тактика этих вампиров? Какого же бедному и больному люду которому не развлечения влекут сюда, а лечение от злой болезни…

Однако я навеял на Вас скуку… Простите дорогой мой Матвей Авелиевич за откровенность.

Целую Вас крепко.

Ваш старый слуга.

Чингис-Хан Тору

приложил

Тугра.

При случае засвидетельствуйте Ивану Алексеевичу мой глубокий селям. Не вздумал ли он поехать «купаться» в Каспийском море? Там кажется в нынешний сезон появился «особенный» – шефкет? … Ха Ха Ха

Скажите пожалуйста что за мода нынче печатать в газетах какие-то документы? То они подложные, то подлинные… Кажись господину железному канцлеру приходится страдать от ржавчины. Да, просто заржавел старик… Ина мудреца находит простата своя… Поживем увидим… Кланяюсь

(ОР РНБ. Ф. 172. Д. 121. Л. 1-1об.)

**Г. Баязитовның В.А. Жуковскийга язган хаты (1911 елның 19 апреле)**

19 апреля 1911 г.

Глубокоуважаемый Валентин Алексеевич!

Уповая Господу Богу я решился вторично идти на операцию. Может случиться, что операция эта будет роковой для меня. Поэтому я пишу Вашему превосходительству последнее мое письмо. На смертном одре я приношу Вам и уважаемой Варваре Алексеевне мою глубочайшую благодарность и признательность за все те милости, которые Вы и Варвара Алексеевна оказали мне.

Затем, глубокоуважаемый Валентин Алексеевич, в виду того, что моя семья – дети совершенно не обеспечены, я обращаюсь к Вам с моей последней просьбой: не оставьте моего сына Сафу. Он совершенно благонадежный человек, на него можно положиться. Восточную литературу, мусульманскую богословие он знает прекрасно, нисколько не меньше меня самого. Об европейском образовании его Вам известно самим. Поэтому прошу Вас, глубокоуважаемый Валентин Алексеевич, не оставьте моих детей, примите моего сына Сафу на мое место в должность драгомана. Тогда бы я спокойно закрыл глаза. Еще раз благодарю Вас и глубокоуважаемую Варвару Алексеевну.

Признательный Вам Ахунд Баязитов»

(АВ ИВР РАН. Ф. 17. Оп. 2. Д. 6. Л. 1)

***Беккин Ренат Ирек улы,***
*икътисад фәннәре докторы, Россия Фәннәр академиясе профессоры,*
*Россия Фәннәр академиясе Африка институтының*
*әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

УДК 94(47)

*З.Р. Хәбибуллина*

**БАШКОРТСТАНДА МӨСЕЛМАННАРНЫҢ «ИЗГЕ УРЫННАР»Ы (1944–1965 еллар)**

В статье на основе материалов Центрального исторического архива Республики Башкортостан (1944–1965 гг.) рассматривается бытование религиозной практики посещения захоронений аулия – «святых» – среди советских мусульман и деятельность Уполномоченного Совета по делам религиозных культов при Совете Министров СССР по борьбе с ней.

**Ключевые слова:** ислам, паломничество, аулия, святые места, уполномоченный, БАССР.

Башкортстан Республикасы мөселман халкы арасында күренекле дин әһелләре җирләнгән урыннарга зиярәт кылу кебек дини традицияләрнең бүген дә саклануы һәм аның тагын да киңрәк тарала баруы тарихи күзлектән караганда да, бу өлкәгә дәүләт сәясәте контекстында да фәнни кызыксыну уята. Башкортстан Республикасы Үзәк тарихи архивындагы Р-4732 нче фонд, СССР Министрлар Советы каршындагы Дин эшләре буенча Совет материалларына нигезләнеп әзерләнгән бу мәкаләдә мөселманнарның изге саналган урыннарга мөнәсәбәтенә карата әлеге Совет һәм аның БАССРдагы Вәкиллеге эшчәнлеге яктыртыла.

Күрсәтелгән еллар дәвамында илдәге дини тормыш 1944 елның 19 маенда оештырылган Дин эшләре буенча Совет күзәтчелегенә алына. Бу Советның төп максаты диннәргә мөнәсәбәттә Совет дәүләте сәясәтен тормышка ашыру, дини йолалар турындагы закончалыкларның үтәлешен контрольдә тоту була. Регионнарда дини проблемаларны хәл итү өчен Совет тарафыннан урыннарда вәкилләр билгеләнә. Аларның мәгълүмати хисап-хәбәрләрен илнең дини берләшмәләргә карата куелган сәяси һәм гамәли юнәлешләре нигезендәге документлар тәшкил итә, шулардан чыгып, СССРда дини эшләрнең тормышына бәя бирелә. Шуңа күрә урыннардан алынган мәгълүматлар илдәге дини йолаларның үтәлеше, аларның халык массасына йогынтысы, гамәлдәге законнарның аларга карата дөрес кулланылуы һ.б. хакындагы картинаны чагылдыралар. СССР Министрлар Советы каршындагы Дин эшләре буенча Совет белән БАССРдагы аның Вәкиллеге арасындагы үзара язма документлар, дин тотучыларны һәм руханиларны кабул итү беркетмәләре, шулай ук Россиянең Европа өлеше һәм Себер мөселманнары Үзәк Диния нәзарәтенең (ДУМЕС) мөселманнарга ачыктан-ачык җиткерелгән документлары илдә исламның ролен, дин тотучылар белән руханиларның теләк-омтылышларын күзалларга мөмкинлек бирә, хакимиятнең җирле органнары тарафыннан оештырылган чараларның

төрләре һәм нәтиҗәләре хакында мәгълүмат җиткерә.

Дин эшләре буенча Советның күзәтү һәм контрольдә тоту пунктларынең берсе – изге урыннарга табыну йолаларын үтәү була. Аңа даими җиткереп барыла торган мәгълүмати белешмәләрдә Башкортстан АССР территориясендәге мөселманнар өчен изге саналган каберлек-төрбәләрнең урыннары һәм аеруча күренекле ислам эшлеклеләренең исемнәре күрсәтелергә, шулай ук ул урыннарга күмәкләп зиярәт кылулар һәм аларның ешлыгы (ел дәвамында яки билгеле бер вакытта) хакында да хәбәр ителергә тиеш була [Переписка с Советом... 1944–1945 гг., л. 24]. 1947 елда СССР Министрлар Советы каршындагы Дин эшләре буенча Совет БАССР вәкиллегенә М. Кәримовка түбәндәге телеграмманы җибәрә: «Вам следует собрать следующие сведения: о паломничестве в мазары (гробницы), где похоронены выдающиеся деятели ислама. Если эти паломничества имеют место, то Вам необходимо выявить и составить краткий перечень важнейших существующих в БАССР мазаров (гробниц) с кратким описанием их. При составлении перечня Вы можете посоветоваться с муфтием Расулевым, членами Духовного управления или муллами зарегистрированных мечетей» [Переписка с Советом... 1947 г., л. 8].

Мөселманнарның табыну урыннары турындагы мәгълүматлар гадәттә Вәкиллек отчетының «Сектантлар хәрәкәте» бүлегенә урнаштырыла. БАССР территориясендә ике урынга – исламның күренекле эшлеклеләре Хөсәен бәк (Чишмә районы) һәм Җәгъфәр ишан (Дәүләкән районының Тимәш (Тимашово) авылы) җирләнгән урыннарга зиярәт кылу киң таралган. Хөсәен бәк каберенә кирпичтән манара (мавзолей) эшләнгән һәм аңа «Монда Хөсәен бәк җирләнде. 1053 ел» дип язылган, әмма аның ислам эшлеклесе буларак күрсәткән хезмәтләре ачык билгеле түгел, шуңа да карамастан, дини йолаларны үтәүче мөселманнар аны «изге» санап, каберенә зиярәт кылуны дәвам итәләр. Вәкиллек мәгълүматларына караганда, Җәгъфәр ишан каберенә табыну тенденциясе әле дә бик көчле [Переписка с Советом... 1950 г., л. 12, 20]. Изге урыннарга табынуны контрольдә тотуның төп сәбәбе – «хезмәт ияләрен дини сектантлык җәмгыятьләренә кушылудан саклау».

1950 елларда Дин эшләре буенча Советның урыннардагы Вәкиллекләргә җибәргән күрсәтмәләрендә мөселманнарның Ураза һәм Корбан бәйрәмнәрен ничек уздыруларына, «изге урыннар, олылауга лаек каберлекләр» тирәсендә руханилар эшчәнлегенә игътибарны көчәйтергә, дингә ышанучыларны ураза тотарга, тәравих намазларына җәлеп итүнең яңа ысулларын ачыкларга һәм ислам эшлеклеләренең онытылган дини йолаларны торгызуга юнәлдерелгән гамәлләрен туктатырга тәкъдим итела [Переписка с Советом... 1950 г., л. 12, 20].

БАССР мөселманнары арасында изге урыннарга табыну йолаларын үтәүнең авырлыгы дини

җәмгыятьләрне регистрацияләүнең катлаулылыгы, табыну урыннары – мәчетләрнең булмавы, беркайда да теркәлмәгән, «күчеп йөри торган» муллалар эшчәнлеге белән бәйле була. Изге урыннарга барып, регистрацияләнгән мәчетләрдә һәм рәсми дин әһелләреннән башка гына гыйбадәт кылу авыл җирлекләрендә киң таралган була. Чөнки шәһәрләрдә дини тормышны контрольдә тоту көчлерәк алып барыла. Табыну урыннары тирәсендә дини активлыкны киметү проблемасын хәл итү өчен авыл халкы арасында массакүләм мәдәни һәм сәяси чаралар оештыру көчәя. Изге урыннарга йөрүчеләрнең күп өлеше контрольгә алынмаганлыктан, дини тормышны республика күләмендә күзәтеп тору һәм тәртипкә салу эшендә кыенлыклар килеп чыга.

1954 елга Мөселман эшләре вәкиллегенең яртыеллык эш планы мөселман руханиларының исәптәге табыну объектлары тирәсендәге эшчәнлеген өйрәнүдән гыйбарәт була. БАССРда Мөселман эшләре вәкиллегенә түбәндәге эшләр тәкъдим ителә: «...путем выезда в Чишминский район изучить состояние религиозности мусульманского населения, деятельности зарегистрированных религиозных общин, групп верующих, действующих без регистрации, и мусульманского духовенства, обратив при этом особое внимание на изучение незарегистрированного духовенства и активность верующих вокруг почитаемой гробницы “Кашана”» [Переписка с Советом... 1954 г., л. 41]. 1958 елда СССР Министрлар Советы каршындагы Дин эшләре буенче Советка Вәкиллектән, БАССР территориясендә дин тотучы мөселманнар һәм руханилар тарафыннан аерым игътибарга лаек булган «изге урыннар» юк, дигән мәгълүмат бирелә. Шул ук вакытта регионда исламны тарату эшчәнлеге белән бәйле ике һәйкәл – Хөсәен бәк мавзолее һәм Тура хан мавзолее («Батыр» зираты) булуы аерып күрсәтелә. Әлеге документ авторы «В дореволюционный период паломничество “зиарата” Хусаин-бека принимало массовый характер, а за последние годы приток паломников в “зиараты” Хусаин-бека и “Батыра” значительно сократился, верующие мусульмане окрестных деревень посещают их группами и в одиночку в дни больших мусульманских религиозных праздников. В эти дни паломникам никто не препятствует, в среднем на каждом таком празднике бывает до 30 человек», – дип яза [Переписка с Советом... 1958 г., л. 31]. Дин эшләре буенча Советның БАССРдагы Вәкиллеге, СССР Фәннәр академисенең Башкортстандагы филиалында һәм Мәдәният министрлыгында әлеге объектларның фәнни өйрәнелеше хакындагы сорауларына алган җаваплардан соң, ул һәйкәлләрне алга таба өйрәнүгә ихтыяҗ юк, дигән нәтиҗәгә килә. Әлеге «төрбә» мөселманнар өчен «Изге урын» булып саналганлыктан һәм бу каберлекләр тирәсенә кешеләрне тарту белән рәсми теркәлгән яки теркәлмәгән руханилар эшчәнлеге күзәтелгәнлектән, Вәкиллек Хөсәен бәк белән Тура хан каберлекләрен

юкка чыгарып, мөселманнарның аларга зиярәт кылуларын туктатырга тәкъдим итә [Переписка с Советом... 1958 г., л. 31].

СССР Министрлар Советы каршындагы Дин эшләре буенча советның 1958 ел, 10 декабрендә кабул ителгән «Изге урыннарга күмәкләп зиярәт кылуны туктату буенча чаралар турында»гы карары Вәкиллекнең дин эшлеклеләре күмелгән урыннарга йөрүне ачыклауга һәм бу гамәлне туктатуга юнәлдерелгән озак вакытлы эшләрен башлап җибәрә. БАССРдагы Вәкиллеккә дини үзәкләр һәм берләшмәләр җитәкчеләренең исемлеген булдыру, изге урыннарга зиярәт кылуны туктатуга кагылышлы мәсьәләләр буенча аларны чакыртып, аңлату һәм кисәтү эшләре йөкләнә [Переписка с Советом... 1958 г., л. 45]. СССР Министрлар Советы каршындагы Дин эшләре буенча советның рәисе А.А. Пузинга Башкортстан вәкиллегеннән 1958 елның 27 сентябрендә юлланган язма хәбәрдә Чишмә районында Хөсәен бәк белән Тура хан төрбәләре булуы хакында тагын бер кат әйтелә. Анда, Хөсәен бәк кабере, җирле халык әйтүенә караганда, изге урын булып түгел, ә күренекле эшлекленең («зур начальникның») кабере генә булып санала, һәм мөселманнар, өлкән яшьтәге дин тотучылардан кала, анда даими йөрмиләр, фәкать мөселман бәйрәмнәрендә генә барып гыйбадәт кылалар, диелә. Вәкиллек әгъзасы фикеренчә, Тура хан кабере дә изге урын саналмый, анда дин тотучыларның зиярәт кылуы күзәтелми. Россиянең Европа өлеше һәм Себер мөселманнары Үзәк Диния нәзарәте мөфтие Ш. Хиалетдинов белән әңгәмәдә бу объектларның изге урын буларак исәптә тормавы әйтелә. Төзелеш һәм архитектура академиясе мөхбир әгъзасы Б. Кәлимуллинның әлеге каберлекләрне Башкортстанның архитектур һәйкәлләре исемлегенә кертүе аларны юкка чыгарудан саклап кала [Переписка с Советом... 1958 г., л. 47–49].

«Изге урыннар»га даими зиярәт кылулар булмаса да, Вәкиллекнең кайбер әгъзалары тарафыннан Башкортстанда шундый ике-өч объект булуы исәпкә алына һәм 1959–1961 еллар дәвамында республикада зиратлар турындагы мәсьәлә берничә мәртәбә күтәрелә. Ул ислам дини эшлеклеләре күмелгән урыннарга барып гыйбадәт кылуны һәм дин әһелләренең Аллага ышанучыларны зиярәт кыларга оештыруларын саклап калу белән бәйле була. Россиянең Европа өлеше һәм Себер мөселманнары Үзәк Диния нәзарәте мөфтиенең Вәкиллеккә җиткергән мәгълүматларына караганда, руханиларның дин тотучыларны Республикадан читтәге изгеләр каберләренә – Троицкидагы Зәйнулла ишан, Татарстан АССР, Ульяновск өлкәсе территорияләрендәге «Изге урыннар»га алып баруны даими оештырулары билгеләнә. Һәм моның төп сәбәбе итеп дини максат түгел, ә халыктан иганә (акча) җыю билгеләнә [Записи приемов Уполномоченным Совета... 1959 г., л. 2–3]. Россиянең Европа өлеше һәм Себер мөселманнары Үзәк Диния нәзарәте тарафыннан дин

тотучыларны «Изге урыннар»га зиярәт кылырга чакырып берничә мөрәҗәгать әзерләнә. Дини эшләр буенча Совет Вәкиллеккә түбәндәге күрсәтмәне бирә һәм аны Диния Нәзарәтенә тәкъдим итәргә боера: «издать не обращение, а более расширенное толкование (фетву), провести ряд мероприятий: «проповеди в мечетях, беседы с духовенством и верующими, направленными не только на прекращение паломничества к зиаратам, но и по отношению различного рода бытующих среди мусульманского населения суеверий, которые используются различного рода шарлатанами в своих корыстных целях» [Переписка с Советом... 1959 г., л. 25]. 1959 елның 18 мартында бу күрсәтмә барлык мөхтәсибләргә һәм руханиларга җибәрелә.

СССР Министрлар Советы каршындагы Дин эшләре буенча Советның «Изге урыннар» белән көрәш буенча карары игълан ителгәннән соң Вәкиллек түбәндәге юнәлешләр буенча мәгълүмат әзерләргә тиеш була: «1. Общее количество выявленных на территории республики «святых мест и источников», к которым совершаются паломничества верующих; 2. количество «святых мест и источников», которые за отчетный период времени были закрыты и прекратили свою деятельность; 3. какими методами было прекращено паломничество к этим «святым местам и источникам»; 4. что конкретно намечено в отношении прекращения паломничества верующих к действующим в настоящее время «святым местам и источникам» (описать план намеченных мероприятий в отношении каждого действующего «святого места и источника»; 5. как были использованы возможности религиозных центров и глав церквей в деле прекращения паломничества к так называемым «святым местам и источникам» и какие дополнительные меры намечаются к дальнейшему использованию возможностей духовенства; 6. какую конкретную помощь оказывают Уполномоченные Совета руководящим органам республик и областей в развертывании массовой политической работы и научно-атеистической пропаганды среди трудящихся, имеющей целью показать обман пропаганды церковников и различных проходимцев о «святости» и «целебности» источников и т.д.; 7. на каком уровне, по сравнению с прошлым годом прошло паломничество верующих к действующим в настоящее время «святым местам и источникам» в частности по мусульманскому вероисповеданию в дни праздника ураза-байрам» [Переписка с Советом... 1959 г., л. 39–40].

Башкортстан Рспубликасы Үзәк тарихи архивында сакланган документлардан ачыкланганча, Вәкиллекнең «изге урыннар» белән көрәше 1960 еллар уртасына кадәр дәвам итә. Изгеләр каберлекләренә зиярәт кылуга каршы көрәшнең активлашуы ул объектларга якын җирлекләрдә яшәүчеләрнең дини гамәлләрен тиешле дәрәҗәдә контрольдә тота алмау белән бәйле була.

**Әдәбият**

Записи приемов Уполномоченным Совета по делам религиозных культов при Совете Министров БАССР представителей верующих и духовенства. 1959 г. // ЦИА РБ. Ф. 4732, Оп. 1. Д. 21.

Переписка с Советом по делам религиозных культов при Совете Министров Башкирской АССР. 1944–1945 гг. // ЦИА РБ. Ф. Р-4732, Оп. 1. Д. 1.

Переписка с Советом по делам религиозных культов при Совете Министров Башкирской АССР. 1947 г. // ЦИА РБ. Ф. Р-4732, Оп. 1. Д. 3.

Переписка с Советом по делам религиозных культов при Совете Министров Башкирской АССР. 1950 г. // ЦИА РБ. Ф. 4732, Оп. 1. Д. 6. Л. 12; ЦИА РБ. Ф. 4732, Оп. 1. Д. 6.

Переписка с Советом по делам религиозных культов при Совете Министров Башкирской АССР. 1954 г. // ЦИА РБ. Ф. 4732, Оп. 1. Д. 10 (II).

Переписка с Советом по делам религиозных культов при Совете Министров Башкирской АССР. 1958 г. // ЦИА РБ. Ф. 4732, Оп. 1. Д. 20.

Переписка с Советом по делам религиозных культов при Совете Министров Башкирской АССР. 1959 г. ЦИА РБ. Ф. 4732, Оп. 1. Д. 22.

***Хәбибуллина Зилә Рәшит кызы,***
*тарих фәннәре кандидаты, РФА Уфа Гыйльми үзәгенең*
*Р.Г. Кузеев исеендәге Этнологик тикшеренүләр институты*
*диннәр өйрәнү бүлеге фәнни хезмәткәре*

## МӨСЕЛМАН РУХАНИЛАРЫНЫҢ 1905 ЕЛГЫ УФА КОРЫЛТАЕНДА КАРАЛГАН КАЙБЕР ПРОЕКТЛАР (Янә бер проект)[1]

Собрание даирәсенә [тирәсенә] дахил [катнашучы, керүче] мөселманнарның хаҗәтләрен бәян кылып, министрлар шурасының назарына тәкъдим кылынмыш проектның нөсхәсе корылтай мәҗлесләрендә укылып, маддәләренең әксәре [күбесе] кабул кылынып, дүрт маддә гыйлавә [өстәмә] кылынмыштыр. 12 хәзрәт каләме илә имза кылынмыш нөсхәдән алып, ул проектны да бу раддә яздым. Шул: «1903 сәнәдә игълан кылынмыш фәрман шаһанәдә, 1904 сәнә декабрь 12 һәм 1905 сәнә февраль 18 фәрман шаһанәләрендә император хәзрәтләре бөтен милләтләргә хөррияте диния ихсан [ярдәм, булышлык] итте. Россия мөселманнары да император хәзрәтләренең бу бөек ихсаннарына наил улды. Дин тотмакта хөрриятемез там [тулы, бөтен] исә дә, дини эшләремезне матлуб [тиешле, кирәк] рәвештә идарә итмәк өчен, безем янә шул хаҗәтләремез дә канун куәте илә безгә вирелсә иде:

1. Россиядә бөтен вилаятьләрдә, областьларда мөнтәшир [җәелгән] улып, әксәренең фәкыйрьлеге өчен бөтен мөселманнарны бер мәркәздә генә тупламак авырлыгына күрә, тиеш җирләрдә хаҗәт кадәре шөгъбәләр тәэсис кылынса иде.

2. Собрание, бөек бер мәхкәмәи исламия улмак сыйфаты илә, ялгыз дахилия назаратына [эчке эшләр министрлыгына] табигъ кылынып [буйсынып], вилаят правлениеләренә табигъ улмактан югары чыгарылса иде.

3. Мөфти милләт ихтыяры илә гомерлек сайланып, император хәзрәтләре тарафыннан, казыйлар халык ихтыяры илә алты сәнәлек сайланып, дахилия назары тарафыннан тәсдыйк кылыныр.

4. Даирәсенә дахил руханилар тиешле мәсьәләләрдә мөшаварә өчен собрание дәгъвәт итә [чакыра] булыр.

5. Хөкүмәт, начальство яхуд бөек мәхкәмәләрнең бере тарафыннан берәр мөһим мәсьәлә хакында фәтва я рәи [караш, фикер] соралса, собрание ялгыз үзе генә җавап вирмәеп, моктәдир руханиларның, могтәбәр зыялыларның мөшавәрәләренә мөрәҗәгать итәр.

6. Коръәни Кәримнең, дини китапларның табигына [бастыруына] назарат [күзәтү, контроль] собрание ихтыярына хәсыр кылыныр [билгеләнер].

7. Низам каршында тәгаен кылынмыш яшьләренә ирешмәгән кыз-егет үз ризалыгы илә никахны ихтыяр итсәләр, вөҗүдләренең тәхмиленә бакып [гәүдәләренең чыдавына карап], зарурәт [үтә кирәклек] сәгатьләрен игътибарга алып, собрание рөхсәт вирә булыр.

---

[1] Җарулла Муса. Ислахат әсаслары. Пг.: М.-А.Максутов типографиясе, 1917. Б. 91–105. Дәвамы. Проектларның бер өлеше «Фәнни Татарстан» журналының 2 нче санында дөнья күрде. Б. 75–85.

8. Мәҗүсиләрдән [потка табынучылардан, язычниклардан] бере исламият кабул итеп, мөселманнардан беренең никахына рәгъбәт [омтылыш] итәр исә, собрание рөхсәт вирә булыр.

9. Яһүдиләрдән [еврейлардан], православие мәзһәбенә, башка нәсраниятьтән [христианлыктан] бере мөселманнардан беренең никахына рәгъбәт итәр исә, собрание рөхсәт вирә булыр.

10. Мөселманнарның нәсранияләрдән, яһүдиләрдән туган балалары ислам дәфтәренә кайд кылынып [теркәлеп], мөселман игътибар кылыныр.

11. Ата-бабалары ислам рәсемендә [гадәтендә] гомер итмеш керәшен нам мөселманнарны собрание ислам дәфтәренә, ислам мәхәлләләренә кайд итә булыр.

12. Христиан руханиларына канун тарафыннан вирелмеш хокукларның һәммәсе ислам руханиларына да вирелер.

13. Имин алыначак урыннарның һәрберендә, мөселманнарның имине үз лисаннарында, ислам руханилары хозурында улыр.

14. Ислам хаҗиләренең паспортлары рус паломникларының паспортлары бәһасендә улыр.

15. Мәктәп-мәдрәсәләргә, мәсҗедләргә, тәрбия йортларына, шифаханәләргә, гомумият илә хәер максатларының һәрберенә һәр җирдән иганә тупламак ихтыяры мөселманнарга да вирелер.

16. Русларның ибтидаи, урта дәрәҗә мәктәпләренең һәрберендә ислам балаларына дин, лисан, язу дәресләре укытмак өчен собрание ислам мөгаллимнәре тәгаен итәр.

17. Гаскәри хезмәтендәге мөселманнар мәгаш [хезмәт хакы] һәм рәтбә [дәрәҗә, звание] хосусларында руслар илә бер хокукта улыр.

18. Ислам гаскәри өчен тиешле микъдарда [чамада] имамнар нәсыб кылыныр [хезмәткә билгеләнер].

19. Штаб имамнары христианнарның штаб руханилары илә бер хокукта улыр.

20. Руханилар, собрание әгъзалары русча ценздан азат кылыныр.

21. Руханилар хезмәт гаскәриядән азат кылыныр.

22. Руханилар хәбестән [кулга алудан, аресттан] азат улыр.

23. Шәхсыятьләрен [үз файдаларын кайгыртуларын] тәгъриф [белдерү, аңлату] юлында фотограф чыгартмак зәхмәте илә руханилар тәклиф [боеру, көчләп кушу] кылынмас.

24. Руханиларга хәзинә мөһере вирелеп, мәхкәмәләргә күндереләчәк рапортлары, гаризалары мөһерләнмеш исә, почтада мәҗанән [түләүсез, бушка] кабул кылыныр.

25. Чит мәмләкәтләрдә тәхсил итмеш рус тәбгасы мөселманнарга мөгаллим, мөдәррис я рухани булынмак хакы вирелер.

26. Мәсҗед бинасына мөсагадә хосусларында христиан руханиларының берәр сурәт илә мөдахәләләре [катышу, кушылулары] катгыян мәнгы [тыю] кылыныр.

27. Дини китаплар, чит мәмләкәт табигы улса да, дәстхат [кулъязма] улса да, мәктәп-мәдрәсәләрдә, мәсҗедләрдә мәмнугъ [тыелган] улыр.

28. Христиан кәлисәләренең [чиркәүләренең] биналарына, тәгъмирләренә [төзекләндерүгә, ремонтка] хәзинә урманнарыннан, земство сәрмаяларыннан носыл иганә кылыныр исә, ислам мәсҗедләренең биналарына да, тәгъмирләренә дә ул илә иганә кылыныр.

29. Мәсҗед бинасының рәсмият җәһәте собрание мөсагадәсе [булышуы, ярдәме] илә тәмам улыр.

30. Мөселман гаскәренә намаз, руза кеби үзләренең фараз гыйбадәтләрен, мөгаен вакытларында әда итмәк [үтәү], һәм дә җомга көннәрендә, бәйрәм көннәрендә штаб имамнары хозурында җомга, гает намазларын укымак мөсагадә кылыныр.

31. Мөселман гаскәренә хинзир [дуңгыз], хәмер кеби хәрам тәгам [ризык], хәрам шәраб вирмәк катгый мәнгы кылыныр [тыелыр].

32. Ислам, Коръәни Кәрим, шаригъ хәким [шәригать законнарын төзүче] хәзрәтләренә тагын [сүгү, хурлау], тәшнигъ [гаепләү, хурлау] юлында нәшер кылынмыш рисаләләргә, мәкаләләргә мокабәлә итмәк [каршы тору] ихтыяры, һәр мәсьүлиятьтән [җаваплылыктан] азат улмак тәэмине илә, мөселманнарның һәрберенә мөсагадә кылыныр.

33. Россия дәүләтендә, биля истисна [чыгармасыз] һәр җирдә, җир-йорт имляк [милекләр] сахибы улып җирләшә белмәк хакы Россия мөселманнарына руслар кеби биля шарт [шартсыз] вирелер.

34. Дәүләтнең ибтидаи [башлангыч], урта, бөек мәктәпләренең һәрбере ислам балаларына һәрвакыт ачык улыр.

35. Башкорт, кыргыз балалары ислам мәктәпләренә, мәдрәсәләренә һәрвакыт кабул кылыныр. Татар, башкорт шәкертләренә кыргыз арасында мөгаллим, мөдәррис, имам улмак хакы вирелер.

36. Тәгълим йортларына кабул кылыначак ислам балаларыннан үзләренең дин, лисан, язуларын белүләре хакында ибтидаи мәктәп шәһадәтнамәсе [таныкламасы] таләп кылыныр.

37. Рус мәктәпләрендә укучы ислам балаларының ислам дәресләренә инабәтле [ышанычлы] мөгаллимнәр васитасы илә [ярдәме белән] собрание һәрвакыт назарат итәр [күзәтер].

38. Иртидад итәчәк [диннән чыгачак] адәм балигъ түгел [несовершеннолетний] исә, гаризасы кабул кылынмас. Балигъ исә, собрание хозурында бер ай мөддәт [ара, вакыт] вәгазь-нәсыйхәт кылынмак гариза мәкъбүлияте [кабул ителү] өчен шарт улыр. Бунын хилафына [кире, каршы] хәрәкәт итәчәк адәмнәр, инсанның диненә тәгадди [гаделсезлек] итмеш улмак гөнаһы илә, низам каршында мәсьүл [җаваплы] улыр.

39. Мөселманнарның әхлакларын төзәтмәк, адабе динияләрен тәгълим итмәк, дөнья хәлләреннән хәбәрдар итмәк өчен үзләренең лисаннарында җәридә [газета], мәҗәллә [журнал], рисаләләр [брошюралар] нәшеренә мөсагадә вирелер.

40. Никах, нәсәб [нәсел-ыру, чыгыш], мирас, ризаг [сөт имү], хазана [өлеш, пай], талак, гадәт

кеби гаилә мәсьәләләре һәм дә буңа мөтәрәттиб [тәртипләнгән] мөһер нәфәка иҗра кеби хокукы малияләр һәммәсе ислам руханиларының мәгърифәтләренә, ихтыярларына тәслим кылыныр [бирелер].

41. Һибә [бүләк, буш бирү], васыять, вакыф кылынмыш милекләргә шәригатьнең хөкемнәрен иҗра кылып, тиешле кәгазьләрен тәсдыйк итмәк кодрәте собраниегә вирелер.

42. Вәрәсәдән [варислардан] бәгъзеләре сабый яки гаиб [югалган] улыр исә, собрание васый [опекун] нәсыб итәр [билгеләр].

43. Хассалары [өлешләре] шәригатькә муафыйк тәгаен кылындыктан соң, хасса кәгазьләрен мәхәллә руханилары тәсдыйк итә булыр.

44. Бөтен варисларның гадәден [санын] бәян итеп, тәкъсим [бүлү] хосусында гариза вирүчеләргә собрание үзе хассаларын тәгаен һәм тәсдыйк итәр.

45. Имамнар мөселманнарның дин башлары улмакларына күрә, голүме диниядә ысулдан, фөругтан [кисәк, бүлемнәрдән] камил дикъкать һәм игътинаэ итеп [әһәмият биреп], хатиплык, мөдәррислек имтиязларына [рөхсәтләренә] имтихан итмәк собрание икътидарына [көченә] махсус улыр.

46. Эшләренең, карарларының һәммәсеннән собрание һәр өч айда бер дәфга [кат, тапкыр] дахилия назаратына [Эчке эшләр министрлыгына] иҗмал дәфтәре [конспект, кыскача аңлатма] мәэмүрият [вазифа, командировка] гарыз итәр.

47. Вилядәт [туу], вафат, никах, талак хәдисәләрен [вакыйгаларын] кайд итмәк [беркетү] өчен метрика дәфтәрләре табгы иттереп [бастырып], даирәсенә дахил [тирәсенә кергән] мәхәллә имамнарының һәрберенә үзенең шөгъбәләре, ахундлары яхуд волость правлениеләре, шәһәр полицияләре васитасы [арадашлыгы] илә собрание нәшер итәр.

48. Метрикә дәфтәрләре төркичә язылыр.

49. Метрикә дәфтәрләренең дөреслеген тәфтиш [тикшерер] һәм мокабәлә иттерер [чагыштырыр].

50. Берәр сәбәп илә кайд кылынмаеп калмак вилядәт, никах, талак, вафаты метрикә дәфтәренә кайд иттермәк гариза илә соралыр исә, мәкъбүл гозерләрен исбат итеп сәнәләрен дә ачык тәгаен тәкъдирендә, собрание тиешле урыннарына кайд иттерер.

51. Һәм мәхәллә руханиялары, һәм собрание метрикә дәфтәрләреннән сәнәд [документ] кәгазе бирерләр.

52. Имамнар кулында метрикә дәфтәре мәгъзүр [гозерле] бер сәбәп илә тәләф улып [югалып, бозылып] соралыр исә, нөсхәләрен собрание яздырып күндерер.

53. Мөселманнардан алыначак имин сурәтләрен тәрҗемәсе илә бәрабәр табгы иттереп [бастырып], тиешле урыннарына собрание таратыр.

54. Собраниедән күндерелеп мәхәлләгә исаль [тапшыру, китереп бирү] кылыначак кәгазьләрне, дәфтәрләрне полиция тиешле урыннарына исаль итәр.

55. Мөнасиб [яраклы] җирләрдә тәрбия йортлары ачмак, җәмгыяте хәйрияләр тәэсис итмәк [оештыру] хакы да собрание икътидарына вирелер.

56. Җәмәгать тарафыннан сайланмыш адәм имтиханда әһлияте сабит [яраклы] улып, әхлак вә истикамәте [намуслылыгы] тәхкыйк [шиксез] кылындыктан соң, мәхәлли правлениеләрнең мөдахәләсеннән [катышуыннан] башка, ялгыз собрание ихтыяры илә тәсдыйк кылыныр. Указ, русча тәрҗемәсе илә бәрабәр, татарча улыр.

57. Сайланмыш руханиларның нәфәкасы [яшәү өчен кирәк булган азыгы] җәмәгать зиммәсенә [йөкләмәсенә] илзам кылыныр.

58. Руханилардан я шәригать, я низам хилафына берәр эш садыр улыр исә, гөнаһның дәрәҗәсенә күрә, бәгъдел тәфтиш [тикшергәннән соң] я тәнбиһ [кисәтү, искәртү], я гыйтаб [шелтә, орышу] яхуд газел итмәк [хезмәттән чыгару] ялгыз собрание икътидарында улыр.

59. Бөтен вазыйфаларын хак илә ифа итәчәге [үтәве] һәм дә хилаф [каршы] низам, хилаф шәригать һичбер хәрәкәттә булынмаячагына газеми [кискен ният] хосусында руханилардан мәнсабларына тәгаен сәгатьләрендә собрание имин алыр.

60. Шәригать җәһәтеннән назар кылыначак эшләре ислам руханилары васитасы илә собрание тәфтиш иттерер.

61. Мәхәллә җәмәгате илә имам арасында яхуд руханиларның ма бәеннәрендә [ике араларында] низаг [талаш] чыгар исә, собрание фасыл [аерым карар] итәр.

62. Бөек мәхәлләләре я җан, я ханә хисабы илә тәкъсим зарур улыр исә, тәкъсим мөсагадәсе собрание назарына мәхсур [чикләнгән] улыр.

63. Имамәт өчен яшь ля әкалле [ким дигәндә] 22 улып, ахундлык өчен ля әкалле 30 улыр.

64. Руханилар гыйбадәт, дини гамәл, шәргый рөсүм [салым, пошлина] кеби бөтен вазыйфаларын биля косур [кимчелексез], биля тәхәллеф [кичектермичә], иминнәренә муафыйк сурәттә ифа итәрләр.

65. Руханилар мәхәллә җәмәгатьләренә гүзәл әхлак, истикамәтле хәят хосусларында вәгазь-нәсыйхәт итәрләр.

66. Мәхәлләдә бер хатип, бер имам, бер мөәзиннән артык нәсыб кылынмас.

67. Ир җан хисабы 200 дән аз җирләрдә бер имам, бер мөәзин я бер хатип, бер мөәзиннән артык нәсыб кылынмас.

68. Руханиларга бер ай я зиядә мөсамәхә рөхсәте вирмәк собрание назарына махсус улыр.

69. Мәхкәмәләр я низами идарәләр тарафыннан хәвалә [бер эшне икенче берәүгә йөкләү, тапшыру] кылыначак хезмәтләрне башкарып, иҗрәтләрен [үтәүләрен] таләп юлында рапорт илә руханиларның мөрәҗәгатьләре соңында тиешле иҗрәтләрен собрание вирер. Бу илә иҗрәтләрне вирә белмәк өчен собрание махсус мая [нигез, капитал] тәшкил итәр.

70. Мәхкәмә тарафыннан руханиларга хәвалә кылынмыш дәгъваларда руханилар ике

тарафның һәрберен мөмкин кадәр солых [килешү, ризалашу] җәһәтләренә дәгъвәт итәр. Солых мөяссәр [җиңел, җайлы] улмас исә, шәригатьнең карарына муафыйк хөкем итеп, мәхкәмәягә рапорт язар.

71. Һиляльнең сөбүтенә [яңа айның шиксез барлыкка килүенә] мөтәвәккыйф [бәйләнгән] гыйбадәтләрдә ахундлардан, руханилардан мәгълүмат тупладыктан соң кабул кылынмыш карарын һәммә руханиларга собрание игълан итәр.

72. Мәсҗеде юк карьяларда мәсҗед бинасына рөхсәт алмак өчен гадәд шарт улмас.

73. Яңа мәсҗед бина итмәк өчен җәмәгатьнең приговоры шарт улып, иске мәсҗедне тәгъмир [төзү, яңарту] рөхсәте өчен имамның рапорты кяфи [җитәрлек] улыр.

74. Зарурәт икътиза [үтә кирәклек] итәр исә, мәсҗеде капамык ялгыз собрание назарына махсус улыр.

75. Мәктәпләр, дини мәдрәсәләр собрание идарәсендә улып, билвасита дахилия назаратына табигъ улыр.

76. Мәктәп-мәдрәсә ачмак хосусында собраниедән рөхсәт алыныр, яхуд биналары тәмам улып ачтыктан соң собраниега игълам кылыныр.

77. Мәктәп-мәдрәсәләргә назараты өчен собрание муафыйк имамнарны, мөдәррисләрне тәгаен итәр. Назыйрлар шәкертләрнең әдәби җәһәтләренә, дәресләренә мөгаллим-мөдәррисләрнең тәгълимнәренә дикъкать итәр.

78. Үзенә табигъ мәктәп-мәдрәсәләр хакында собрание махсус дәфтәрләр тотар.

79. Шәкертләр, дәресләр, китаплар, мөгаллимнәр, мөдәррисләр хакында тиеш мәгълүматны һәр сәнә җәмгы итәр.

80. Собрание һәр сәнә һәр мәдрәсә шәкертләрен имтихан иттерә белер.

81. Дини китапларны мәдрәсә сәнәләренә, таләбәләрнең әхваленә күрә һәр мөдәррис үзе интихаб итә [сайлый, аралап ала] белер. (Корылтай мәҗлесләрендә шул проект укылып, маддәләренең әксәре мәгъкуль күрелдегеннән соң, янә дүрт маддә зиядә кылынмыш.)

82. Собрание һәр һәфтә [атна] алты көн эш күреп, җомгаларда, ислам бәйрәмнәрендә, падишаһ көннәрендә тәгътыйль итәр [ял итәр, туктап торыр].

83. Һәммә Россия мөселманнары җомга, гаед көннәрендә, Царский көннәрдә тәгътыйль кылып; якшәмбеләрдә, христианнарның дини праздникларында тәгътыйль итмәсләр.

84. Руханилар җомга, бәйрәм көннәрендә һичбер хезмәт өчен һичбер мәхкәмә тарафыннан дәгъвәт кылынмас.

85. Мөбарәк Рамазанда мөселман гаскәри билкөллия [бөтенләй, тулысынча] азат улыр. Һич улмаса, тәгамнәре, чәйләре ифтар, сәхәр сәгатьләренә татбикъ кылыныр.

Корылтай мәҗлесләренә риясәт итмеш дамелла Габдулла хәзрәт Апанай имзасы илә бәрабәр 12 хәзрәт 85 маддәдән гыйбарәт шул ляихәдә имза итмешләр.

Шурага кадәр нәкыль кылынмыш проектларның, ляихәләрнең маддәләре бере дигәренә

тәмам мотабикътыр, яхуд бере дигәренең нөсхәседер. Башкалык аз мөтәхалиф маддәләре дә вар. Интикадимы соңра [тәнкыйтьтән соң] бәлки язармын, хәзер хикәят юлына дәвам итәем.

**Министрлар шурасына виреләчәк петиция ляихәсенә материал улмак үзрә мөхтәрәм Хәсәнгата казый хәзрәтләре тарафыннан хәзерләнмеш маддәләр:**

1. Мөселманнарның гыйбадәтләре, дини эшләре тәмам үз ихтыярларында улып, руханиларын нәсыб итмәк, газел итмәк, мәктәп-мәдрәсәләрне идарә итмәк; судларга, төрмәләргә, гаскәрләргә, рус мәктәпләренә мөгаллимнәр, имамнар тәгаен итмәк кеби эшләр һәм дә никах, талак, мирас, нәфәка кеби гаилә эшләре ялгыз собрание ихтыярына махсус улса иде.

2. Собрание үзенең хәзерге гайре табигый хәленнән, ягъни түбәнлегеннән, ялгыз әмернамәләр илә генә идарә кылынмак интизамсызлыгыннан чыгарылса иде. Бәлки бөек рухани мәхкәмә игътибар кылынып, һәр җәһәте законда ачык тәгаен кылынмыш хосусый маддәләр илә идарә кылынса иде.

3. Буннан соң мөфти иң мөмтаз дин галимнәреннән халык ихтыяры илә сайланса иде. Патриарх кеби бөек руханилардан, вәлиләрдән түбән хисап кылынмаса иде.

4. Собрание әгъзалары да халык тарафыннан сайланып, нәсыб та, газел дә мөфтиләрнең мөдахәләләре булынмаса иде.

5. Әгъзалар низам кашында да казый аталып, мәгашләре ля әкалле 1200 рубля улса иде. Өч сәнә мөддәт илә генә сайланып читтән килүләренә күрә, казыйларга да квартира һәм җиһаз хәзерләнсә иде.

6. Собрание секретаре бөек образование сахибы улмак шарт улып, мәгаше дә ля әкалле 1200 улса иде. Өстәл түрәләренең дә мәгашләре, тәрҗеманнарның мәгашләре зиядә кылынса иде.

7. Собраниенең үзенә махсус типография лязимдер. Метрика дәфтәрләре, мәхәллә руханиларына, мәктәп-мәдрәсә мөгаллимнәренә, назарларына циркулярлар, әмернамәләр, дәстүрләр, китаплар, нәсыйхәтләр халык һәм гаскәргә хаҗәт ула булачак зикерләр, дәгъвалар собрание матбагасында табгы кылыныр.

8. Собрание матбагасында табгы кылыначак шәйләрнең һичбере собрание карары булынмадыкча цензура вирелмәс.

9. Собрание әгъзаларына, чиновникларына хәзинә тарафыннан вирелеп килә торган жалованиеләрен тиешенчә арттыру өчен, собраниенең башка хәраҗатларын [чыгымнарын] да тәэмин итү өчен, һәрбер туган бала башыннан, һәр никахтан, һәр мирастан мөгайян [билгеләнгән] бер микъдар [чама, өлеш] рәсми алыныр.

10. Собрание карарларын, фәрманнарын, мохабәрәләрен [хәбәрләшүләрен], руханиларның интикал [күчү, урын алмаштыру], газел [хезмәттән чыгару, урыннан төшерү], вафатларын, мөселманнарның мирасларын, дини я гыйльми мәкаләләре нәшер итмәк өчен айлык бер мәҗәллә [журнал] нәшер кылынып, халык мөгайян

бәһасе илә иштиракь итеп [уртак булып, катнашып]; руханилар, мөгаллим-мөдәррисләр мөмтаз [югарырак] бәһасе илә, әлбәттә, иштиракь итәр.

11. Мәхәллә руханилары искечә халык ихтыяры илә сайланып, собраниедә имтихан кылынып тәсдыйк кылыныр.

12. Ислам руханилары, мөгаллим-мөдәррисләре собраниедән магадә [башка, бүтән] һичбер җиргә табигъ [буйсынучы] улмас. Анларга юнәләчәк әмер, фәрманнар, сөаль-фәләннәр собрание васитасы [арадашлыгы] илә юнәлер.

13. Ислам руханилары һәр хокукта православие руханилары кеби улыр. Һәм дә ата-баба сословиесеннән хисап кылынмаеп, духовный сословиедән хисап кылыныр. Карья руханилары крестьянский судларга табигъ улмас; гаскәр хезмәтенә алынмас, государственный, земской, мирской налоглар түләмәс. Ләкин җир, тиҗарәт [сәүдә, сату] виргуләрен вирер.

14. Руханиларның гаиләсе дә руханилык хокукы илә файдаланыр.

15. Мәхәллә руханиларының җәмәгать тарафыннан хосуллары [керем, файдалары] һәр сәнә, һәр көн ноксанда [кимчелекле, җитешсез]. Руханиларның мәгашләре өчен никах, талак, виләдәт, вафат кеби даими хосул мәнбәгъларыннан [чыганакларыннан] мөгайян бер микъдар алыныр. Карья җирләрендә һәр басу саен бер микъдар җир һәм печәнлек вирелер. Шәһәр җирләрендә я квартира, я йорт хәзерләнеп вирелер.

16. Руханиларга русчадан ценз ихтыярый улыр.

17. Мәхәллә руханиларына гүзәл әхлак, истикамәт [намуслылык, турылык] шарт кылыныр. Һәр җомгада вәгазь сөйләмәк; тугрылык, пакьлек юлларына күндерү, яхшылык хосусларында рәһбәрлек [җитәкчелек, юлбашчылык] итү руханилар үзәрендә иң бөек вазыйфа улыр.

18. Имтихан өчен собраниедә мәгълүм вакытлар тәгаен кылыныр. Имтихан сәгатьләренә руханилар һәм дә мәхәллә җәмәгатьләре дә дәгъвәт кылыныр. Имтихан кылыначак адәмнәрдән голүме шәргыя һәм дә үзләренә лазем закон маддәләре, өстләренә лазем хезмәт вазыйфалары, мәхәллә җәмәгате илә могамәлә әдәпләре соралыр.

19. Мәктәп-мәдрәсәләр дәресләренең програмнары мәгариф назаратыннан чыгарылып, халык ихтыярына тәслим кылынса иде. Собраниедә әһлияте исбат кылынмыш әфәнделәр арасыннан мөгаллим, мөдәррис сайламак хакы да, идарә җәһәте дә халык ихтыярында улыр.

20. Мәктәп-мәдрәсәләрнең һәммә җәһәтләрен идарә итеп, Уфа собраниесенә һәр сәнә хисап вирелеп тормак өчен, халык үз араларыннан өч-дүрт яхуд дәһа зиядә [тагын да күбрәк] мөтәвәллиләр [мәчет, мәдрәсә эшләрен башкаручы кешеләр] интихаб итәрләр [сайлап алырлар]. Арадан бере рәис улыр. Мөтәвәллиләрнең исемнәрен, фамилияләрен, сыйфатларын собрание махсус дәфтәрләрдә забыт итәр [язып куяр].

21. Дини мәдрәсәләрдә һәммә голүме диния, һәмдә тиешенчә

мәгариф гомумия тәхсил кылыныр. Дини мәдрәсәләр өчен дәрес китаплары интихаб итеп тәгаен итмәк бер һәйәте гыйльмия мәгърифәтенә тәслим кылыныр.

22. Дини мәдрәсә дәресләрен тәмам итеп руханилык хезмәтләренә хәзерләнмеш шәкертләр, әлләрендә [кулларында] собрание шәһадәтнамәсе булыныр исә, хезмәт гаскәриядән азат улыр. Һич улмаса студентлар кеби бер сәнә хезмәт илә иктифа [канәгатьләнү] кылыныр.

23. Мәхәллә мәктәп-мәдрәсәләренә дә мәхәллә руханилары мөгаллим, мөдәррис, мөтәвәлли ула булыр.

24. Мәктәп-мәдрәсә нәфәкасы [яшәү өчен кирәк булган малы (азыгы)]: 1) земстволардан алыныр, христиан мәктәпләренә земство никадәр вирер исә, ислам мәктәп-мәдрәсәләренә дә улкадәр вирер; 2) әһле хәйратның [садака бирүченең] хосусый иганәләреннән, ихсаннарыннан [ярдәм, булышлыкларыннан]; 3) вар исә, вәкыфлардан; 4) мәктәп-мәдрәсәләрдә укучы шәкерт башыннан.

25. Һәр мәктәп, һәр мәдрәсә үзенең шәкертләренә шәһадәтнамә вирер.

26. Әгәр дә халыкның бәхетенә каршы Россиядә гомуми тәгълим мәҗбүри улыр исә, мәктәп-мәдрәсә шәһадәтнамәсе кяфи [җитәрлек] хисап кылыныр.

27. Мөселманнар өчен махсус учительский школаларда инспекторлар, мөгаллимнәр мөселманнан улмак шарт улыр.

28. Учительский школа сыйныфларына кабул кылынмак өчен яшь шарт улмас, бәлки рәгъбәте [теләге, омтылышы] вар һәм адәм, нәкадәр яшь исә дә, кабул кылыныр.

29. Учительский школаларда голүме диния учительский семинарияләрдә «Закон Божий» кадәр укылыр. Дин мөгаллимнәре собрание тарафыннан тәгаен кылыныр.

30. Учительский школаларда таләбәләрнең тәрбиясе, хәяте һәр җәһәт илә исламның милли-дини әдәпләренә муафыйк улыр.

31. Учительский школалардан чыгачак мөгаллимнәр ибтидаи мәктәпләрдә ислам балаларын тәгълим, тәрбия итәчәкләренә күрә, учительский школа дәресләре мөселманнарның ихтыяҗларына, заруратларына, файдаларына мөнасиб сурәттә тәртип кылынса иде. Рус тарихы илә бәрабәр төрек тарихы да, ислам тарихы да; рус грамматикасы илә бәрабәр төрек нәхүы [синтаксисы] да, сарыфы [морфологиясе] да укылса иде.

32. Рус мәктәпләрендә ислам балалары өчен дин мөгаллиме куелып, рус балаларының дин дәресләренә никадәр сәгать тәкъдир кылынса, ислам балаларының дин дәресләренә дә улкадәр тәгаен кылыныр.

33. Тиҗарәт [сәүдә], санаигъ кеби хосусый мәктәпләрне мөселманнар тәэсис итә белсә иде, ул мәктәпләрне хокук җәһәте илә хөкүмәт мәктәпләре кеби улса иде.

34. Мәктәпләрнең береннән шәһадәтнамәсе вар мөселман һәр җәһәт илә: хокук җәһәте илә дә, урын хезмәт алмак җәһәте илә дә руслар илә бер дәрәҗәдә хисап кылынса иде.

35. Мөселман гаскәри мөмкин кадәр бер җирдә тупланып, имам тәгаен кылыныр. Русларның военный попларына хәзинәдән никадәр вирелер исә, гаскәр имамнарына да улкадәр вирелер. Мөхарәбә [сугыш] заманнарында имамнар арттырылыр.

36. Мөселман гаскәриләренә, рус мәктәпләрендә укучы ислам балаларына русларның гыйбадәтләре сәгатендә һәм дә диннәрен тәгълим сәгатьләрендә хазир улмак [шунда булу, катнашу] мәҗбүри улмаса иде.

37. Цензура алга кылынсын. Һич булмаса ислам китаплары да гомуми цензура уставларына табигъ улып [буйсынып], хосусый цензура бетсен. Цензура статьялары гаять ачык төзелеп, ислам китаплары өстендә цензорларга шалить итәрлек урын калмасын.

38. Әдәби, фәнни, дини, сәяси рисаләләр, җәридәләр, мәҗәлләләр нәшер итмәк хосусларында һичбер сурәт илә тарлык кылынмасын, әүвәлдәге кеби миссионерлык кылучылардан рәи [караш, фикер, уй] соралмасын.

39. Земстволарда, шәһәр думаларында дин һәм җенсиять башкалыгы игътибар кылынмасын, мөселманнар һәр хосуста русларга бер дәрәҗәдә игътибар кылынсын, мөселманнарны мәхрүм итә беләчәк высокий цензлар бетсен. Мөселман бар земстволарда, думаларда тавыш күплеге илә мөселманнардан сайланмак мөмкин булмаса да, берничә мөселман сайламак лазем улсын.

40. Дин һәм җенсиять башкалыгы игътибар кылынмаеп, бөтен халыктан тупланган сәрмая русларның ялгыз үзләренә махсус хаҗәтләренә никадәр сарыф кылыныр. Мөселман хиссасына [өлешенә, үзенә тиешле күләмгә] төшәчәк микъдар мөселманнарның үзләренә вирелер.

41. Урта вилаятьләрдә мөселманнарның әксәре [күбесе] крестьян сословиясеннән хисап кылына. Шул тоткынлык бәндәлек заманаларыннан калма мәнфур [нәфрәт ителгән] исем илә Россиядә һичкем аталмаса иде. Бәлки хөррият вирүче император теләгәнчә, я сельский обыватель, я поселян, я хлебопашец кеби исемнәр илә аталса иде. Шул крестьянин сүзе христианин сүзеннән бозылма сүз булганлыгы өчен, хосусият илә мөселманнар шул крестьянин исеме илә аталмаса иде.

42. Миссионерлык кылучы христианнар ислам балаларын тәрбия итүдән катгый сурәттә мәнгы [туктату, булдырмау] кылынса иде.

43. Нагяһ [көтелмәгәндә, аңсыздан] арттан кылачак бер адәм табылса, ислам руханилары хозурында ля әкалле [иң кимендә] бер ай мөддәт [ара, вакыт] вәгазь кылынмак шарт кылынса иде.

44. Ислам дине үзәрендә туган, торган, ислам динендә гомер иткән, һичбер вакыт һичбер җирдә христиан диненә кучмәгән, кәлисә метрикәләрендә исеме язылмаган, асылсыз «отпавший от православия» исеме вирелгән бичара мөселманнар хәзерге хәлләре кеби газапта тотылмаса иде. Бәлки үзләренең миллион кат таләпләре буенча рәсми мөселман хисап кылынса иде. Ул бичаралар вөҗдан куәте илә кәлисәдән, закон куәте илә мәс-

җедтән мәмнүгъ [тыелган] улып, диннән-гыйбадәттән мәхрүмдер.

45. Миссионерлык кылучылар мөселманнарның диннәренә тәгадди итүдән [җәберләүдән, рәнҗетүдән], ялан яла ябу кеби эшләрдән мәнгы кылынса иде. Ул илә эшләрдә хөкүмәт өчен дә, христианлык өчен дә зарардан башка һичбер файда юк.

46. Мәсҗед-мәдрәсә бина итмәк, ислам мәхкәмәләренә адәм тәгаен итмәк кеби хосусларда миссионерлык кылучыларның рәиләре [карашлары] һәм дә мөселманнарның эшләре хакында Синод заключениесе соралмаса иде.

47. Мәктәп-мәдрәсәләргәме, мәсҗедләргәме яхуд башка хәйрат юлларынамы вәкыф кылыныр исә, вакыйфның ихтыярына муафыйк сурәттә вәкыф тәсдыйк кылыныр. Мәктәп-мәдрәсәләр, мәсҗедләр файдасына вәкыф кылынган җирләрдән, йортлардан, маллардан һичбер налог виргу алынмас.

48. Мөселманнарның каберстан җирләре, мәсҗед җирләре мөкаддәс игътибар кылынып, ул җирләрдә мәктәп-мәдрәсә, мәсҗедтән магада [башка, бүтән] һичбер шәй бина кылынмас. Ул җирләр һичбер бәһанә [сылтау, сәбәп] илә алынмас.

49. Россия мөселманнарының петицияләренә кушылып, бөтен милләтләрнең интеллигенцияләре илә бәрабәр, Россия мөселманнары да закон кашында бөтен халыкның гомуми мөсавәтләрен [тигезлекләрен]; диннең, матбугатның, иҗтимагларның [җыелышларның], сүзнең хөрриятләрен таләп итәр. Һәр фәрднең [затның] шәхесе һәр җирдә, һәрвакыт хөр улыр, мәхкәмә карары булынмадыкча, администрация юлы илә һичбер фәрд һичбер вакыт тоткын улмас, хокукта тәхдид [чикләү] сәбәбе кылынмас.

Мөхтәрәм казый Хәсәнгата хәзрәтләренең шул 49 маддәсе әүвәлге ляихәләрдә, проектларда нәкыль [сөйләнгән] кылынмыш маддәләрнең тәкрары [кабатлау] кеби исә дә, үз башына мөстәкыйль сурәттә язылып, бәгъзе мөһим зиядәләренең дә варлыгына күрә, бу раддә тәмам илә нәкыль иттем.

*Текстны гарәп имласыннан кирилл алфавитына күчереп, сүзлекне һәм аңлатмаларны Казан федераль университетының Н.И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханә хезмәткәре* ***Шәрәфиева Рәисә Гамир кызы*** *әзерләде*

УДК 372.881.512.145

*Э.Г. Багирова*

# БАЛАЛАР БАКЧАСЫНДА ТАТАР ТЕЛЕ УКЫТУНЫҢ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Обучение детей татарскому языку в детском саду – одна из самых сложных методических задач. Для того чтобы обучение принесло положительный результат, нужно правильно построить процесс обучения, при котором сохраняется самобытность и специфика дошкольного детства, нормальный ход развития детей. Раньше в преподавании языков доминировали академичность, теория, но сейчас идет обращение к практике ориентированности, мультимедийности, обучения с помощью игр, сказок, мультфильмов.

**Ключевые слова:** татарский язык, обучение с помощью игр, теория, методика.

Милли мәдәниятне, халыкның гасырлар дәвамында формалашкан рухи байлыгын бары шул халыкның теле ярдәмендә генә үзләштерергә мөмкин. Туган телне балаларга кече яшьтән үк өйрәтеп кенә, аларда телгә һәм шул тел аша халыкның мәдәниятенә мәхәббәт тәрбияләргә мөмкин. Бу учреждениеләрдә балаларга татар телен өйрәтү катлаулы методик бурычлардан санала. Балалар бакчаларында тел өйрәтү методлары һәрвакыт үсеш-үзгәрештә булып, соңгы елларда балалар бакчаларында татар теле укытуда да яңа методларга ныграк игътибар юнәлтелә. Хәзерге вакытта мәктәпкәчә яшьтәге балаларга татар теле укытуның методлары бу процессны укытучы өчен дә, бала өчен дә кызыклырак итүгә юнәлтелгән. Белем бирүдә, академиклыкка, теорияне өйрәтүгә басым ясау урынына, уеннар, халык иҗаты, мультфильмнар ярдәмендә, мультимедия, практика аша тел өйрәтү алгы планга чыга. Ягъни балалар телне уен аша, уйнап өйрәнәләр. Уйнау – бала өчен табигый халәт. Шуңа күрә бала белән аралашканда үзара аңлашуга да уен аша ирешү җиңелрәк. Шул ук вакытта шуны да истән чыгарырга ярамый, теләсә кайсы стресс халәте баланың уйнарга булган теләген һәм, нәтиҗә буларак, чит телне өйрәнергә булган омтылышын юкка чыгара. Димәк укытучы дәрестә, уен атмосферасы тудыруга һәм уен ярдәмендә телне өйрәтүгә ирешү өчен, уңай эмоцияләргә нигезләнгән фон сакларга кирәклеген истә тотарга тиеш була. Шуңа күрә балалар дәрестә үзләрен иркен тотарга, йончымаска һәм кызыксынуларын сакларга тиеш. Дәрес шартлары никадәр комфортлы булса, чит телне өйрәнү процессы шулкадәр интенсив бара. Балаларга уен аша телне өйрәтү укытучыдан югары профессионализм, күп төрле сәләткә ия булуны һәм зур тырышлык таләп итә. Укыту процессы уңай нәтиҗәләр бирсен өчен, мәктәптәгечә, балаларның яшь үзенчәлеге һәрвакыт искә

алынырга тиеш. Бу очракта, беренче чиратта, укыту процессы бала өчен кызыклы һәм файдалы булырга, тел өйрәтү мәктәп дәресенә әйләнеп калмаска тиеш.

Балалар бакчаларында тел дәресләрендә дидактик уеннар куллану бик отышлы. Ул балага тел өйрәтүнең бер формасы да, шул ук вакытта баланы төп шөгыленнән – уеннан да аермый. Дидактик уеннарның асылы, аларның исеменнән үк аңлашылаганча, өлкәннәр тарафыннан өйрәтү һәм тәрбия максатыннан уйлап чыгарылганнар. Әмма балаларга уенның тәрбияви һәм белем бирү функциясе алга чыкмый, тәрбия һәм белем бирү уен шартлары, кагыйдәләре, хәрәкәтләре аша тормышка ашырыла.

Шәхси тәҗрибәмнән чыгып, балалар бакчасында балаларга татар теле өйрәтүнең кайбер мәсьәләләре белән таныштырып үтәргә булдым. Озак еллар мәктәпкәчә яшьтәге балалар учреждениеләрендә эшләгәннән соң, балаларга белем бирү процессында нәкъ дидактик уеннарның әһәмияте зур булуны аңлыйсың. Дидактик уеннар – педагогикада балаларны укыту һәм тәрбияләү максаты белән махсус төзелгән уеннар ул. Бу уеннар аерым бер мәсьәләне хәл итүгә юнәлтелә, шул ук вакытта аларда уен процессының баланы тәрбияләү һәм белем алу күнекмәләрен үстерү эшчәнлеге дә чагыла. Дидактик уеннарның мәктәпкәчә яшьтәге балаларның танып-белү эшчәнлеген активлаштырудагы, мөстәкыйль танып-белү эшчәнлеген формалаштырудагы әһәмияте дә зур. Балалар бакчаларында укыту процессы нәкъ дидактик уеннарга нигезләнеп оештырыла. Балаларның өйрәнелгән материалны ныгыту процессында да дидактик уеннар ярдәмгә килә.

Дәрестә дидактик уеннар кулланганда, алар түбәндәге максатларга җавап бирергә тиеш:

1. Программада каралган материалны яхшырак үзләштерергә ярдәм итү.

2. Татар теленең лексикасын (ягъни аерым тематик төркемнәргә караган сүзләрне) үзләштерергә ярдәм итү.

3. Сөйләм материалын уен формасында ныгыту, татар телен өйрәнүгә кызыксынуны арттыру.

Укыту эшчәнлегендә файдаланылган теләсә кайсы уен методикасының нигезе түбәндәге принципларга нигезләнә: дидактик материалның актуаль булуы һәм дөрес сайлануы балаларга мәсьәләләрне уен дип кабул итәргә булыша, дөрес һәм иң отышлы җавап табарга омтылыш тудыра. Дидактик уеннарның тагын бер әһәмияте шунда, бу уеннар аша балалар бердәм группа булып зуррак һәм катлаулырак мәсьәләләрне хәл итәргә сәләтле коллективта эшләргә өйрәнә. Ярышып эшләү балаларда эшне тизрәк һәм башкаларга караганда нәтиҗәлерәк тәмамлауга этәрә, бу, бер яктан, билгеле бер мәсьәләне чишүгә бирелгән вакытны кыскартса, икенче яктан, тел өйрәнүдә дә реаль нәтиҗәләр бирә.

Тел өйрәтү дәресләрендә кулланылган дидактик уеннар түбәндәге таләпләрне истә тотып сайланырга тиеш. Һәр дидактик уен бала өчен яңалык алып килергә тиеш. Анда узган дәресләрдә

очрамаган яңа элементлар кертелү зарур. Балалар уйнарга теләмәгән уенны мәҗбүриләп бирү тискәре эффект бирә ала, һәр бала үз теләге белән уенга керергә тиеш. Балаларның үзләренә ошамаган уеннан баш тартырга, башка уен сайларга мөмкинлеге булырга тиеш. Уен – ул дәрес кенә түгел. Балаларны яңа темага алып керә торган, ярыш элементлары кергән, әкият дөньясы белән таныштырган уен алымнары, беренчедән, укытучының методик байлыгы һәм сәләте булса, икенче яктан, балаларның тәэсиргә бай уртак эш процессы да. Укытучының эмоциональ халәте дә ул оештырган эшчәнлеккә туры килергә тиеш. Башка методик чаралардан аермалы буларак, дидактик уенның тиешле нәтиҗәләр бирүе оештыручының халәтенә дә бәйле. Укытучы уенны оештыра белергә генә түгел, балалар белән үзе дә уйный белергә тиеш.

Дидактик уеннар барышында баланың үз-үзен тотышы аша, аны яхшырак өйрәнергә, проблемаларын ачыкларга мөмкин. Уйнаганда баланың уңай һәм тискәре сыйфатлары ачыла. Уен кагыйдәләрен яки уен атмосферасын бозган бала белән йомшак кына сөйләшү, аңлашу да уңай нәтиҗәләр бирә. Әмма балага җәза бирелергә тиеш түгел.

Балаларга бакча яшеннән туган телне өйрәтү – хәзерге вакытта дөнья күләмендә актуаль проблемаларның берсе. Хәзерге вакытта Татарстан Республикасында да балалар бакчаларында татар телен өйрәтү актуаль мәсьәлә. Туган телне, татар телен аралашу чарасы буларак яхшы өйрәнү, киләчәктә яхшы белем алу өчен генә түгел, баланың интеллектуаль һәм әхлакый җитлегүе өчен дә мөһим.

Телне максатчан рәвештә өйрәнүнең зарурияте Л.С. Выготский, А.М. Шахнарович, А.А. Леонтьев, Г.Ш. Әсәдуллин, Ф.Ф. Харисов, Ч.М. Харисова һәм башка галимнәрнең фәнни хезмәтләрендә чагыла. Галимнәр тел өйрәнү өчен нәкъ мәктәпкәчә яшьнең сенситив чор булуын, бу яшьтә баланың телгә караган информацияне кабул итәргә һәм ныклап хәтерендә калдырырга эмоциональ яктан әзер булуын ассызыклыйлар. Теләсә кайсы телнең төп функциясе аралашу чарасы булган кебек, балалар бакчасында тел өйрәтүнең төп максаты да – коммуникация, ягъни шул телдә сөйләшергә өйрәтү.

Баланы сорауларга җавап бирергә генә түгел, үзен дә сораулар бирергә, сөйләшергә, әңгәмәдә катнашырга, яшьтәшләре белән аралашырга өйрәтү мөһим.

Шуңа күрә без татар телен өйрәтү процессын, бу эшкә ата-аналарны, балалар бакчасы тәрбиячеләрен дә җәлеп итеп, өзлексез процесс итәргә омтылабыз. Балаларга татар теле өйрәтүдә балалар бакчасы тәрбиячеләре, педагоглар да һәрдаим ярдәмгә килә. Аларның татар телен өйрәнүенең әһәмиятен аңлап, тел өйрәтү процессында булышлык итүе укытучы өчен дә зур стимул булып тора. Чөнки бары тел өйрәтү процессы бер укытучының тырышлыгы белән генә тиешле нәтиҗәләрне бирә алмый.

Безнең мәктәпкәчә яшьтәге учреждениедә «Без татарча сөй-

ләшәбез» дигән укыту-методик комплексын тормышка ашыру (УМК «Говорим по – татарски») өч юнәлештә башкарыла:

1. Балаларны дәүләтебезнең ике телендә укыту (рус һәм татар телләре).

2. Рус теле тәрбиячеләренә татар телен өйрәтү.

3. Балалар бакчасында балалар һәм тәрбиячеләр өчен татар телендә аралаша торган милли мохит булдыру.

Безнең балалар бакчасына балаларга дәүләтебезнең ике телендә дә белем һәм тәрбия бирә торган 15 төркемдә 380 бала йөри. Бу балалар өчен атнага өч тапкыр татар теле дәресләре уздырыла. Бер дәрескә балаларның яшеннән чыгып 20–30 минут вакыт бүленә.

Балалар татар теле дәресләренә теләп йөриләр. Дәресләрдә телне уен формасында өйрәнәләр, татар халкының тарихы, мәдәнияте белән танышалар, татар телендә мультфильмнар карыйлар. Каралган мультфильмнардан соң, шул сюжетка ясалган рәсем күргәзмәләрендә дә балалар бик теләп катнаша. Ул рәсемнәрдән ата-аналар өчен күргәзмәләр дә оештырабыз.

Татар теле дәресләре махсус җиһазландырылган кабинетта уздырыла. Кабинетта балаларны Татарстан Республикасы халыкларының тормышы, этнографиясе, мәдәнияте, көнкүреше белән таныштыру өчен материал тупланган. Татар телен дәресләрендә өйрәнгән уеннарны балалар дәрестә генә түгел, урамда йөргәндә, кичке буш вакытларында да уйныйлар. Татар теле дәресләрендә татар теле өйрәнү дәфтәрләре белән эшлибез. Тел өйрәнү процессын кызыклырак итү максаты белән дәресләрдә аудио- һәм видеоматериаллар, тематик иллюстрацияләр кулланыла. Кабинетта сөйләм эшчәнлеген активлаштыруга юнәлтелгән дидактик уеннар тупланган күргәзмә әсбаплар, мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен татар телендәге матур әдәбият, методик әдәбият саклана.

Һәр яшь категориясе өчен «Татарча сөйләшәбез» дигән махсус почмак әзерләнгән. Биредә балаларның яшь үзенчәлекләре искә алып әзерләнгән, билгеле бер яшьтәге балалар үзләштерергә тиешле тел материаллары, лексик ярдәмлекләр дә урын алган.

Рус телле педагог-тәрбиячеләр «Ана теле» дигән онлайн проектны уңышлы үттеләр. Бу – тәрбиячеләрнең сүзлек запасын баетты, аларга балалар белән уеннар вакытында татар телендә аралашырга этәргеч булды. «Татарча сөйләшәбез» УМКы буенча тәрбиячеләр һәм ата-аналар өчен уздырылган махсус чаралар аларның сүзлек запасын баетырга ярдәм итте. Өлкәннәр балага чит телдә аралашырга өйрәтүдә ярдәмче була, төрле сүз һәм сүзтезмәләрне тиешле урында кулланырга өйрәтә. Шуның нәтиҗәсе буларак, балаларга да татар телендә аралашу өчен, балалар бакчасыннан тыш та сүзлек запасларын баетырга, бакчада өйрәнгән сүзләрне яки сүзтезмәләрне, кирәкле текстларны кабатларга һәм истә калдырырга мөмкинлекләр артты.

Ел дәвамында тәрбиячеләр һәм балалар бакчаларында эшли

торган башка белгечләр өчен «Балаларга дәүләтебезнең ике телен дә өйрәтү буенча авторлык УМКы» дигән юнәлеш буенча консультацияләр уздырылды. Башкарылган эшләр милли тәрбия бирүне, балаларга татар теле өйрәтү буенча эшчәнлекне тагын да югарырак нәтиҗәләргә күтәрергә мөмкинлек бирде. Эш практикасында алда искә алынган УМК буенча эшләү белем бирүнең сыйфатын үстерүгә, балаларда татар телен өйрәнүгә кызыксыну уятуга китерде. Балаларга татар теле укыту буенча үткәрелгән мониторинг аларның татар телен теләп өйрәнүләрен һәм тел буенча белемнәренең югары булуын күрсәтте.

«Татарча өйрәнәбез» дигән УМКы буенча башкарылган эшнең нәтиҗәсе – 2017 елда безнең балалар бакчасы коллективы республика күләмендә уздырылган «Иң яхшы ике телле балалар бакчасы» дигән конкурста катнашып җиңүче булды.

Татар телен киләчәктә өйрәтү буенча түбәндәге перспективалар күзаллана:

педагоглар белән татар телен өйрәнү буенча эшне дәвам итү;

татар теле декадасы оештыру;

татар теле укытучыларының фәнни-гамәли конференциясен оештыру һәм уздыру;

һәр ел була торган музыкаль-әдәби кичәләрне үткәрүне дәвам итү;

Татарстан Республикасы халыкларының этнокультурасы буенча материал туплау;

ике телле балалар өчен татар телендә театр иҗаты түгәрәге оештыру, аның дәвамлы, комплекслы, системалы эшчәнлеген тәэмин итү.

**Әдәбият**

*Бабынина Т.Ф.* В мире национальных культур. Программа приобщения старших дошкольников к национальной культуре народов, населяющих Республику Татарстан. Набережные Челны, 2001.

*Борһанова Р.А.* Татар халкының мәдәнияте белән таныштыру программасы. Казан, 1994.

*Васильева М.А., Гербова В.В., Комарова Т.С.* Программа воспитания и обучения в детском саду. М.: Мозаика – Синтез, 2005.

*Зарипова З.М.* Программа и методические материалы. Поликультурное воспитание детей старшего дошкольного возраста. Набережные Челны, 2006.

*Зарипова З.М.* Үстерешле уеннар. Казан: Беренче полиграфия компаниясе, 2013.

*Зарипова З.М., Исаева Р.С., Кидрячева Р.Г.* Балалар бакчасында рус балаларына татар теле өйрәтү: программа, методик киңәшләр, диагностика. Казан: Беренче полиграфия компаниясе, 2013.

ФГОС, Игровое обучение детей 5–7 лет. Методические рекомендации / под ред. Н.В. Ивановой. М.: ТЦ Сфера, 2008. 112 с.,

*Крашенинникова Е.* Развитие познавательных способностей дошкольников, ФГОС. М.: Мозаика – Синтез, 2014.

*Шаехова Р.К.* Региональная программа дошкольного образования. Төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программасы. РИЦ, 2012.

***Багирова Эльвира Гарифулла кызы,***
*Казан шәһәренең 376 номерлы балалар бакчасында*
*татар теле өйрәтү буенча тәрбияче*

УДК 579.64

***Л.Ф. Миңнуллина, М.Т. Лотфуллин***

# РИЗОСФЕРА БАКТЕРИЯЛӘРЕНЕҢ ҮСЕМЛЕКЛӘР ҮСЕШЕНӘ ТӘЭСИРЕ

Работа посвящена выделению из ризосферы картофеля и характеристике бактерий с ростостимулирующей активностью. Выделенные изоляты бактерий были идентифицированы на основе гомологии гена 16S рРНК как новые штаммы *Brevibacterium iodinum* MG-1 и *Pseudomonas putida* MG-2. Показано, что бактерии способны к триптофан-зависимому синтезу индолил-уксусной кислоты (ИУК). Максимальное накопление ИУК у *B. iodinum* MG-1 и *P. putida* MG-2 составило 28,65 мкг/мл и 11,5 мкг/мл соответственно на 72 час роста при добавлении 500 мкг/мл L-триптофана. Обработка семян гороха и ржи суспензией клеток *B.iodinum* MG-1 и *P.putida* MG-2 приводила к стимулированию роста проростков и корешков на 24–28% и 14–24% соответственно. Полученные данные свидетельствуют о том, что выделенные штаммы бактерий имеет потенциал использования в качестве биопрепаратов в сельском хозяйстве.

**Ключевые слова:** ризосфера, биопрепараты, почвенные бактерии, развитие растений, индолил-уксусная кислота.

Химик ашламаларны даими һәм күп вакытта контрольсыз куллану кеше сәламәтлегенә генә түгел, әйләнә-тирәгә дә начар тәэсир итә, ә бу исә авыл хуҗалыгы культураларының уңдырышлылыгын арттыруда яңа, биологик яктан зарарсыз ысуллар булдыру ихтыяҗын тудыра. Мондый ысулларның берсе – үсемлекләр үсешен яхшыртырга сәләтле ризосфера (тамыр яны зонасы) бактерияләреннән ясалган биопрепаратлар булдыру. Үсемлекләр үсешен арттыруның төп механизмы булып әлеге бактерияләрнең фитогормоннар (ауксиннар, цитокиннар һәм гиберилиннар), витаминнар һәм башка төрле биологик актив матдәләр бүлеп чыгаруы тора [Bais *et al*., 2006]. Моннан тыш, ризобактерияләр һавадагы азотны бәйләү, туфрактагы фосфорны үзләштерелә торган хәлгә күчерү, су һәм минераль матдәләр транспортын яхшырту аша да үсемлекләр үсешенә йогынты ясый ала. Бактерицид һәм фунгицид кушылмалар синтезлап, ризосфера бактерияләре үсемлекләрне төрле фитопатогеннардан саклый, һәм шуның белән уңыш югалтуны бермә-бер киметә. Димәк, үсемлекләр үсешен яхшыртырга сәләтле ризобактерияләрне куллану химик ашламаларга биологик альтернатива була ала [Lutfullin *et al*., 2016].

Фитогормоннарның үсемлек организмындагы күпчелек процессларны контрольдә тотуы яхшы билгеле. Әлеге матдәләрнең күпчелеге үсемлекләрнең үзләрендә синтезланса да, күпмедер өлеше (ризобактерияләр

бүлеп чыгарганы) туфрактан керә. Фитогормоннар бактерияләргә нигә кирәк, дигән сорауга болай җавап биреп була: алар, беръяктан, бактерияләргә башка микроорганизмнар һәм үсемлекләр белән бәйләнеш урнаштырырга ярдәм итсә, икенче яктан, бактериаль күзәнәкнең үзе өчен дә мөһим роль башкара. Шулай итеп, симбиотик бактерияләрнең фитогормоннар синтезлауга сәләте үсемлекләр үсешен яхшыртуда иң кирәкле сыйфатлары булып тора [Shaharoona *et al.*, 2007].

Индолил-3-сиркә кислотасын (ИСК) синтезлау ризобактерияләр арасында киң таралган күренеш булганга, нәкъ менә бактериаль ауксиннарның үсемлекләр үсеше һәм тукლануына керткән ролен билгеләүгә зур игътибар бирелә [Glick, 2012]. Әлеге матдә үсемлек күзәнәкләре бүленеше һәм дифференциациясенә йогынты ясый, орлык һәм бүлбеләрнең шытучанлыгын, ян һәм өстәмә тамырлар барлыкка килүен арттыра, вегетатив үсеш процессларын контрольдә тота, яктылык һәм гравитацияне тою, чәчәк ату күренешләре өчен җаваплы реакцияләрдә арадашчы ролен башкара, фотосинтезга һәм стресс шартларына каршы торучанлыкка тәэсир итә. ИСК башкарган функцияләрнең шундый күп төрле булуы әлеге ауксинның биосинтезы, транспорты һәм сигнал юлларының гадәттән тыш катлаулылыгы белән аңлатыла [Santner et al., 2009]. Ризосфера бактерияләре тарафыннан ауксиннар синтезы күпмедер дәрәҗәдә үсемлек тамырларының бүлендек[1] составы, төгәлрәк әйткәндә, әлеге бүлендеккә ауксиннарның төп элгәресе булган L-триптофан аминокислотасы керүе белән билгеләнә [Zaidi et al., 2009]. Шунлыктан, үсемлек үсешенә уңай тәэсирле ризобактерия штаммнарын эзләү һәм өйрәнү авыл хуҗалыгында яңа төр биотехнологияләр үсеше өчен мөһим.

Бәрәңге ризосферасыннан югары дәрәҗәдә ИСК синтезларга сәләтле 2 бактериаль штамм бүлеп алынды. Әлеге изолятлар 16S рРНК генына гомология нигезендә *Brevibacterium iodinum* һәм *Pseudomonas putida* төрләренә караган яңа MG-1 һәм MG-2 штаммнары буларак билгеләнде.

Сальковский реактивы белән үткәрелгән тестта, M9 тирәлегендә үскәндә, *B. iodinum* MG-1 һәм *P. putida* MG-2 бактерияләренең триптофанга бәйле ИСК синтезына сәләтле икәне ачыкланды. Тирәлектә L-триптофан булмаганда, һәр штамм өчен дә ИСК синтезлау дәрәжәсе түбән булды, һәм 1 мл-га 0,7–1,7 мкг-нан артмады (рәс. 1). 300 мкг/мл L-триптофан өстәлгән тирәлектә 24 сәг. үскәннән соң, *B. iodinum* MG-1 бүлеп чыгарган ИСК күләме 9,65 мкг/мл, ә *P. putida* MG-2 бүлеп чыгарганы – 3,45 мкг/мл-га җитте. Тирәлеккә 500 мкг/мл L-триптофан өстәү исә бу күрсәткечләрне 16,35 һәм 8,85 мкг/мл дәрәҗәсенә җиткерде. Бактерияләрне шул ук шартларда (ягъ-

---

[1] Тамыр бүлендеге – корневые выделения.

ни 300 һәм 500 мкг/мл L-триптофан өстәлгән М9 тирәлегендә) үстерүне дәвам иткәндә, ИСК-ның тирәлектәге концентрациясе артты, һәм *B. iodinum* MG-1 өчен – 27,3 һәм 28,65 мкг/мл (1 нче А рәс.), ә *P. putida* MG-2 өчен 9,7 һәм 11,5 мкг/мл тәшкил итте (1 нче Б рәс.). Әлеге күренеш L-триптофанның ИСК синтезын индукцияләве турында сөйли.

Бактерияләрнең үсемлек үсешен арттыру сәләтен билгеләү өчен стерильләштерелгән борчак һәм арыш орлыклары кулланылды. Шыттырыр алдыннан, орлыклар 1 сәг. $10^5$ һәм $10^7$ КББ[1]/мл концентрациясендәге *B.iodinum* MG-1 һәм *P. putida* MG-2 суспензиясендә тотылды. 7 тәүлектән соң тамыр һәм шытымнарның коры биомассасы үлчәнде.




1 нче рәсем. А. *B. iodinum* MG-1 һәм Б) *P. putida* MG-2 бактерияләре үскән тирәлектә индолил-серкә кислотасының тупланышы. К – контроль (М9 тирәлегендә ИСК күләме)

*1 нче табица.*

*B.iodinum* MG-1 һәм *P. putida* MG-2 бактерияләре тәэсирендә борчак белән арыш үсемлекләренең тамыр һәм шытым биомассалары артымы

| Орлыклар | | Биомасса артымы, % ларда | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | *B. iodinum* MG-1, КББ/мл | | *P. putida* MG-2, КББ/мл | |
| | | $10^5$ | $10^7$ | $10^5$ | $10^7$ |
| Арыш | Шытым | 23,8±2,4 | 28,4±2,8 | 26,7±2,5 | 25,4±2,2 |
| | Тамыр | 22,8±2,3 | 14,9±1,8 | 5,3±0,8 | 7,01±0,9 |
| Борчак | Шытым | 26,4±2,6 | 10,6±1,2 | 28,9±3,1 | 24,0±2,3 |
| | Тамыр | 24,6±2,5 | 20,0±1,9 | 9,3±1,0 | 14,3±1,3 |

[1] КББ – колония барлыкка китерүче берәмлекләр (*рус*. КОЕ – колониеобразующие единицы)..

Таблицадан күренгәнчә, орлыкларны бактерияләр белән эшкәртү шытым һәм тамырларның биомасса артымына уңай йогынты ясый. Шулай да бу эффект шытымнарның биомассасында ачыграк күренә. Әйтик, *B. iodinum* MG-1 һәм *P. putida* MG-2 тәэсирендә шытымнарның коры биомассасы артымы 10–28% һәм 24–28% ка җитсә, тамырчыклар өчен бу күрсәткеч 14–24% һәм 5–14% кына тәшкил итте. Шулай ук биомасса артымына тирәлектәге бактерияләр санының тәэсире дә билгеләнмәде: һәр ике концентрация өчен дә охшаш эффект күзәтелде.

Бактерияләрнең үсемлекләрнең башка өлешләренә тәэсирен өйрәнү өчен, «Дубравная» сорты томатының стерильләштерелгән орлыклары 3 көнлек *B. iodinum* MG-1 һәм *P. putida* MG-2 культуралары белән эшкәртелде. 25 тәүлектән соң үсемлекләрнең сабак озынлыгы һәм тамыр системасының үсеш дәрәҗәсе анализланды (2 нче рәс.).

Әлеге нәтиҗәләр *B. iodinum* MG-1 бактерияләренең томат сабак һәм тамырлары үсешенә, *P. putida* MG-2 бактерияләренә караганда, күбрәк йогынты ясавы турында сөйли.

Шулай итеп, бәрәңге ризосферасыннан бүленгән *B. iodinum* MG-1 һәм *P. putida* MG-2 бактерияләренең үсемлекләр үсешенә уңай йогынты ясарга сәләтле икәне ачыкланды. Әлеге штаммнар, химик ашламаларга алмаш буларак, экологик яктан куркынычсыз биопрепаратлар ясауда кулланыла ала.




2 нче рәсем. 25 көнлек томат үсемлекләренең сабак һәм тамырлары үсешенә *B. iodinum* MG-1 һәм *P. putida* MG-2 штаммнарының тәэсире. Контроль – бактерияләр белән эшкәртелмәгән үсемлекләр

**Әдәбият**

*Bais H.P., Weir T.L., Perry L.G., Gilroy S., Vivanco J.M.* The role of root exudates in rhizosphere interactions with plants and other organisms // Annu. Rev. Plant Biol. 2006. V. 57. P. 233–266.

*Glick B.R.* Plant growth-promoting bacteria: mechanismsand applications // Hindawi Publishing Corporation, Scientifica. 2012.

*Lutfullin M.T., Hadieva G.F., Sharipova M.R., Mardanova A.M.* Characterization of growth-promoting activity of *Pseudomonas putida* strain MG-2 // RJPBCS. 2016. V. 7. No. 5. P. 1538–1542.

*Santner A., Calderon-Villalobos L.I.A., Estelle M.* Plant hormones are versatile chemical regulators of plant growth // Nature Chem. Biol. 2009. V. 5. P. 301–307.

*Shaharoona B., Jamro G.M., Zahir Z.A., Arshad M., Memon K.S.* Effectiveness of various *Pseudomonas* spp. and *Burkholderia caryophylli* containing ACC-deaminase for improving growth and yield of wheat (*Triticum aestivum* L.) // J. Microbiol. Biotechnol. 2007b. V. 17. P. 1300–1307.

*Zaidi A., Khan M.S., Ahemad M., Oves M.* Plant growth promotion by phosphate solubilizing bacteria // Acta Microbiol. Immunol. Hung. 2009. V. 56. P. 263–284.

*Тикшеренү эше Казан (Идел буе) федераль университетының дөньякүләм әйдәп баручы фәнни-белем бирү үзәкләре арасында көндәшлек сәләтен арттыруга юнәлтелгән Дәүләт программасы кысаларында тормышка ашырылды.*

*Мәкалә «2014–2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Дәүләт программасының 3.5.4. номерлы чарасын тормышка ашыру кысаларында нәшер ителә*

***Миңнуллина Ләйлә Фәрваз кызы**,*
*Казан федераль университеты аспиранты,*
*Фундаменталь медицина һәм биология институтының*
*кече гыйльми хезмәткәре*

***Лотфуллин Марат Тәфкил улы**,*
*Казан федераль университеты магистранты,*
*Фундаменталь медицина һәм биология институты*
*инженеры*

УДК 579.61

*Л.Ф. Миңнуллина, Э.Р. Шәйдуллина, А.М. Мәрданова*

# ОППОРТУНИСТИК ИНФЕКЦИЯЛӘР СӘБӘПЧЕСЕ *MORGANELLA MORGANII*: АНТИМИКРОБ МАТДӘЛӘРГӘ ЧЫДАМЛЫЛЫГЫ ҺӘМ БИОЭЛПӘЛӘР ХАСИЛ ИТҮЕ

В данной работе проведен анализ встречаемости бактерий *Morganella morganii* в биологических материалах амбулаторных больных г. Казани в 2013 г. Показано, что *M. morganii* занимает четвертое место по частоте встречаемости среди наиболее частых возбудителей внебольничных инфекций из семейства *Enterobacteriaceae*. 93% изолятов *M. morganii* были устойчивы к ампициллину, 91% – к азитромицину, а 77% и 74% устойчивы к цефазолину и доксициклину. Помимо этого, установлена способность двух полирезистентных штаммов *M. morganii* к формированию биопленок в различных условиях и толерантности к действию пероксида водорода, что также может обусловливать их устойчивость к антимикробным препаратам.

**Ключевые слова:** внебольничные инфекции, *Morganella morganii*, резистентность к антибиотикам, чувствительность к пероксиду водорода, биопленкообразование.

*Enterobacteriaceae* семьялыгына караган бактерияләр иммун системасы зәгыйфьләнгән кешеләрдә төрле оппортунистик инфекцияләр кузгатырга сәләтле. Мондый инфекцияләргә шартлы патоген микроорганизмнар китереп чыгарган авыруларны кертәләр. Соңгы вакытта *Morganella morganii* бактерияләре, амбулатор инфекцияләр сәбәпчесе буларак, ешрак искә алына башлады [Dutta, Narang, 2004]. Әлеге бактерияләр бәвел чыгару юлы, тире һәм йомшак тукымалар инфекцияләре, сепсис, менингит һәм баш мие абсцессы кебек авырулар китереп чыгарырга мөмкин [Atalay *et al.*, 2010; Kim et al., 2007; Tsai *et al.*, 2013; Vijaya *et al.*, 2014]. *M. morganii* изолятларының күпчелеге киң спектрдагы антибиотикларга, бигрәк тә β-лактамнарга чыдам, бу исә авыруларны тагы да катлауландыра [Jones *et al.*, 2004].

Күпчелек энтеробактерияләр кислородның актив формаларын (КАФ) зарарсызландыра торган каталаза, пероксидаза һәм супероксиддисмутаза кебек ферментлар синтезларга сәләтле [Fridovich, 1995, 1997]. Организмга эләккән инфекцион агентларны нейтральләштерү максатыннан, макрофаг һәм нейтрофилларның КАФ, аерым алганда $H_2O_2$ кушылмасын бүлеп чыгарулары күптәннән билгеле [Klebanoff *et al.*, 1966; Yoshpe-Purer, Henis, 1976]. Водород пероксиды, антимикроб матдә буларак, сәламәтлек саклау һәм санитария өлкәсендә дә актив кулланыла. Шуңа күрә, авыру кузгатучы

микроорганизмнарның КАФларны зарарсызландыра торган ферментлар синтезлавы медицина өчен шактый проблема тудырырга мөмкин. Моннан тыш, авыру тудыручы бактерияләрнең еш кына төрле микроорганизмнардан торган биоэлпәләр[1] составында очравын да искәртеп үтәргә кирәк [Atalay *et al.,* 2010]. Биоэлпәләр микроорганизмнар яшәешенең киң таралган формасы булып тора, әлеге структуралар формалашу 60% хроник инфекцияләрнең сәбәпчесе икәне дә билгеле [Голуб, 2012]. Моның сәбәбе шунда: биоэлпәләр составындагы күпчелек бактерияләргә антибиотикларның стандарт концентрациясе тәэсир итми [Keren *et. al.,* 2004].

Шулай итеп, әлеге тикшеренүнең максаты, берьяктан, 2013 елда Казан шәһәрендә бүленгән амбулатор *M. morganii* штаммнарына статистик анализ үткәрү булса, икенче яктан, сайлап алынган ике штаммның водород пероксидына каршы торучанлыгын һәм биоэлпәләр хасил итүгә сәләтен билгеләү булды.

2013 елда Казан шәһәренең «Биомед» дәвалау-диагностика үзәге 13153 биоматериал үрнәгенә микробиологик анализ үткәрә. Ясалган статистик анализ нәтиҗәләренә караганда, бу үрнәкләрдән 79819 бактериаль изолят бүлеп алына, шуларның 4824 ен грам-тискәре бактерияләр тәшкил итә. *Enterobacteriaceae* семьялыгы вәкилләренә бу категориянең 98% ы туры килә (1 нче рәс.).




1 нче рәсем. *Enterobacteriaceae* семьялыгы вәкилләренең амбулатор биоматериалларда очрау ешлыгы (Казан, 2013)

Төрле биоматериаллардан 57 *M. morganii* изоляты бүленде, шулай итеп, очрау ешлыгы буенча бу бактерияләр энтеробактерияләр арасында 4 нче урынны алды. *M. morganii* бүленү очракларының 42,8% ын монокультура тәшкил итсә (ягъни *M. morganii* үзе генә), 57,2% ы катнаш культурага туры килде. Мондый культуралар, күпчелек очракта, тизәк үрнәкләрендә очрады. Гадәттә, *M. morganii* белән берлектә, *Klebsiella pneumonia*, гемолитик *Escherichia coli* һәм *Staphylococcus aureus* бүленгәнлеге ачыкланды.

*M. morganii* штаммнарының төрле антибиотикларга каршы торучанлык спектры билгеләнде (1 нче табл.).

[1] Биоэлпә (рус. биопленка) – нинди дә булса өслеккә берегеп үскән һәм үзен тулы бер система кебек тотучы микрооганизмнар бергәлеге. Бергәлектәге күзәнәкләр химик матдәләр ярдәмендә даими коммуникациядә торалар.

*1 нче таблица.*

Амбулатор пациентлардан бүлеп алынган *M. morganii* изолятларының антибиотикларга сизгерлеге

| № | Антибиотиклар | Чыдам штамм-нар, % | Сизгер штамм-нар, % |
|---|---|---|---|
| 1. | Ампициллин | 93 | 7 |
| 2. | Амикацин | 0 | 100 |
| 3. | Цефтазидим | 9 | 91 |
| 4. | Цефатоксим | 12 | 88 |
| 5. | Цефазолин | 77 | 23 |
| 6. | Азитромицин | 91 | 9 |
| 7. | Ципрофлоксацин | 4 | 96 |
| 8. | Гентамицин | 9 | 91 |
| 9. | Доксициклин | 74 | 26 |

Таблицадан күренгәнчә, штаммнарның 93% ы ампициллинга, 91% ы – азитромицинга, 77% ы – цефазолинга, 74% ы доксициклинга чыдам булып чыкты. Изолятларның барысы да амикацинга, күпчелеге цефтазидим, цефатаксим, гентамицин, нитроксолин һәм ципрофлоксацин кебек антибиотикларга сизгер иде. Алдагы тикшеренүләр өчен бәвел үрнәкләреннән бүленгән *M. morganii* 1 һәм 4 штаммнары сайлап алынды.

*M. morganii* 1 һәм *M. morganii* 4 штаммнарының төрле концентрациядәге водород пероксидына чыдамлылыгы тикшерелде. Моның өчен бактерияләр 0,5, 1, 2, 5, 10, 15 һәм 20 мМ концентрациядәге $H_2O_2$ өстәлгән LB тирәлегендә үстерелде. Штаммнарның $H_2O_2$ гә чыдамлылыгы лаг-фазаның дәвамлылыгы һәм 6 сәг. эчендә үсеш тизлеген торгыза алу сәләте буенча билгеләнде. Алынган нәтиҗәләргә караганда, *M. morganii* штаммнарының һәркайсы 1 мМ водород пероксидына чыдам булып чыкты, ә 2 мМ $H_2O_2$ тәэсире астында үсеш тизлеген ике сәгатьтән соң гына торгыза алды. *M. morganii* 1 штаммы бик нык яшәүчән булуы белән характерланды: хәтта 20 мМ $H_2O_2$ дә аның үсешен тулысынча туктата алмады (2 нче рәс. А). Шул ук вакытта, *M. morganii* 4 штаммының үсеше водород пероксидының тирәлектәге концентрациясе 5 мМ тәшкил иткәндә үк тулысынча тоткарлана иде (2 нче рәс. Б). Шулай итеп *M. morganii* 1, *M. morganii* 4 штаммына караганда, КАФ тәэсиренә тотрыклырак булып чыкты.




2 нче рәсем. *M. morganii* 1 (А) һәм *M. morganii* 4 (Б) бактерияләренең 0,5, 1, 2, 5, 10, 15 һәм 20 мМ $H_2O_2$ өстәлгән тирәлектә үсеше. Контроль – $H_2O_2$ өстәлмәгән LB тирәлегендә үсеш темплары

Патоген һәм шартлы-патоген микроорганизмнарның кеше организмында сакланып калуы, аларны антибиотиклар һәм иммун системасы тәэсиреннән саклаучы биоэлпәләр хасил булу белән бәйле [Ильина с соавт., 2004]. *M. morganii* 1 һәм *M. morganii* 4 штаммнарының төрле тирәлек һәм температура тәэсирендә биоэлпәләр барлыкка китерә алу сәләте тикшерелде. Биоэлпәләр хасил итү нәтиҗәлелеге генцианвиолет буявын бәйләү дәрәҗәсе буенча билгеләнде (3 нче рәс.).



3 нче рәсем. *M. morganii* 4 бактерияләренең 28 °С (сулда) һәм 37 °С (уңда) температура шартларында 48 сәг. үсү дәверендә хасил иткән биоэлпәләрен генцианвиолет ярдәмендә ачыклау

4 нче А рәсеменнән күренгәнчә, *M. morganii* 1 бактерияләре кулланылган тирәлекләренең һәркайсында да биоэлпәләр хасил итәргә сәләтле. Шулай да, 28 °С та LB тирәлегендә үстергәндә әлеге структураларның барлыкка килү нәтиҗәлелеге, 37 °С ка караганда, 40% ка югарырак булды. Miller модификациясендәге LB тирәлегендә (алга таба «Miller тирәлеге») исә биоэлпәләр ике температурада да яхшырак барлыкка килә (28°С та – 10% ка, 37°С та – 40% ка). 4 нче Б рәсеменә карасак, *M. morganii* 4 штаммының *M. morganii* 1 штаммына караганда биоэлпәләрне күпкә эффективрак хасил итүен күрербез. Әлеге штамм биоэлпәләрне шулай ук Miller тирәлегендә активрак барлыкка китерә.

Шулай итеп, *M. morganii* штаммнарының икесе дә, 28°С та Miller тирәлегендә үскәндә, биоэлпәләрне яхшырак хасил итүе ачык күренә. Miller тирәлегенең LB тирәлегеннән бары тик




4 нче рәсем. *M. morganii* 1 (А) һәм *M. morganii* 4 (Б) штаммнарының LB һәм Miller тирәлекләрендә биоэлпәләр хасил итүе

натрий хлориды күләме белән аерылып торуын истә тотсак[1], тозларның югары концентрациясе *M. morganii* бактерияләре тарафыннан биоэлпәләр хасил итүне стимуллаштыра, дигән фикергә килергә мөмкин. Бәлкем бу күренеш бактерияләргә сидек юлларындагы тозлар һәм сидекчәнең[2] югары концентрацияләренә җайлашырга мөмкинлек бирәдер. *M. morganii* 4 штаммының һәр ике тирәлектә дә биоэлпәләрне яхшырак хасил итүе һәм киң спектрдагы антибиотикларга чыдамлылык күрсәтүе (мәгълүмат китерелмәгән), әлеге штаммның вирулентлык үзлекләре югарырак булуына дәлил булып тора.

Шулай итеп, 2013 елда Казан шәһәрендә амбулатор инфекцияләр сәбәпчесе булган энтеробактерияләр арасында *M. morganii* бактерияләре 4 нче урынны алды. Бүленгән изолятларның төрле антимикроб матдәләргә чыдамлылыгын тикшерү, *M. morganii* штаммнарының 74–93% ы ампициллин, азитромицин, цефазолин һәм доксициклин кебек антибиотикларга резистент икәнен ачыкларга ярдәм итте. Моннан тыш, лаборатор тәҗрибәләр *M. morganii* штаммнарының биоэлпәләр хасил итүгә сәләтле һәм водород пероксидына чыдамлылык буенча аерылып торуларын күрсәтте.

**Әдәбият**

*Голуб А.В.* Бактериальные биопленки – новая цель терапии? // Клин. микробиол. антимикроб. химиотер. 2012. Т. 14. № 1. С. 23–29.

*Ильина Т.С., Романова Ю.М., Гинцбург А.Л.* Биопленки как способ существования бактерий в окружающей среде и организме хозяина: феномен, генетический контроль и системы регуляции их развития // Генетика. 2004. Т. 40. С. 1445–1456.

*Atalay H., Güney I., Solak Y., Almaz E.* First case of CAPD-related peritonitis caused by *Morganella morganii* // Petit Dial Int. 2010. V. 30 (1). P. 119–121.

*Dutta S., Narang A.* Early onset neonatal sepsis due to *Morganella morganii* // Indian Pediatr. 2004. V. 41 (11). P. 1155–1157.

*Fridovich I.* Superoxide anion radical and superoxide dismutases // An. Rev. Biochem. – 1995. V. 64. P. 97–112.

*Fridovich I.* Superoxide anion radical (O2), superoxide dismutases, and related matters // JBC Online. 1997. V. 272 (30). P. 18515–18517.

*Jones M.E., Draghi D.C., Thornsberry C., Karlowsky J.A., Sahm D.F., Wenzel R.P.* Emerging resistance among bacterial pathogens in the intensive care unit – a European and North American surveillance study // Clinical Microbiology and Antimicrobials. 2004. V. 3. P. 14.

*Keren I., Shah D., Spoering A., Kaldalu N., Lewis K.* Specialized persister cell and the mechanism of multidrug tolerance in *Escherichia coli* // Bacteriol. 2004. V. 186. P. 8172–8180.

*Kim J.H., Cho C.R., Um T.H., Rhu J.Y., Kim E.S., Jeong J.W., Lee H.R.* *Morganella morganii* sepsis with massive hemolysis // J. Korean Med. Sci. 2007. V. 22. P. 1082–1084.

---

[1] Miller тирәлегендә NaCl күләме ике тапкырга күбрәк.

[2] Сидекчә – мочевина.

*Klebanoff S.J., Clem W.H., Luebke R.J.* The peroxidase-thiocyanate-hydrogen peroxidase antimicrobial system // Biochim. Biophys. Acta. 1966. V. 117. P. 63–72.

*Merritt J.H., Kadouri D.E., O'Toole G.A.* Growing and analyzing static biofilms // Режим доступа: http://www.ncbi.nlm.nih.gov/pmc/articles/PMC4568995/pdf/nihms315401.pdf.

*Yoshpe-Purer Y., Henis Y.* Factors affecting catalase level and sensitivity to hydrogen peroxide in *Escherichia coli* // Applied and Environmental Microb. 1976. V. 32. P. 465–469.

*Vijaya D., Sathish J.V., Yashaswini M.K., Sulaiman S. Morganella morganii* causing abscess over the anterior chest wall // Clin. Diagn. Res. 2014. V. 8, No. 9. P. 103.

*Тикшеренү эше Казан (Идел буе) федераль университетының дөньякүләм әйдәп баручы фәнни-белем бирү үзәкләре арасында көндәшлек сәләтен арттыруга юнәлтелгән Дәүләт программасы кысаларында тормышка ашырылды.*

*Мәкалә «2014–2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Дәүләт программасының 3.5.4. номерлы чарасын тормышка ашыру кысаларында нәшер ителә*

***Миңнуллина Ләйлә Фәрваз кызы***,
*Казан федераль университеты аспиранты,*
*Фундаменталь медицина һәм биология институтының*
*кече гыйльми хезмәткәре*

***Шәйдуллина Эльвира Расил кызы***,
*Казан федераль университеты магистранты,*
*Фундаменталь медицина һәм биология институтының*
*кече гыйльми хезмәткәре*

***Мәрданова Айслу Миркасыйм кызы***,
*биология фәннәре кандидаты, Казан федераль университетының*
*Фундаменталь медицина һәм биология институты доценты*

УДК 821.512.145

***Р.Ф. Харрасова***

# ФӘНГӘ БАГЫШЛАНГАН ГОМЕР

*(Галимҗан Нигъмәтинең тууына 120 ел)*

В статье рассмотрены основные вехи жизни и творчества профессора Галимджана Амирджановича Нигмати (1897–1941), литературоведа, литературного критика, внесшего большой вклад в развитие комплексного изучения татарского художественного творчества.

**Ключевые слова:** Галимджан Нигмати, татарское литературоведение, татарская литературная критика, комплексное изучение художественного творчества.

Узган гасырның иң шомлы елларында үз халкына мәгърифәт-фән өлкәсендә хезмәт күрсәткән, бай гыйльми мирас калдырган, егерменче-утызынчы еллар әдәбият белемен, тәнкыйтен аның исеменнән башка күзаллап та булмаган шәхесләрнең берсе, һичшиксез – Галимҗан Нигъмәти. Галимнең гыйльми-теоретик карашлары, әдәби хәрәкәттәге теге яки бу күренешләргә мөнәсәбәте милли сүз сәнгатебезнең узган чорлардагы барышын аңлауда мөһимлеген югалтмаган күләмле хезмәтләрендә, әдәбият белеменең теоретик нигезләрен ачкан китапларында, аерым каләм ияләренә һәм әдәбиятка җитди тәэсир ясаган язмаларында саклана.

* * *

Галимҗан Әмирҗан улы Нигъмәтуллин 1897 елның 26 июлендә Башкортстан туфрагында – Чишмә (Благовар) районы Үдрәкбаш (Өйдерәкбаш) авылында дөньяга килә. Россия авылларын әледән-әле көчәеп алган ачлык интектергән, кешеләрнең, нигезләрен ташлап, күпләп шәһәргә күченгән гасыр азагы бу. Үтә ярлы крестьян Әмирҗан аганың гаиләсе дә 1899 елда Уфага китеп бара. Һәм монда ата кеше, икътисади авырлык чылбырын өзү өчен, бар көчен улын укытуга куя, 1911 елда Галимҗанны дини белем янәшәсендә гимназия курсы буенча дөньяви предметлар да кергән «Галия» мәдрәсәсенә илтә. Ул анда 1917 елгача белем ала. Бүгенге көн галимнәре, әлеге уку йорты заманына күрә милли институт дәрәҗәсендә булган, дигән карашта тора. Монда Казан, Мәскәү, Багдад, Каһирә кебек шәһәрләрнең һәм Төркиянең югары уку йортларын, Казан татар укытучылар мәктәбен тәмамлаган зур белгечләр белем биргән. Г. Ибраһимов – әдәбият, Ә. Вәлиди – фәлсәфә, Г. Терегулов – психология, З. Кадыйри – гарәп, төрек телләре, Ф. Сәйфи-Казанлы – тарих, Г. Шинаси – педагогика, методика кебек фәннәрне укыткан. Г. Нигъмәти соңгы сыйныфларда үзе дә мөгаллимлек итә башлаган.

Г. Нигъмәтинең Октябрь инкыйлабына кадәрге төп хезмә-

те – балаларга белем бирү булса, аннан соң ул аны иҗтимагый эшчәнлек белән бәйли: шәкертләрне мәдәни агарту эшләре белән шөгыльләнә, «Парлак» кулъязма әдәби журналына мөхәррирлек итә. Г. Нигъмәтинең чын мәгънәсендәге журналистлык юлы исә 1918 ел азагында башлана. Иң башта ул Көнчыгыш фронт газетасы «Кызыл яу»га әдәби хезмәткәр булып урнаша. 1919 елның язында, Колчак гаскәрләренең көчле һөҗүменә каршы тора алмыйча, Кызыл Армия Уфадан чигенгәндә, Г. Нигъмәти Бәләбәйгә күченә һәм шулай ук редакциягә эшкә керә. Ул бераздан Коммунистлар партиясенә кабул ителә. 1919 елның ахырында, Бишенче Армиянең Революцион хәрби шурасы карары белән, газета хезмәткәрләре партия Үзәк Комитетының Себер бюросы карамагына күчерелә. Шуның нәтиҗәсендә, Г. Нигъмәти Омскида (бераздан – Новосибирскида) чыккан «Азат Себер» газетасының башта җаваплы сәркатибе, аннан мөхәррире вазифаларын башкара, партиянең губерна комитетында инструктор булып та эшли.

1921 елда Г. Нигъмәти Себердән Мәскәүгә күченә һәм Көнчыгыш коммунистик институттагы берьеллык курсларда укый, татар курсантларына әдәбият дәресләре дә бирә. Курсларны тәмамлаганнан соң, булачак галим Дәүләт журналистика институтына укырга керә, ләкин тиздән укуын ташлый, чөнки аны 1923 елда Үзәк башкарма комитет аппаратына милли матбугат инструкторы итеп билгелиләр. Г. Нигъмәти Мәскәү чорында журналистика, әдәби тәнкыйть, бигрәк тә иҗтимагый фәннәр өлкәсендә ныклап танула башлый. Ул, киң катлам халыкка адреслап, марксизм-ленинизм тәгълиматы, социализм нигезләре турында гыйльми хезмәтләр, мәдәният, әдәбият, матбугат проблемаларын чагылдырган мәкаләләр, китаплар яза.

1926 елның ахырында Г. Нигъмәтине партия Үзәк Комитеты «Кызыл Татарстан» (хәзерге «Ватаным Татарстан») газетасының баш мөхәррире сыйфатында Казанга җибәрә. Ул 1928–1929 елларда – Татарстан дәүләт китап нәшриятының баш мөхәррире вазифасында, аннан соң ике ел «Яңалиф» журналының җаваплы мөхәррире булып эшли, шуның янәшәсендә, берара Марксизм-ленинизм институтында әдәбият секциясенә җитәкчелек итә. Галим 1929–1933 елларда – Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы доценты, 1935–1937 елларда – шул ук кафедраның мөдире, ә 1934 елдан – инде профессоры да. Г. Нигъмәти утызынчы еллар башына күренекле тәнкыйтьче буларак танула. Ике унъеллык чигендә ул 4 күләмле китап, Дәрдемәнд, М. Гафури, Г. Коләхмәтов, Ш. Бабич, Г. Ибраһимов, К. Нәҗми, Һ. Такташ һәм башкаларның зур иҗатларына кагылышлы иллегә якын мәкалә бастыра, татарлар арасында рус классикасын пропагандалау белән шөгыльләнә. Г. Нигъмәтинең утызынчы еллар язмаларында иҗат методлары, әдәби-мәдәни барыш мәсьәләләре, әдәбият

гыйльменең үсеш юнәлешләре, әдәбиятның сыйфатлылыгы кебек үз заманы өчен үтә дә актуаль проблемалар күтәрелә.

Г. Нигъмәти әдәбият белеме өлкәсенә күпсанлы галимнәр әзерләп калдыра. Ул М. Гайнуллин, Х. Ярми, Г. Халит, Җ. Вәзиева, Я. Агишев, Г. Кашшаф һәм башка танылган шәхесләрнең остазы иде. Кызганыч ки, галимнең педагоглык һәм фәнни эшчәнлеге иртә өзелә: Г. Нигъмәти шәхес культы елларының репрессияләренә элэгә. Аны 1937 елның 16 сентябрендә, троцкийчы контрреволюцион оешма әгъзасы дип гаепләп, кулга алалар, һәм 1940 елның 17 гыйнварында, 5 елга хөкем итеп, Устьвымлаг лагерена җибәрәләр. Сәламәтлеге какшаган Г. Нигъмәти 1941 елның 4 декабрендә вафат була.

* * *

Татар тәнкыйте инкыйлабтан соң Яңа заман сүз сәнгате нинди булырга тиешлек соравына җавап эзли. Сәнгатькә кагылышлы элекке карашлар кризис кичергән бу чорда теләсә кайсы тәнкыйтьче рухи кыйммәтләрне яңадан бәяләргә омтыла, үткәндәге күзаллаулары искердеме, әллә яшәргә хаклымы, зур һәм кече әдәби берәмлекләрне нинди яңа алым-чаралар яисә чит фәнни өлкәләрдәге табышлар ярдәмендә анализларга мөмкин дип уйлана. Моны егерменче-утызынчы елларда актив язган теләсә кайсы тәнкыйтьче мирасы ярдәмендә дәлилләргә мөмкиндер. Әйтик, Г. Нигъмәтинең 1931 елда дөнья күргән «Әдәбият һәм тормыш» хезмәтендә шундый бүлекләр бар: «Әдәбият фәнендә формалистлык-буржуа карашы», «Әдәбият фәнендә психологик карашлар». Ул шулай ук бу елларда «Иске әдәби мирастан файдаланырга кирәкме?» (1928), «Әдәби тәнкыйтьтә механистик һәм эклектик бозуларга каршы» (1931) һ.б. мәкаләләр дә иҗат итә, алар аша фәндә һәм әдәбиятта барган күренешләргә мөнәсәбәтен белдерә.

Әдәбиятның инкыйлабтан соңгы яңарышы, анда яңа агымнар, мәктәпләр барлыкка килү сәнгатьнең иҗтимагый-социаль тормыш белән ни дәрәҗәдә тыгыз бәйләнгәнлеген ачык күрсәтеп тора башлый, шул сәбәпле әдәбият белгечләре дә иҗтимагый мәсьәләләрне читләп уза алмый. Инкыйлабны көтеп алган яшь галим иң башта, үзенең остазы Г. Ибраһимов кебек үк, вакытлы матбугатта актив рәвештә татар тормышына, аның төрле институтларына, бигрәк тә мәдәният-сәнгатькә, шул исәптән әдәбиятка Октябрь алып килгән күренешләрне, марксизм-ленинизм тәгълиматын ачарга, уңай яктан бәяләргә һәм пропагандаларга керешә. Г. Нигъмәтинең егерменче еллар башында басылган «Карл Маркс безгә нәрсәләр калдырды?» (1922), «Ленин һәм пролетариат революциясе» (1924), «Адәмнәр ничек яратылган?» (1924) мәкаләләре, «Коммунизм турында» (1924) китабы киң катлам халыкка сәяси һәм фәнни мәгълүмат җиткерүне максат итә, ә инде унъеллык ахырындагы «Февраль ничек хәзерләнде» (1928), «Партиянең уникенче съезды һәм милләт-

ләр мәсьәләсе» (1928) язмалары егерменче гасыр башында иҗтимагый-сәяси барыштагы хәлләрне чагылдыручы хезмәтләр булып тора.

Г. Нигъмәти мәкаләләренең идея-тематик юнәлеше башкарган вазифалары белән дә билгеләнә дип уйларга кирәк. Әйтик, партиянең төп газеталарыннан булган «Кызыл Татарстан»га баш мөхәррир итеп билгеләнү үзе үк аның алдына көнүзәк мәсьәләләрне яктырту һәм инде бигрәк тә партия күзлегеннән бәя бирү таләбен куя. Галимнең егерменче еллардагы әдәби барышка мөнәсәбәтле «Октябрь һәм әдәбият» (1922), «Әдәбият мәйданында» (1925) исемле хезмәтләре дә – илкүләм иҗтимагый-сәяси үзгәрешләрнең сүз сәнгатенә йогынтысын уңай бәяләү рухында. Ул аларда инкыйлабтан соңгы татар әдәбиятына күзәтү ясый, иҗат методы мәсьәләләренә туктала, реализм белән романтизм янәшәсендә, заманга бәйле популярлашып киткән символизм, футуризм, имажинизм кебек төшенчәләрне һәм күренешләрне дә аңлатып уза.

Г. Нигъмәти хезмәтләренең атамалары аның инкыйлаби барышта тоткан тарафын – «кызыл» пропагандистлыгын сөйли. Алай гына да түгел, «Сәнгать һәм әдәбият турында Маркс һәм Энгельс» дигән хезмәтендә Г. Нигъмәти партиячел тенденциялелекне ачыктан-ачык яклап чыга. Бу чорда тәнкыйтьче, бер яктан, әдәбиятны «дәүләтиләштерү», партия күзәтчелеге астына кертү өчен көрәшүчеләргә, бигрәк тә Г. Ибраһимовка, икенче яктан, әдәбиятка кагылышлы язмалар да калдырган атаклы рус марксизм-ленинизм теоретикларына таяна. Г. Нигъмәти хезмәтләрендә В. Ленин, Г. Плеханов, А. Луначарский, Л. Троцкий һәм башка большевик тәнкыйтьчеләрнең, идеологларның партиягә җаны-тәне белән хезмәт иткән М. Горький кебек әдипләрнеке белән кисешкән нокталарны табу авыр түгел. Л. Троцкийның Г. Нигъмәтинекенә аваздаш исемдәге «Литература и революция» китабы 1923 елда дөнья күрсә дә, аның инде шул рухтагы мәкаләләре 1907–1923 еллар аралыгында язылган була. Әлеге хезмәт русларның гына түгел, татарларның да инкыйлабтан соңгы әдәбият турындагы карашлары һәм тәнкыйть терминологиясе формалашуга зур йогынты ясый. Г. Нигъмәти чор әйләнешкә керткән һәм алга таба актив кулланылырга тиешле дип фаразланган иҗтимагый-сәяси терминнарны халыкка аңлату максатыннан басылган «Сәяси лөгать» (1925) сүзлеген төзүдә катнаша. Димәк, эш барышында ул турыдан-туры Л. Троцкий һәм башка марксистларның язмаларына, Г. Ибраһимов кебек, татар тәнкыйтендә яңа терминнарны активлаштырган каләм ияләренең иҗтимагый-сәяси эчтәлектәге хезмәтләренә мөрәҗәгать иткән дип уйларга кирәк.

Г. Сәгъди 1927 елда ук инде «Безнең юл» журналында: «Диалектик материализм, марксизм нигезендә ныклыгы белән үзен тиз вакыт эчендә танытып өлгерүче Г. Нигъмәти булды», – дип яза (№ 10, б. 41). Г. Ибраһимов та аны «әдәбиятны-сәнгатьне

марксизм-ленинизм буенча тикшерүче, тәнкыйть кыйлучы»лар арасында атый [Ибраһимов, б. 504]. Дөрес, галим төрле партия эшлеклеләренең хезмәтләренә таянса да, заманга ияреп, тенденциозлыкка бирешсә дә, тапталган юллардан гына атлаучы, фәнгә һәм әдәбиятка сәяси корал дип кенә караучы түгел. Чын мәгънәсендә академик фән кешесе саналган Г. Нигъмәти каләменә – филологик тирәнлек, ә үзенә эстетик күзаллауларны калыплаштыру омтылышы хас. Ул әдәбиятка бервакытта да социологик планда гына якын килмәде, әдәби әсәрләр эчтәлеген бары тик коммунистларга файдалы сәяси яссылыктан гына бәяләмәде, чөнки Г. Нигъмәти сәнгатиэстетик сыйфатламаларны тәмам читкә кую тарафдары түгел иде. Моның шулай икәнлеген галимнең: «Революциягә килгән һәм аның эчендә пешеп чыккан әдипшагыйрьләребезнең бурычлары исә, чын революция рухы белән сугарылган, художество ягыннан эшләнгән, эшче-крестьянның киң катлавы аңларлык рәвештә простой булган, простойлыгы белән матур булган сәнгать әсәрләре бирүләреннән гыйбарәт булырга тиеш» [Нигъмәти, 1929, б. 28], – дип язып чыгуы да күрсәтә. Без бүген, узган чорларга әйләнеп карап, галимнәр арасыннан әдәбиятны өйрәнүдә вульгар социологизм агымына бөтенләй бирешмәүчеләрне таба алмабыз, чөнки социалистик җәмгыять төзү идеясенә илкүләм бирелү, шуңа хезмәт итмәгән әсәрләр дөнья күрергә тиеш түгел дип ышану, ә хезмәт иткәннәрен пропагандаларга омтылыш үзеннән-үзе сүз сәнгатен сыйнфый позицияләрдән торып бәяләүгә китерә. Димәк, Г. Нигъмәтинең дә, әдәби барышны өйрәнгәндә, марксист каләм ияләре язганнарга табынуы табигый.

Г. Нигъмәти тәнкыйть белән ныклап егерменче еллар ахырында шөгыльләнә башлый: әдәби барышка күзәтүләр ясый, рецензияләр, юбилей материаллары яза, теге яки бу каләм иясенең әсәрләрен гыйльми проблема яссылыкларында тикшерә. Утызынчы елларга кергәч, галим татар классиклары иҗатын өйрәнүне тагын да көчәйтә, иҗат портретлары тудыру белән шөгыльләнә, әдәбият гыйльменең үсеш юллары, совет чоры сүз сәнгатендә килеп туган күренешләр турында ныклабрак уйлана.

Г. Нигъмәти, 1927 елда «Ун ел эчендә безнең әдәбиятыбыз» дигән мәкалә язып, татар әдәбиятының инкыйлабтан соңгы барышын ачып сала. Соңрак әлеге мәкалә форматы бераз үзгәргән рәвештә «Революция елларындагы әдәбиятыбыз» (1929) җыентыгында дөнья күрә. Анда сүз милли әдәбиятыбызның инкыйлабкача хәле, әдипләребезнең илкүләм сәяси-иҗтимагый үзгәрешләргә мөнәсәбәте, әлеге үзгәрешләрнең алар каләменә һәм рухиятенә тәэсире турында бара. Галим М. Гафури, Г. Камал, Ш. Камал, Г. Ибраһимов кебек өлкән буын әдипләрнең генә яңа шартларда «әдәбиятта кайбер тарихи эз калдырырлык нәрсәләр» бирүе турында сөйли.

Гражданнар сугышы һәм сугыштан соңгы еллар әдәбиятын-

дагы күзәтүләрендә Г. Нигъмәти өлкән буынга алмаш әзерләү проблемасын куя, яшь әдипләрнең фронт шартларында үсеп чыгулары, ә инде тыныч тормышта, яңа бурычлар алып, чын язучы сыйфатында калыплашулары, зур хыяллар, оптимизм, көрәш дәрте белән рухланып, яңа эчтәлектәге әсәрләр иҗат итүгә алынулары хакында яза. Тәнкыйтьче Ш. Усманов, К. Нәҗми, Н. Баян, Г. Толымбай, А. Шамов, С. Баттал, С. Кудаш, Г. Гомәр, А. Таһиров һәм башкаларның иҗатын уңай яктан билгеләп үтә. Бу чорда да, алга таба да әдәби барышка ясаган күзәтүләрендә һәм аерым шәхесләрнең иҗатларына бәяләмәләрендә Г. Нигъмәти аларның идеологик позициясен ачыклауны һәм каләм сәнгатилеген үзәккә куя. Тәнкыйтендә чорның әйдәп баручы әдибе булган Г. Ибраһимов прозасын һәм М. Горький иҗатын яктырту зур урын алып тору галимнең фәнни эзләнүләрендә әдәбияттагы уңай күренешләрне калкуландыру, алга таба яшәргә, көчәергә тиешлекләрен раслау максаты белән эш йөрткәнлеген күрсәтә. Әйтик, Г. Нигъмәти «Галимҗан Ибраһимовның әдәби хезмәтенең егерме елы» (1928) мәкаләсендә каләм иясенең иҗат эволюциясен күздән кичерә һәм эшчәнлегенең татар әдәбияты өчен кыйммәтен маһир язылган революцион эчтәлекле әсәрләр белән баетуында таба.

Г. Нигъмәти «Г.Ибраһимов әсәрләрендә революция мотивлары» (1928), «Бу томда Галимҗан Ибраһимов безгәниләр биргән?» (1929), «Галимҗан Ибраһимовның яңа әсәре» (1929), «Г. Ибраһимов һәм аның иҗат юлы турында» (1932) һәм башка хезмәтләрендә тәнкыйтьче Г. Ибраһимов хезмәтләрен яңа заман идеологиясенә җавап бирү, иҗат методлары, стиль үзенчәлекләре яссылыкларында бәяли. «Бу томда Галимҗан Ибраһимов безгә ниләр биргән?» язмасында галим әдипнең 1909–1913 елларда дөнья күргән «Казакъ кызы», «Татар хатыны ниләр күрми» әсәрләре һәм берничә эрелеваклы хикәясе турында сүз алып бара. Ул роман белән повестька инкыйлабтан соң кайбер үзгәрешләр кертелгәнлек, аларның, беренче чиратта, әдәби материал белән композициягә каравы турында әйтә, чагыштырма-типологик анализ кулланып, «коммунист әдип каләме» барлыкка китергән башка аерымлыкларны да таба. Г. Нигъмәти «Татар хатыны ниләр күрми»нең тәүге вариантын чор вазгыятенә мөнәсәбәттә ача, әсәр язылганда «татар әдәбиятында өстенлек кылган стиль, агым романтизм мотивлары, романтизм фикер тойгылары белән сугарылган иде», болар Г.Ибраһимов иҗатында да чагылды, дип белдерә һәм әлеге «тойгыларның характерлы күрсәтелеше»нә мисал рәвешендә «Диңгездә» хикәясен китерә.

Нинди генә иҗатны анализласа да, Г. Нигъмәти даими рәвештә укучыны әдәбиятка кагылышлы теоретик белемнәр белән коралландыра, һәм галимнең тәнкыйть язмалары аның теге яки бу терминга нинди эчтәлек салуын, әдәби барыштагы теге яки бу күренешләргә

мөнәсәбәтен дә ачык күрсәтеп тора. Г. Нигъмәти бу хезмәтендә, Г. Плеханов фикерләренә таянып, узган чорларда мәдәни сыйныфларның үзләреннән артта калучы төркемнәргә йогынты ясарга мөмкинлеген әйтә. Ул элеккеге әдәбиятта дворяннар тудырган романтизмны реакцион тармак дип билгели, «яңа сыйныф»ларныкын бераз революцион мотивларны да үз эченә алган романтизм дип атый, һәм Г. Ибраһимовның язу стилен шуларның икенчесенә кертә: «Г. Ибраһимовның әсәрләрендәге романтизм, реакциячел сыйныф романтизмы түгел, бәлки бөек борылыш еллары дулкыны эченә кереп тә, монда ныклап көрәш алып бару батырлыгына ирешә алмаган, шулай да бер як читтә битараф кала да алмаган иҗтимагый төркемнәр карашын күрсәтә торган романтизмнан гыйбарәт». «Г. Ибраһимовның бу әсәрләре үткәнгә – феодализм заманнарына кайтмыйлар, ул момент әдип иҗатында төп сыйфат түгел, ләкин боларда тормыш гармониясен авылдан, табигатьтән /.../ эзләү омтылышы ярылып ята. Боларда билгесез формадагы тормышка омтылыш, шуның турында сагыш бар, шуның белән бергә, һәрбер әсәрдә диярлек кызыл җеп булып сузылган “сукыр тәкъдир” көченә ышанучанлык, шуңа рәнҗүчәнлек бар» [Нигъмәти, 1958, б. 58–59, 62], – дип тә белдерә.

Г. Нигъмәтинең «Бу томда Галимҗан Ибраһимов безгә ниләр биргән?» мәкаләсендә язучы прозасында чагылыш тапкан әдәби дөньяның төп үзенчәлекләренә игътибар бирелә, аның төрле тип каһарманнардан, әлеге геройларның эш-хәрәкәтләреннән, табигать сурәтләреннән, тормыш-көнкүреш картиналарыннан, гореф-гадәтләреннән, рухи дөньяларыннан, ягъни этнографик тасвирлардан да торганлыгы күрсәтелә. Галим аларны тудыру алымнары, әйтик, психологик янәшәлекләр, символлар куллану, төрле стилистик элементлар турында сүз алып бара.

Г. Нигъмәти «Г.Ибраһимов һәм аның әдәби иҗат юлы» мәкаләсен әдипнең инкыйлабкача иҗатын бәяләүдән башлый һәм шул чор әсәрләрендә аның нинди иҗтимагый катламнар тормышына игътибар иткәнлеген күрсәтә. Ул Г. Ибраһимов инкыйлабкача «Иҗтимагый һәм шәхси мотивлар аралашып йөрү белән берлектә, аның иҗтимагый мотивлары шушы революция һәм реакция дәверләренең буржуа һәм бигрәк тә вак буржуа укымышлылары хәрәкәтенә каратылганнар», «романтизм буявына» сугарылганнар иде, дигән гомумиләштерүләр ясый, «әдипнең бу дәвер әсәрләре арасында иң зур урынны» «Яшь йөрәкләр» белән «Безнең көннәр» алганны күрсәтеп бирә [Нигъмәти, 1958, б. 73–75]. Галим анализында төп игътибар «шәхес сурәтләре»нә һәм әсәрләрнең композиция белән стилистикасына юнәлтелә.

Г. Нигъмәти ике унъеллык чигендә бастырган кайбер язмаларында әдипнең язу калыбын сыйнфый көрәш тарихы белән бик тыгыз бәйли. Аның «“Безнең көннәр” һәм аның стилендә бишенче еллар сыйнфый

көрәшенең чагылышы» (1932) мәкаләсендә: «"Безнең көннәр" революцион партия һәм аның көрәшчеләре бурычларын ничек итеп аңлата, революциянең төп этәрүче көчләре дип кемнәрне ала, гомумән анда 1905 ел революциясе кайсы ягы белән һәм ничек чагылдырыла, менә бу сорауларга ничек җавап бирелүгә карап, әсәрнең сыйнфый йөзе, әдипнең нинди әдәби идеология үткәргәнлеге билгеләнәләр» [Нигъмәти, 1958, б. 97], – дигән юллар бар. Галим алга таба шул сорауларга җавап эзли, таба һәм түбәндәге гомуми нәтиҗәгә килә: «Әсәр буржуаз демократик революция сызыгында тора» [Нигъмәти, 1958, б. 119]. «Кызыл чәчәкләр»дә (1928) исә ул шул исемдәге әсәрне революциянең «төпке катлауларга» тәэсирен күрсәткән уңышлы хезмәт рәвешендә атый.

Г. Нигъмәти, әдәбиятта тоткан урынына карамыйча, теләсә кайсы язучы каләменә хас җитешсезлекләрне күрсәтеп бирергә тырыша. Г.Ибраһимов иҗатына бәйле рәвештә дә, ул теге яки бу кимчелекләрне атап килә. «Галимҗан Ибраһимовның яңа әсәре» (1928) мәкаләсендә тәнкыйтьче «Тирән тамырлар»га хас түбәндәге җитешсезлекләрне билгели: «Кайбер каһарманнар турында үтә нечкәләп җентекләү әсәрне суза, төп фикерне таркауландыра төшә. Әсәр барышы өчен кирәксез яки башкача итеп үзгәртелүе артык булган урыннар да юк түгел». Дөрес, шуның артыннан ук галим: «Ләкин бу җитешсезлекләр әсәрнең яңалыгы, көчлелеге алдында артка чигенеп калалар», – дип белдерә [Нигъмәти, 1958, б. 144–145].

Г. Нигъмәти тәнкыйтендә һәрбер каләм иясенең язганнары иҗтимагый һәм әдәби шартлар җирлегендә яктыртыла. «Гафур Коләхмәтов һәм аның иҗаты» мәкаләсендә сүз «бишенче ел дулкыннарында кайнап, татар социал-демократ большевиклары – "уралчылар" арасында яшәгән әдип» [Нигъмәти, 1958, б. 7] һәм аның төрле «сыйныф һәм иҗтимагый төркемнәрнең иҗтимагый хәрәкәтләре әйләнәсе эчендә» үскән иҗаты турында барса, «Шәриф Камал – драматург»та төп игътибарны нинди чор, нинди катлау, социаль төркемнәр тормышын кайсы материал һәм ысуллар ярдәмендә яктыртуга юнәлтелә. «Акчарлаклар»га мөнәсәбәттә, Г. Нигъмәти болай дип белдерә: «Бу комедия үзенең тематик юнәлеше, сурәтләренең бирелеше буенча, шуңа кадәр булган татар буржуа драматургиясе әсәрләреннән нигезендә аерылмый» [Нигъмәти, 1958, б. 149].

Г. Нигъмәти «Кави Нәҗми һәм хикәяләре» (1929) хезмәтендә әдип иҗатының тематик киңлекләрен, сурәтләү алымнарын, аларны куллану юлларын ача, ул тудырган сурәтләрнең төрлелеге, хәрәкәтчәнлеге, абстракттан конкретка күчеше, тасвирлар кыйммәтендә дәрәҗәлек, доминанталык хакында сүз йөртә. Хезмәттә эстетик категорияләр, тойгылар, аларның нәрсәгә хезмәт итүе хакында да фикер бар. Г. Нигъмәтигә, кайсы әдип турында гына язса да, оптимизмы дәрәҗәсен билгеләү бик мөһим. К. Нәҗминең эчке рухиятен ул, прозасы

белән бәйлелектә ачып: «Көрәш, революция тормышын язуда ул күбесенчә оптимист булса да, тыныч тормыш дәверен язуга күчкәндә инде ул, ничектер, бераз пессимизмга төшә. Белмим, ул элекке коммунизм дәверләрен сагына, белмим инде, болай сагынмаса да, яңа тыныч тормыш заманында яңа тормыш (быт) төзелешенең уңышлы чыгуына ышанмый. Ни булса булсын, аның соңгы әсәрләрендә пессимистлык күбрәк сизелә» [Нигъмәти, 1958, б. 197], – ди. Галимнең башка каләм ияләренә бәяләрендә дә аларның эчке сынуларын яки рухи күтәренлеклекләрен, чор атмосферасын чагылдырган урыннар шактый. К. Нәҗминең, Г. Нигъмәти билгеләгәнчә, инкыйлабтан соң бераз вакыт узуга, өметсез язуы, тормышның караңгы якларына күбрәк игътибар бирүе, уңай типлар бирә алмавы, агитацияләренең кайчак шәрә тудырылуы, текст тукымасына отышлы үтеп керә алмавы әдип күңелендә барган катлаулы кичерешләр хакында да сөйли, дип уйларга кирәк.

Г. Нигъмәти әдәби әсәрләрдә буржуа тормышын тәнкыйть итү, аңа меңнәрне ымсындырган һәм барлык милләтләр өчен уртак Яңаны каршы кую проблемасын бервакытта да читләп узмаска тырыша. Ул «Татар совет театр һәм драматургиясенең үсеше» хезмәтендә болай дип яза: «Әсәрләре соңгы унбиш ел эчендә татар театры репертуарыннан төшми килгән К. Тинчурин революциягә хәтле үк татар буржуа, мещан тормышын тәнкыйть итеп чыккан иде. Ләкин ул вакытта әле аның әсәрләре милләтчелек карашлары белән сугарылып язылган иделәр. Октябрьдән соң ул каләмен пролетариат революциясенә хезмәт иттерүгә бора һәм 1927 елда татар буржуазиясенең контрреволюцион асылын ачып биргән сатирик комедиясе “Җилкәнсез”не бирә. Шуннан соң “Ил”, “Зәңгәр шәл” музыкалы пьесаларында беркадәр милли демократчылык карашларын чагылдырып чыккан бу язучы 1932 елда Татарстан колхозлары тормышыннан алынган “Кандыр буе”н, социалистик төзелеш гигантларының эшкә җибәрелеш чорларында күрелгән авырулар һәм аларның ничек бетерелүен күрсәткән һәм бездә завод-фабрикаларда ничек итеп яңа кешеләр җитештерелүен сурәтләндергән “Тургай” пьесасын /.../ яза» [Нигъмәти, 2011, б. 325]. Г. Нигъмәти, беррәттән, «хроникаль пьесаларга хас җитешсезлекләр»не – характерларның тулы эшләнмәвен, эпизодиклыкны, кайбер шәхесләрне бирүдә схематизм кебек күренешләрне дә атап уза.

Г. Нигъмәти тәнкыйтендә үзәктә торган проблемаларның берсе – яңа әдәбиятта уңай герой мәсьәләсе. Әлбәттә, уңай герой дигәндә, галим зур хыяллар белән янган, дошман элементлардан һәр яктан караганда да өстенрәк торган социалистик төзелешләр кешесен күз алдында тота. Аның күренекле иҗатлардан заманчалык рухын, чор кешесен, тормышчан тасвирларны эзләве Г. Толымбай прозасына бәяләмәләрендә бик ачык күренә. Г. Нигъмәти әдипнең 1920 елларның икенче яртысында ба-

сылган әсәрләрендә гади авыл кешеләре һәм аларның көндәлек тормышы тасвирлануга игътибар итә һәм болай дип яза: «Толымбай, /.../ әдәбият әсәре үзенең мөндәриҗәсен тормыштан алырга тиешлеген күз алдында тотып, үзе яза торган тормыш күренешләрен һәрвакыт өйрәнә килде» [Нигъмәти, 1929, б. 40].

Г. Нигъмәтинең узган гасырның егерменче-утызынчы елларында Тукай фәнен үстерүгә керткән өлеше биниһая зур: ул шагыйрь иҗатын гыйльми яктыртуны яңа көч белән җанландыра, Тукайның фәнни биографиясен төзү, аны яңа фактлар белән баету юнәлешендә эшли; иҗатын комплекслы анализлау, пропагандалау кебек гамәлләр башкара. Әле әдәбият мәйданына узып кына барган чорында ук Г. Нигъмәти Г. Тукай иҗатының социаль җирлеген ачкан «Габдулла Тукаев» (1923) мәкаләсен язган була. Алга таба галимнең «Шагыйрь Габдулла Тукай үлүгә 15 ел тулды» (1928) хезмәтендә Тукай поэзиясенә хас тема-мотивлар шулай ук авторның шәхси тормышы, социаль хәле белән бәйләнештә карала. Г. Нигъмәтинең гыйльми тирәлектәге абруе сәбәпле дә, Тукай мирасының идея-эстетик бәһасе башка галимнәр тарафыннан озак еллар дәвамында социологик принциптан чыгып бәяләнүен дәвам итә. Г. Нигъмәтинең шагыйрь иҗатын әдәби багланышлар кысасында анализлавы Тукай гыйльмиятендәге шул юнәлешне көчәйтеп җибәрүгә һәм хәтта бүгенгә кадәр китереп җиткерүгә хезмәт итә. Г. Нигъмәти Тукайның әдәби үсеш этапларын күзаллатырлык фикерләр әйтә, шигъри иҗеге турында дәлилле сүз алып бара, шагыйрь кулланган тезмә сүз системаларын, ритм, рифма, строфика һәм композиция үзенчәлекләрен дөрес тотып ала. Димәк, Тукай иҗатының идея эчтәлеген форма белән тыгыз бәйләнештә ача, шигырьләренең сурәтлелек дәрәҗәсенә зур игътибар бирә.

Г. Нигъмәти халык авыз иҗатының Тукайга тәэсирен, шагыйрьнең тәрҗемәчелек һәм публицистик осталыгын ача. Галим Тукай каләменең көчле ягы сатирада икәнлекне, аның тормышның кайсы якларына юнәлдерелгәнлеген оста тотып ала. Шунысы мөһим: Г. Нигъмәти һәрвакыт Тукай мирасын комплекслы өйрәнү кирәклеген аңлап эш йөртә. «Шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлы» (1936) мәкаләсендә, мәсәлән, галим Тукай поэзиясен фольклор, башка халыклар әдәбияты тәэсире планында да, шәхси үзенчәлекләрен ачыклау юнәлешендә дә анализлый. Әлеге хезмәттә ул Тукай сатирасының заманчалыгын, оперативлыгын, тәнкыйть объектының тәгаенлеген һәм ысул-чараларын билгели, «Печән базары яхуд Яңа Кисекбаш» (1908) поэмасын исә югары дәрәҗәдәге сатира үрнәге буларак характерлый, лирикасына хас үзенчәлекләрне барлый, һәм, гомумән алганда, иҗатын үсеш-үзгәрештә күрсәтә. Социологик мәктәп вәкиле булган Г. Нигъмәти фәнни язмаларында башта Тукайны вак буржуа шагыйре дигән карашны уздыра, чөнки узган әдәбиятка, тулаем алганда да, шул ракурстан карый. Заман

өчен актуальлеген аңлаган галим шагыйрь иҗатының, беренче чиратта, иҗтимагый-социаль ягын яктыртуга игътибар бирә, шунлыктан да сатирасын ныграк калкуландыра, ә инде интим лирикасына дикъкать итми диярлек. Г. Нигъмәти Тукайның милли-дини хисләрен, бигрәк тә Толстойдан килгән карашларын, дөньяны аңлауда чикләнгәнлеге дип карап, кире кага. Тора-бара ул Тукай мирасын бәяләүдәге ялгышлардан әкренләп читкә китә.

Һ.Такташ, Х.Туфан кебек яшь һәм талантлы язучылар иҗатын анализлаганда, Г. Нигъмәти шулай ук әсәрләренең актуальлеге һәм форма камиллеге мәсьәләләренә игътибар итә. Ул, Һ.Такташка бәйле рәвештә, болай дип белдерә: «...аның тормыштагы актуаль мәсьәләләргә җавап бирергә тырышып караулары да булмады түгел. Мәсәлән, аның “Мәхәббәт тәүбәсе” шундый әсәрләрдән булып, художество ягыннан да нык игътибарга алынырга тиешле әсәр» [Нигъмәти, 1927, б. 30]. Г. Нигъмәти «Һади Такташ» (1932) язмасын шагыйрь иҗатының борылышларын тасвирлаудан башлый: «Такташның Октябрь елларында революциягә юлаучылыктан пролетариат әдәбиятына союздашлыкка таба үсеше аның символист-идеалистлыктан Советлар илендәге бүгенге социализм төзелешенең кызу темпта югарыга барган күренешләрен шигъри сурәтләрдә күрсәтү һәм тәгъбир итүгә килеп ялгану рәвешендә барды. 1916 елда ук берничә шигырь язып та, шагыйрьлек эшчәнлеген чыннан тик Октябрьдән соң гына башлаган Такташның үсешендәге югарыда әйтелгәнчә булган борылышны күзәтү вак буржуа катлавыннан чыккан һәм шуның карашыннан килгән бер интеллигентның сәяси-әдәби үзгәрүе нинди катлаулы юллар белән баруын, шагыйрьдә пролетариатка чит карашлар революция тәрбиясе аркасында ничек җимерелеп, ватылып ташлана килүен безгә кызык мисаллар бирә алыр» [Нигъмәти, 1958, б. 164].

Аталган хезмәттә Һ.Такташның иҗат юлы этапларга бүленә, һәр баскычта каләменә хас сыйфатлар, шагыйрь тудырган символик сурәтләрнең җирлеге һәм эчтәлеге, әсәрләренең кайсы сыйныфка хезмәт итүе ачыклана. Чор модасына бирелеп, Г. Нигъмәти ул кулланган методларның, аерым алганда символизмның реакционмы, әллә прогрессив юнәлештәгесеме икәнлеге турында сүз йөртә, пролетариат диктатурасын урнаштыруга, ныгытуга юнәлтелгән сәяси-иҗтимагый көрәшләр чорында «абсолют рәвештәге шәхси азатлык өчен кычкырып чыгу революция өчен» [Нигъмәти, 1958, б. 170] кирәксез иде, дигән карашныуздыра. Г. Нигъмәти тәнкыйтендә чагыштырма-типологик анализга зур урын бирелә, Һ. Такташ поэзиясе С. Рәмиев, Г. Тукай һәм башкалар иҗаты янәшәсенә куеп карала. Галим, Такташ әсәрләренең тормышчанлык дәрәҗәсен, реаль эчтәлеген ачканда, марксизм-ленинизм тәгълиматына, марксистларның, әдәбият – идеологик күренеш, өскорма күренеш, дигән сүзләренә, «вак

буржуаз стихия» турында фикер йөртүләренә таяна. Ул, Такташның 1918–1922 еллардагы әсәрләреннән чыгып: «Чыннан да, Такташ бу шигырьләрендә революция вакытында теге яки бу сыйныфның иҗтимагый, икътисади програмасын төшенү, үзләштерүдән ерак тора әле.

Ул һаман үзен сыйныфтан тыш торучы һәм үзе дә рәтләп төшенмәгән миссияне үтәүче “яшь пигамбәр” итеп күрә. Ләкин аның барып таяныр иҗтимагый катлавы юк» [Нигъмәти, 1958, б. 173], – дип белдерә. Г. Нигъмәти Такташ әсәрләрендә тормышны тәгаенрәк сурәтләү омтылышы 1923 елдан көчәя төшә дип саный, әмма Такташның әле яңа этап башында да инкыйлаб бурычларын ахыргача аңлый алмавын күрсәтә.

«Һади Такташ»та Г. Нигъмәти егерменче еллар ахырында башланган иҗтимагый-сәяси үзгәрешләрне, аның мәдәният һәм әдәбиятта чагылышын шактый төгәл күрсәтә, әмма Яңа өчен кискен көрәшне яклап сүз алып бара, иң кирәкле дип санаган урында тагын коммунистлар тәгълиматына, бу очракта Сталин сүзләренә таяна, ул тәнкыйть иткән «тигезлек» теориясенең өлешчә Такташ иҗатында да чагылуын, аның да еш кына «партиясез» әдәбият карашларын уздыруын сөйли. Шагыйрь иҗатындагы уңай күренешләр рәвешендә аның «революция барлыгына күз сала» башлавын, аның үсеп баруын, яңа көчләр тудыруын күрүен, индивидуалистлыкны коллективка буйсындыру омтылышының көчәюен атый. Мәкалә ахырында Г. Нигъмәти Такташ иҗатының соңгы этабы хакында мондый фикерләр әйтә: «...31 елда инде аның алдында бөтен төзүчелек һәм бәхет китерүчелек көче белән пролетариатның сыйнфый көче килеп баса /.../, сыйныф ничек итеп төзү эшләре алып барганын, сыйныф һәм аның әгъзалары арасында мөнәсәбәт берлекле булганын, аерым аңлы әгъзаларның “шәхси” бәхете сыйныф бәхете булганын, шуңа күрә дә болар арасында каршылык булмаганын күрә башлый» [Нигъмәти, 1958, б. 184–185].

Г. Нигъмәти 1936 елда шагыйрьнең тормышы һәм иҗаты турында «Һ.Такташ» исемле тагын бер мәкалә чыгара. Ул анда яңадан бер кат Һ.Такташ поэзиясенең «вак буржуаз бунтарьлыктан башлап, пролетариат революциясе тудырган чынбарлыкны дөрес төшенергә һәм шуның тормышта аерым чагылышларын күрсәтергә тырышу аша үтеп, социалистик реконструкция эпохасының бай җимешләрен, социализм иленең гөрләп чәчәк атуы һәм анда яңа кешеләр, күп санда геройлар туа баруын күрсәтүгә килеп җитүе» [Нигъмәти, 1958, б. 186] турында яза. Мәкалә шагыйрь әсәрләренең халык арасында үтә популярлыгы сәбәпләрен күрсәтү белән тәмамлана.

Г. Нигъмәти югары бәя биргән шагыйрьләрнең чираттагысы – Хәсән Туфан. Ул аның хакында фәнни эзләнүләрне 1927 елда «Нәни разбойниклык, хатынсыз ай һәм бераз гына мужик фәлсәфәсе турында» дигән мәкалә язу белән башлый. Алга таба тәнкыйтьче шагыйрь иҗатын теге

яки бу күләмдә «Туфан шигырьләрендә производство мотивлары» (1928), «Туфан шигырьләре» («Революция елларындагы әдәбиятыбыз». М., 1929), «Матур әдәбият фронтында ун ел» («Ун ел эчендә татар матур әдәбияты». Казан, 1930), «Татар совет әдәбиятында социалистик реализм мәсьәләләре» (1933), «Социалистик реконструкция чорында татар совет матур әдәбияты» (1934) дигән тәнкыйть хезмәтләрендә чагылдыра.

Г. Нигъмәти «Туфан шигырьләре» (1929) язмасында каләм иясен: «башлап «производство» мотивларын көйләп чыккан шагыйрь» [Нигъмәти, 1958, б. 202],– дип атый, хезмәт темасына нисбәтле Туфан тудырган сурәтләрнең «җансыз завод көчен күрсәткән, механика көчен генә әйтергә теләгән сурәтләр түгел»леген, Х. Туфанның һәм эчтәлек, һәм форма ноктасыннан камиллеккә омтылуын әйтә. Г. Нигъмәти татар әдәбиятында эшчеләр тормышын чагылдырган әсәрләр авторларының производство темасын белмәүләрен күрсәтә. Аның фикеренчә, шул тормыштан чыкканнар аны сәнгати югарылыкта тасвирлый алмый, бары тик әдәби әзерлекле язучылар үстерү генә әлеге проблеманы уңышлы хәл итәчәк. Ул Х. Туфанны эшчеләр тормышын яхшы белүче, производство мотивларына сәнгати югарылыктагы әсәрләр иҗат итүгә дә сәләтле дип саный. Г. Нигъмәти Туфанның эзләнүчәнлек сыйфатын, яңа сурәт һәм ифадәләр табарга тырышуын, әсәрләренең тел-сурәтләү ноктасыннан байлыгын мактый, шәхси рухи кичерешләрне бирүгә караганда, күпчелекнең уй-хисләрен тасвирлауга өстенлек бирүен, иҗатында «сөйләү һәм декламация тибындагы лирика» [Нигъмәти, 1958, б. 214] зур урын тотуын күрсәтә.

* * *

Г. Нигъмәти XX гасырның егерменче-утызынчы елларында татар совет әдәбиятының методологик нигезләрен эшләүгә зур өлеш керткән, сүз сәнгатенә заман алып килгән үзгәрешләргә игътибарлы галимнәрнең берсе иде. Аның тәнкыйтендә, теге яки бу иҗатның идеялелеге, кайсы сыйныфка хезмәт итүе, заманчалыгы, тормышчанлыгы, типлары һәм уңай геройлары кебек проблемаларны чишү янәшәсендә, язучылар кулланган әдәби алым-чараларны, әсәрләренең сәнгатилек дәрәҗәсен, каләм көчен ачыклау да читтә калмады. Г. Нигъмәти талант иясенең дөнья сүз сәнгатендәге уңай традицияләрдә калыплашкан камил шәхси стилгә ия булуын, ә язганнарының социалистик төзелешләргә хезмәт итүен яклады. Аның егерменче-утызынчы еллардагы тәнкыйте, бер яктан, әдәби әсәрләрне бәяләүдә норматив система булдыруга хезмәт итсә, икенче яктан, талантның индивидуаль чагылышка иялеген дә раслады.

**Әдәбият**

*Ибраһимов Г.* Әсәрләр: сигез томда. Т. 5: Әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933). Казан: Татар. кит. нәшр., 1978.

*Нигъмәти Г.* Революция елларындагы әдәбиятыбыз. М.: СССР халыкларының үзәк нәшр., 1929.

*Нигъмәти Г.* Сайланма әсәрләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1958.

*Нигъмәти Г.* Татар совет театр һәм драматургиясенең үсеше // Кәрим Тинчурин: тарихи-документаль, әдәби һәм биографик җыентык / төз.: И. Һадиев, Р. Батулла. Казан: Җыен, 2011. Б. 325.

*Нигъмәти Г.* Ун ел эчендә безнең әдәбиятыбыз // Безнең юл. 1927. № 10.

***Харрасова Рифә Фатхрахман кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 821.512.145

***З.Г. Мөхәммәтшин***

# ШӘРКЫЯТЬЧЕ ГАЛИМ ҮРЛӘРЕ

*(С. Гыйләҗетдиневкә –70)*

Салим Гилязутдинов долгие годы работал в Институте языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ сначала в отделе народного творчества, затем в отделе рукописей и текстологии. Статья посвящена 70-летию этого прекрасного знатока восточных языков, специалиста по истории ислама и просто хорошего человека.

**Ключевые слова:** Салим Гилязутдинов, татарское востоковедение, арабские и персидские рукописи в фондах Центра письменного и музыкального наследия ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ.

Татар халкының мәдәни һәм әдәби багланышы Шәрык мәдәнияте һәм ислам фәлсәфәсенә бәйле. Бигрәк тә Болгар дәүләтенең ислам динен кабул итүе белән аның тәэсире нык арта, хәтта милләтнең милли үзаңы, психологиясе, дөньяга фәлсәфи карашлары да Шәрык стилендә формалаша. Рус дәүләтенең милли һәм дини изүе дә, коммунистик һәм бүгенге Россиянең христианлыкка тарткан идеологиясе дә аны җимерә алмый. Монда халыкның ислам фәлсәфәсенә өстенлек бирүенең һәм Шәрык, шул исәптән татар дин галимнәренең тирән белемле булулары, борынгы традицияләрне саклаган хәлдә мөселманлык идеяләрен сеңдерә белү алымнарының да тәэсире булмыйча калмагандыр. 1917 елгы Октябрь түнтәрешенә кадәр татар галимнәре, беренчедән, дин галимнәре буларак танылсалар, икенчедән, Шәрыкка гына хас фәлсәфи фикерләрне пропагандалаучылар гына түгел, шуның нигезендә, татар халкының милли хисләрен саклап калган бөек шәхесләр дә иде. Шуны да искәртеп үтү урынлы булыр, дини тәгълимат, нигездә, гарәп теле аша өйрәнелсә, Шәрыкның бөек әдәби мирасы һәм аралашу теле фарсы теле икәнлеген дә ассызыклап үтү кирәктер. Кызганыч, инде бүген бай тарихлы Шәрык мәдәниятен, аның әдәбиятын бөтен нечкәлекләре белән белүчеләр бик сирәк, бәлки юк дәрәҗәсендә дип әйтү дөресрәктер дә. Шул сирәкләр арасында гарәп, фарсы, инглиз, рус һәм татар телләрен, аларның мәдәниятен, әдәбиятын камил белгән Сәлим Гыйләҗетдинов турында аерым туктапып, аның фәнни эшчәнлеге, Шәрыкны өйрәнүгә керткән хезмәте хакында фикерләремне белдереп китү урынлы булыр кебек.

Сәлим Минһаҗ улы Гыйләҗетдиновның фәнгә килү һәм уңышларга ирешү юлы гаять тә бормалы һәм дә сикәлтәле. Ул 1947 елның 18 августында әле 40–60 нчы елларда да миллилекне саклап кала алган Ка-

зан шәһәренең Иске Бистәсендә эшче гаиләсендә дөньяга килә. XX гасыр башында Иске һәм Яңа Бистәдә Шәрык стилендә формалашкан мәдәни һәм милли мохитнең уңай традицияләре киләчәктә галим буларак танылачак С. Гыйләҗетдиновка да тәэсир итмичә калмагандыр. Әмма аңа үз теләгенә ирешү юлында шактый каршылыклы юллар узарга туры килә әле. Аның тәрҗемәи хәлен күзәткәндә гомер юлы тоташ каршылыклар белән бара сыман. 1965 елда Казанның 80 нче татар мәктәбен тәмамлаганнан соң, башта берничә ай М. Вахитов исемендәге химия комбинатында, соңрак моторлар төзү заводында фрезерчы булып эшли. Телләр үзләштерүгә сәләте ташып торуга карамастан, заманына хас булганча, төгәл фәннәргә өстенлек биреп, Сәлим, ялгышлык белән генә Казан авиация институтының радиотехника факультетына кичке бүлеккә укырга керә һәм үз һөнәре түгеллеген аңлагач, ел ярымнан укуын ташлый. 1967–1970 елларда Тын океан флотында гидроакустик буларак хезмәт итә. Яхшы хезмәт иткәне өчен Казанга ялга кайта. Мәктәптә гарәп теленә, гомумән, Шәрык мәдәниятенә мәхәббәт уяткан Мәхмүт ага Рәхимовның хәлен белергә баргач, аңа үзенең киләчәк язмышын гарәп телен, Коръәнне өйрәнүгә багышлау теләген җиткерә. Остаз гарәп теле буенча СССРда Мәскәү, Ташкент, Ленинградта уку йортлары барлыгын әйтә. Сәлим әфәнде бу очрашудан рухланып, кабат хезмәткә киткәндә гарәп теле дәреслеге, сүзлекләре алып юлга чыга. Вахтадан бушаган араларда гарәп телен өйрәнә, корабльдә җәмәгать эшләренә актив катнаша, коммунистлар фиркасына әгъзалыкка кандидат итеп тәкъдим ителә. Флот хезмәтенә өч елын багышлаган Сәлим Минһаҗ улы, армиядән кайту белән укырга китә дисәк дөреслеккә туры килмәс, ул башта 1972 елга кадәр радиокомпонетлар заводында (халык телендә җиденче завод) радиокөйләүче булып эшли. Шул елда Ленинград университетына барып имтихан тапшырып карый. Сынау бирүдә катнашса да, уңышсызлыкка очрый. Очраклы гына университет каршында эшләгән рабфакта әзерлек курслары барлыгын белә һәм шул курска укырга керергә тели. Әмма завод директоры Сәлимне эштән җибәрергә теләмичә, нинди генә үгет-нәсыйхәтләр бирми. Гарәп теле буенча югары белем алуга омтылыш зур булган яшь егетне мондый гына каршылыклар сындыра алмый әлбәттә, ул, тәвәккәлләп, Ленинградка китә. Рабфакта инглиз теленнән башлангыч белеме дә булмаган Сәлим әфәнде берничә ай эчендә курсташларын да узып, телне камил дәрәҗәдә үзләштереп, 1973 елда университетның Көнчыгыш телләр факультетына студент буларак кабул ителә.

Бу урында аның остазларын да искә алып үтү урынлы булыр мөгаен. Ул аларга бүген дә рәхмәтле һәм һәрвакыт ихтирам белән искә ала. Ихтирамга лаек остазлар кемнәр дисәгез, менә алар: Татарстанның Апас районы Морзалар авылыннан

чыккан галим Габдерахман Таһирҗанов һәм Ольга Борисовна Фролова, Илья Павлович Петрушевсий, Олег Федорович Акимушкин, Александр Николаевич Болдыревлар.

Шул рәвешле, Шәрык дөньясына танылган шәхесләрдән белем алган Сәлим әфәнде 1978 елда, Ленинград университетының «Көнчыгышның чит илләрен, Көнчыгышны өйрәнүче, Иран тарихчысы» дигән белгечлек буенча укуын уңышлы тәмамлап, Казанга кайта. Күпкырлы Шәрык белгечен, Коръәнне яттан белгән Сәлимне Казан колач җәеп каршы алырга ашыкмый. Шәһәр буенча дүрт ай эш эзләп йөргәннән соң, ниһаять, татар гуманитар фәненең үзәге – Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтына эшкә урнаша. Университетта алган белгечлеге буенча эш булмаса да, халык иҗаты бүлегенә кабул ителгән фәнни хезмәткәр фән үрләрендә беренче чыныгуларын ала башлый. Институтның халык иҗаты бүлеге «Татар халык иҗаты»ның 12 томлыгын әзерли башлаган еллар бу. Сәлим Минһаҗ улына катлаулы томнарның берсе «Риваятьләр һәм легендалар» томын төзү бурычы йөкләнә. Үзен тырыш, эшчән һәм тирән белемле, яхшы әзерлекле итеп таныткан Шәрык телләре белгече буларак, аңа борынгы чыганаклар белән бәйле әлеге томны югары кимәлгә җиткерү өчен шактый нык казынырга, дөресрәге яңа фәнни юнәлеш буенча белем эстәргә туры килә. Ул төзеп бастырган «Риваятьләр һәм легендалар» томының күп өлешен төрки һәм татар тарихына бәйле хезмәтләрдән алынган кыйммәтле чыганаклар тәшкил итә дә инде. Аларның кайберләре XXI гасыр башында «Имам» нәшриятында аерым китаплар булып нәшер ителделәр. Һәм соңрак текстлары кабат каралып, төзәтелеп (борынгы һәм хәзерге татар телендә) 2011 елда Татарстан китап нәшриятында «Мирастан биш сәхифә» исемле китап дөнья күрде. Шулар нигезендә, Болгар һәм Казан тарихына карата халык арасында киң таралган легенда һәм риваятьләрне туплап, татар, рус, инглиз һәм фарсы телләрендә «Казан турында легендалар», «Серле Казан» һәм «Легендалар һәм мифологик хикәятләр» исемле китаплар басылып чыкты.

Институтта Сәлим әфәндегә үз белгечлеге буенча фәкать 1991 елда гына эш тәкъдим ителә. Монда институтны гаепләү урынсыз кебек. Совет идеологиясе хакимлек иткән елларда Казанда гарәп-фарсы чыганакларын өйрәнүгә әллә ни игътибар бирелмәде дә кебек, хәтта, аспирантурада Шәрык телләреннән имтихан бирү өчен шактый катлаулы юллар үтәргә кирәк иде. Кыскасы, зур тәҗрибә туплаган галим институтның кулъязмалар һәм текстология бүлегенә эшкә күчерелә һәм аңа мирасханәдә сакланган фарсы телле кулъязмаларның тасвирламасын эшләү бурычы куела. Галим берничә ел дәвамында өч чыгарылыштан торган, гомуми күләме 46 табак тәшкил иткән хезмәттә, XI гасырдан алып – XX гасырга кадәр татар халкына мәгълүм фарсы телендәге рухи язма байлык-

ны тасвирлап милләтнең белем дәрәҗәсен күрсәтүгә ирешә. (*Гилязутдинов С.М.* Описание рукописей на персидском языке из хранилище института Языка, литературы и искусства. Выпуск I, II, III. Казань: Фикер, 2002, 2006, 2008). Сәлим әфәнде тарафыннан эшләнгән бу китаплар татар гуманитар фәнендә фундаменталь хезмәтләр итеп каралырга лаек.

Күпкырлы галим татар укучысына тәрҗемәче буларак та мәгълүм. Институтта эшләү дәверендә һәм аннан соң да гарәп, фарсы, төрек телләреннән күп кенә әсәрләрне тәрҗемә итеп бастырды. Мәсәлән, төрек галиме Гариф Бикнең «Мең дә бер хәдис шәрехе» дигән төрек телендәге китабын, беренчеләрдән булып, татар мәгърифәтчесе Габдерәшит Ибраһимов татар теленә тәрҗемә итеп, үзеннән өстәмә шәрехләр биреп бастыра. Сәлим әфәнде исә, хәдисләрнең шәрехләрен иске татар теленнән, ә хәдисләрне турыдан-туры гарәп теленнән тәрҗемә итә (*Гариф Бик.* Мең дә бер хәдис шәрехе. Казан: Раннур, 2005). Сәлим әфәнде Татарстан Яңа Гасыр телевидениесе җитәкчелегенең үтенече буенча Иран кино сәнгате осталарының «Шәһрияр» дигән 17 серияле фильмының татарчага тәрҗемәсен дә эшли. Әлеге сериалдагы 84 газәл татарча милли аһәндә яңгырашы һәм камиллеге белән тамашачының күңеленә һуш килгәндер мөгаен.

Институт һәр җәй илнең төрле төбәкләренә таралып яшәгән татар халкы арасына фәнни экспедицияләр оештыра. С. Гыйләҗетдинов халык иҗаты, кулъязма һәм текстология бүлекләрендә эшләгәндә дә милләтнең асыл җәүһәрләрен җыюда актив катнашты. Ерак Себер, Башкортстан, Киров, Пермь, Рязань, Төмән, Чиләбе, Екатеринбург, Әстерхан, шулай ук Россиянең башка өлкә, край һәм республикаларына, шул исәптән Татарстанның күпчелек районнарына оештырылган фольклор, археографик экспедицияләр вакытында татар гуманитар фәннәре өчен аеруча кыйммәтле тарихи, мәдәни чыганаклар табып, аларны фәнни яктан эшкәртүче, кайберләрен беренчеләрдән булып фәнни әйләнешкә кертүче дә ул иде. XX гасырның 90 нчы елларында Институтта эшләү дәверендә Татарстан Мәдәният министрлыгы каршында оештырылган Фольклор үзәгендә өлкән фәнни хезмәткәр вазыйфаларын башкарды һәм анда да экспедицияләргә чыгып, тарихыбыз, гореф-гадәтләребез, халык иҗаты, сәнгатебез, этнографиябез, гомумән татар энциклопедиясе өчен кыйммәтле, тарихи яктан әһәмиятле булган эшләр башкарды, шул материаллар нигезендә махсус фәнни фильмотека булдыру эшен дә алып бара.

Галим бары академик фән белән генә шөгыльләнде дисәк хакыйкатькә хилафлык килер төсле. Ул дәүләттә башланган үзгәртеп кору елларыннан ук, аерым алганда, 1986 елдан башлап, тирән белемен укучыларга бүләк итүче талантлы педагог буларак та таныла. С. Гыйләҗетдинов педагогик эшчәнлеген Казан шәһәре мәктәпләрендә гарәп теле укытучысы буларак башлап

җибәрә, соңрак Казан дәүләт педагогия колледжында гарәп теле, Казан дәүләт университетында фарсы теле укыта. Болардан тыш милләтнең дини хисләре кабат уянган елларда Коръән өйрәтү курсларында «Тәҗвид», ягъни Коръәнне дөрес уку фәне буенча дәресләр бирә. Ул һәрбер укучы яисә шәкертнең яраткан остазы була. Алар арасында хәрбиләр, дин әһелләре һәм башка күп төрле һөнәр ияләре бар.

Сәлим әфәнденең ислам дине тарихы, аның фәлсәфәсе буенча киң карашлы галим булуына һәм Коръәнне яттан белүенә аерым тукталып үтү кирәктер. Студент елларында ук Коръән сүзләрен картотекага сала башлаган галим бүген Коръән сүзләре күрсәткечен төзү белән мәшгуль. Инде бу күрсәткеч халыкка тәкъдим итү алдында дип әйтерлек. Шулай ук институтта эшләгән елларында аның тарафыннан институт мирасханәсендә сакланган кулъязма Коръән тасвирламасы төзелеп, 2013 елда «Описание рукописей Корана» исеме белән нәшер ителде. Бу темага кагылганмын икән, азрак лирик чигенеш ясап алу да комачау итмәс мөгаен. Текстология белән шөгыльләнгәндә, XX гасыр башында иҗат иткән әдипләрнең иҗатларында Коръәннән аятьләр, Мөхәммәт пәйгамбәр хәдисләре, яисә башка гыйбарәләр шактый очрый. Бу өлкәне җитәрлек белмәү нәтиҗәсендә без еш кына төртелеп калабыз. Шул вакыт, һәрдаим ярдәменнән ташламаган, белемгә омтылган яшьләргә һәрвакыт хәерхаһлы булган галим аятьнең кайсы сүрәдән булуын һәм тиз генә тәрҗемәсен, аның мәгънәсен, тарихи темага караганрак булса, тарихын да аңлатып бирә. Хәдисләр белән дә шул ук хәл була торган иде. Киң карашлы, эрудицияле Сәлим әфәнде шушы яклары белән дә сокландыра.

Фән дөньясында галимнең гыйльми дәрәҗәсе аның халыкара конференцияләрдә, конгрессларда, халык каршында ни дәрәҗәдә катнашуына карап та бәяләнә. Шуны да ассызыклау кирәк, Сәлим әфәнде халыкара симпозиумнарда, конференцияләрдә, конгрессларда катнашып, үзен чын галим итеп таныта алды. Ул 1994 елда Иранда булып узган фарсы теле, Иран тарихы һәм ислам белгечләренең I Халыкара конгрессында катнашты. Анда ул Иран президенты тарафыннан оештырылган кабул итү мәҗлесендә була. 2000 елда Сәлим әфәндегә Казанда узган «Иран һәм Россия» дигән халыкара фәнни конференциядә, 2001 елда исә Иранда узган «Иран һәм Туран» исемле халыкара фәнни конгресста да чыгыш ясау бәхете татый. Фарсы темасына кергәнмен икән, Сәлим әфәнде бу өлкәдә дә шәкерт тәрбияләгән галим.

С. Гыйләҗетдиновның фәнни казанышлары болар белән генә чикләнми әлбәттә. Аның 2011 елда фарсы-татар әдәби бәйләнешләре буенча «Персидско-татарские литературные связи (X – начало XX вв)» монографик хезмәте дә дөнья күрде. Махсус әзерлекле Шәрык телләре белгече, тәрҗемәче, сәяхәтче, педагог, киңкырлы талант иясе Сәлим әфәнденең институтта һәм инсти-

туттан тыш 40 ел чамасы фәнни эшчәнлеге дәверендә бүген дә, киләчәктә дә әһәмиятен югалтмаячак 22 китабы, күпсанлы фәнни мәкаләләре басылып чыккан.

Мәкаләнең башында ук Сәлим әфәнденең тормыш баскычлары каршылыклар һәм көрәшләрдән торуы искәртелгән иде. Ул инде үзен күптән күпкырлы галим итеп танытса да, фәкать озак еллардан соң (22 ел вакыт үткән) 2000 елда гына, Х. Мәхмүтев җитәкчелегендә «Татар тарихи риваятьләре һәм легендалары» исемле темага кандидатлык диссертациясе яклап, филология фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗәгә ирешә. Докторлык темасы буенча монографиясе басылып чыгуга карамастан, яклауны ашыктырмый. Хәер, кем әйтмешли, чын галим булу өчен доктор булу мәҗбүри дә түгел анысы. Гомерен фәнгә багышлаган Сәлим Минһаҗ улы аңа мохтаҗ да түгел. Ул фән докторларына тиң дәрәҗәдә фәнни-аналитик фикергә ия шәхес. Шәрык мәдәнияте һәм ислам дине тарихы, яисә гарәп-фарсы тәрҗемәләре буенча мөрәҗәгать иткән фән докторларына да галим ярдәм кулын сузарга һәрвакыт әзер.

Озын сүзнең кыскасы, тормыш каршылыкларын җиңәҗиңә ихлас күңелле, олы җанлы, һәркемгә игътибарлы һәм ихтирамлы, авыр хәлләрдә бервакытта ярдәменнән ташламаган галим, педагог, Шәрык телләре белгече, тәрҗемәче, изге вә эчкерсез, саф күңелле Сәлим Минһаҗ улы Гыйләҗетдиновның гомер бәйрәмендә исәнлек-саулык, җан тынычлыгы, фәнни эзләнүләр юлында тагын да зуррак ачышларга һәм дә уңышларга ирешүен теләп калам. Сәлим әфәнденең андый мөмкинчелекләре бар, әле дары мичкәсендә ялкынлы ут сүнмәгән.

***Мөхәммәтшин Зөфәр Гомәр улы,***
*филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

УДК 351.852.13

*О.Л. Улемнова*

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СЫНЛЫ СӘНГАТЬ МУЗЕЕ ТУПЛАНМАСЫНДА ИЛЕБЕЗНЕҢ 1910–1920 ЕЛЛАР АВАНГАРД СӘНГАТЕ

В статье раскрываются этапы формирования и особенности сложившейся в Государственном музее изобразительных искусств Республики Татарстан коллекции отечественного авангардного искусства. Коллекция включает произведения как ведущих российских мастеров авангарда, так и художников Казанской губернии (с 1920 г. – ТАССР). Начало собранию было положено в художественном отделе Центрального музея ТАССР в 1920-е гг., когда сформировалось ядро коллекции русского авангарда и началось формирование коллекции казанских авангардистов. Продолжилось в 1960-е – 1970-е гг. в Музее изобразительных искусств ТАССР (с 1992 – ГМИИ РТ), образованном на базе этого отдела. С этого периода акцент в формировании сместился в сторону казанского искусства 1920-х гг. В результате в ГМИИ РТ сложилась одна из крупных коллекций отечественного авангарда, отражающая особенности развития столичного и регионального авангардного искусства.

**Ключевые слова:** изобразительное искусство, формирование коллекции, русский авангард, региональный аспект, ГМИИ РТ.

Татарстан Республикасы Дәүләт сынлы сәнгать музеендагы (ТР ДССМ) рус авангарды коллекциясе музей тупланмасының горурлыгы санала. Ул рус сәнгате тарихына теркәлгән тасвирый сәнгать, графика һәм скульптура өлкәсендә XX гасырның күренекле рәссамнары В.В. Кандинский, П.П. Кончаловский, А.В. Куприн, А.В. Лентулов, Н.С. Гончарова, М.Ф. Ларионов, Н.К. Рерих, П.В. Кузнецов, Р.Р. Фальк, К.Ф. Богаевский, В.В. Рождественский, И.И. Машков, А.М. Родченко, Д.П. Штеренберг, С.Т. Коненков, Б.Д. Королёв һ.б. хезмәтләреннән гыйбарәт. Музей коллекциясе рус авангарды үсешенең барлык этапларын да (элгәрләре М.А. Врубель һәм В.Э. Борисов-Мусатов иҗатыннан башлап, Европаның һәм рус сәнгатенең символизм, кубизм, футуризм, абстракционизм, примитивизм һәм башка яңа агымнарын) чагылдыра. Алар «Голубая роза», «Бубновый валет», «Ослиный хвост» кебек рус һәм «Синий всадник» халыкара берләшмәләре осталары иҗатында гәүдәләнә.

Академик һәм реалистик сәнгатькә оппозиция рәвешендә формалашкан, үзләренең рус сәнгати программаларын игълан иткән, кайчак үз иҗади юнәлешләреннән баш тарткан, үзенчәлекле алымнары белән публиканы гаҗәпләндергән рус авангардчылары кыска гына вакыт эчендә Европа модернизмы вәкилләре казанышы белән баетылган зур үсеш юлы үтә; дөнья сәнгатенең радикаль формаларына

башлап юл сала. Музей тупланмасында шулай ук авангардчыларның тоталитар режим шартларында, 1930–1940 еллардагы соцреализм хакимлеге чорында (И.И. Машков, П.П. Кончаловский, Р.Р. Фальк һ.б. осталар әсәрләрендә) художество теленең трансформацияләнү күренешләре да чагылыш таба. ТР ДССМндагы рус авангарды коллекциясендә Н.С. Гончарова, В.В. Кандинский, П.П. Кончаловский, А.В. Куприн, М.Ф. Ларионов, А.В. Лентулов, И.И. Машков, А.А. Осмеркин, В.В. Рождественский, Р.Р. Фальк кебек күренекле осталарның рәсем сәнгате, графика һәм скульптура буенча 80 нән артык әсәре саклана. Авангардчы рәссамнарның башлангыч чордагы импрессионистик иҗатын, аларның 1920 елларның икенче яртысы – 1930 еллар башындагы хезмәтләрен, шулай ук 2 нче дулкын рәссам-символистлар К.Ф. Богаевский, П.В. Кузнецов, Н.Д. Милиоти, Н.К. Рерих, Н.Н. Сапунов, М.С. Сарьян, П.С. Уткин һ.б.ның әсәрләрен дә истә тотканда, ул күрсәткеч 150 гә җитә. Коллекциядә рәсем сәнгате белән графика бер дәрәҗәдә, әмма графика өлешендә исемнәр саны азрак, чөнки Д.П. Штеренберг, А.М. Родченко һәм В.Ф. Степанова гравюралары серияләп, П.В. Кузнецов, К.Ф. Богаевский иҗаты – ташбасма альбомнар, И.И. Машков һәм Р.Р. Фальк рәсемнәре монографик коллекцияләр рәвешендә тәкъдим ителгән. Скульптура исә Б.Д. Королев, С.Т. Коненков, И.С. Ефимов композицияләрен генә (барысы – 3) тәшкил итә.

ТР ДССМндагы рус авангарды коллекциясе 1920 елдан – Казан фәнни-сәнәгый музее 1919 елда Казан губерна музее, аннан (1920 елда) Татарстан АССР Үзәк музее дип үзгәртелгәннән соң – формалаша башлый. Бүгенге рус сәнгате коллекциясен тулыландыруда Музей эшләре һәм сәнгати-борынгы заман истәлекләрен саклау буенча Бөтенроссия коллегиясе, шулай ук Мәгариф халык комиссариатының тасвирый сәнгать бүлеге Дәүләт музей фонды (ДМФ) зур роль уйныйлар (аңа кадәр музейда бу өлкәгә караган материаллар бөтенләй булмый). ДМФ 1920 елда музейның сәнгать бүлегенә танылган рус рәссамнарының (беренче чиратта иң яңа сәнгати агымга иярүчеләрнең) күп кенә хезмәтләрен тапшыра. Нәкъ менә шулар арасындагы Б.Д. Королев, С.Т. Коненков, И.С. Ефимовның 3 скульптурасы, күренекле рус авангардчыларының һәм тагын А.В. Грищенко, М.В. Ле Дантю, А.И. Мильман, Н.В. Синезубов, Б.А. Такке, әле зур танылу яуларга өлгермәгән осталарның 40 тан артык тасвирый әсәре Казандагы рус авангардчылары коллекциясенең төп өлешен тәшкил итә. Тапшыру процессы музейның 25 еллыгы (1920 елның апреле), Казан дәүләт сәнгать остаханәсе (Элеккеге Казан сәнгать мәктәбе) бинасында Дәүләткүләм беренче фән һәм сәнгать күргәзмәсен уздыру уңаеннан берничә мәртәбә оештырыла. Соңыннан рус авангардчыларының аларда күрсәтелгән экспонатларыннан күбесе музейның сәнгать бүлеге тупланмасына өстәлә.

Рус авангарды коллекциясе 1920 елларның икенче яртысында – 1930 еллар башында тагын да киңәя: 1927 һәм 1929 елларда ДМФ ннан анда Д.Д. Бурлюк, М.С. Сарьян, В.Э. Борисов-Мусатов, П.С. Уткин рәсемнәре, шулай ук Д.П. Штеренбергның 3 ксилографиясе күчереп урнаштырыла. Шушы ук елларда П.В. Кузнецов белән К.Ф. Богаевскийның басма графикасы альбомы да шул тупламага тапшырыла. 1930 елда анда Дәүләт Рус музееннан да Н.К. Рерихның, Н.Д. Милотти, Н.И. Альтман, Н.И. Кульбинның берничә рәсеме килеп ирешә: 1932 елда дәүләт Третьяков галереясыннан М.Ф. Ларионов һәм В.В. Кандинский хезмәтләре тапшырыла (алар Рәсем сәнгате музее таратылганчы, шул музейда сакланган булалар).

Рус авангарды коллекциясенең алдагы киңәю этабы 1958 елда Музейны яңадан үзгәртеп кору белән бәйле була, анда ул сәнгать бүлегеннән мөстәкыйль Сынлы сәнгать музее статусы ала һәм 1968 елда үз бинасына күчә. 1970–1980 еллар рус авангарды осталарының әсәрләрен аларның варисларыннан табып алу активлашкан чор була. Әйтик, 1969 елда Е.М. Бебутовадан – П.В. Кузнецов, 1975 елда М.И. Машковадан И.И. Машковның 7 һәм тагын 3 рәсем сатып алалар; 1985 һәм 1987 елларда А.В. Щекин-Кротова музейга 2 тасвирый сәнгать әсәре һәм Р.Р. Фалькның 45 рәсемен сатып бирә; 1988 елда музей В.А. Родченкодан А.М. Родченко белән В.Ф. Степанованың график композицияләрен сатып ала.

Россия музейларындагы иң эре саналган рус авангарды коллекциясе әнә шулай формалаша, аның туплану юлларын тулырак итеп өйрәнүчеләрнең берсе – Г.А. Могильникова [Русское искусство…, 2005]. Әлеге коллекция рус авангарды сәнгате үсешенең төп тенденцияләрен һәм аның Р.Р. Фальк һәм И.И. Машков кебек осталарының эволюциясен чагылдыра. 1980 еллардан башлап, бу коллекция ТР Дәүләт сынлы сәнгать музееның даими экспозициясенә әверелә һәм Россиядә дә, чит илләрдә дә рус авангардчылары әсәрләре күргәзмәләрен һәрвакыт зур кызыксыну белән карыйлар. Шундый күргәзмәләрнең кайберләрен әйтеп китү урынлы булыр: «1910–1930 елларда рус һәм совет сәнгате» (Турку, 1989); «В.В. Кандинский» (М.-Л. – Франкфурт на Майне, 1989); «В.В. Кандинский Россиядә» (СПб. – Флоренция, 1993); «Мәскәү – Берлин» (Берлин, 1005–1996; М., 1996); «Авангард амазонкалары» (Берлин, 1999; Лондон – Венеция – Бильбао, 2000; Нью-Йорк – Москва, 2001); «Зәңгәр роза – рус символизмы» (Брюссель, 2005–2006; М., 2006); «Футуризм – радикаль революция. Италия – Россия» (М., 2008); «Гасыр даһие» (Казан, 2017) һ.б.

Казан авангардчы рәссамнары әсәрләре коллекциясен әлеге зур тупланманың логик дәвамы дип әйтергә кирәк. Казан сәнгатендә авангардлык юнәлешләре үсеше фәкать 1910 еллар ахырыннан гына башланып,

1930 елларга кадәр дәвам итә. Казан авангардын, кыска гына вакыт эчендә һәм авыр шартларда, рус һәм Европа авангарды формаларының үзара йогынтысы белән һәм шуларның синтезын татар милли традицияләре белән баетып үстерелгән, үзенә генә хас төсмерләргә ия тулы бер күренеш дип бәяләргә мөмкин. «Көнбагыш» («Подсолнечник»), «Җайдак» («Всадник»), «ТатЛЕФ», «СулФ» иҗади берләшмәләре рәссамнарының сакланып калган әсәрләре аларның Европа сәнгате авангарды яулаган иң яңа казанышларны үзләштерүен күрсәтә. Казан «Сул фронт» тарафдарлары рәсем сәнгатендә, станок һәм китап графикасында, плакат һәм театраль декорация сәнгатендә югары нәтиҗәләр яулыйлар, монда аларның экспериментель театрлар, шагыйрьләр һәм язучылар, әдәби һәм сәнгать әсәрләре тәнкыйтьчеләре белән якыннан хезмәттәшлеге дә зур роль уйный, чөнки алар иҗади хезмәтләрне тикшереп бәялиләр, җитешсезлекләрне ачыктан-ачык күрсәтәләр, кыскасы, яңа хадожество теле табарга ярдәм итәләр.

Казан авангарды коллекциясендә бүген 30 лап рәсем, 600 дән артык график әсәр һәм берничә скульптура берәмлеге исәпләнә. Графиканың өстенлеге Казан рәссамнарының авангардлыкка омтылышы көчле булу белән бәйле.

Казан авангардының музей коллекциясе формалашу ул юнәлешнең үз үсеше белән параллель бара. 1919 елдан башлап, Казан губерна музеенда И.Н. Плещинский, Н.С. Шикалов, К.К. Чеботарев, А.Г. Плутонова, С.С. Федотов, В.Э. Вильковиская, И.А. Никитин, соңрак – Ф.Ш. Таһиров, Н.М. Сокольский, Б.И. Урманче һ.б. кебек күренекле рәссамнарның рәсемнәре, скульптура, графика әсәрләре урын ала.

Сәнгатьтә формализмга каршы көрәш 1930 елларда үзенең иң югары ноктасына җитә, ул осталарны да, аларның күп кенә әсәрләрен дә кызганмый. Сталин чоры дәвере репрессияләренә Б.И. Урманче, С.С. Федотов, И.А. Никитин әлегә, И.Н. Плещинский, М.И. Меркушев, К.К. Чеботарев, А.Г. Плутонов, М.В. Барашев, Ф.Ш. Таһиров, А.Н. Коробкова, В.Э. Вильковиская, Н.С. Ломоносов, Е.А. Александров һ.б. Казаннан китәргә мәҗбүр булалар. Яңа художество телен эзләү белән бәйле әсәрләрнең безнең көннәргә килеп җитүен могъҗиза дип әйтергә кирәк. 1929 елда кулга алынган Б.И. Урманче хезмәтләрен аның шәкерте М.З. Кәримов саклап калган. Г.И. Сотонина АРХУМАС өйрәнчекләре гравюралары оттискларын, ташларга дип, график остаханәсенә бикләнгән хәлдә табып ала һәм аларны К.К. Чеботаревка (1910–1920 еллар Казан сәнгать тормышының елъязмасын туплаучы) тапшыра. Ә менә С.С. Федотов белән М.И. Меркушевның Казанда уздырылган күргәзмәләрдә зур кызыксыну уяткан абстракт рәсемнәре сакланмаган. Сәнгатьнең 1930 еллар башында актуаль саналган бу яңа төре үрнәкләрен иҗат иткән И.А. Никитин һәм Н.М. Сокольский фотомонтажларын да журналларда,

яки махсус басмаларда гына күрергә була.

1960–1970 елларда сынлы сәнгать музее Казан авангардчылары әсәрләре коллекциясен тулыландыруны дәвам итә. Анда К.К. Чеботарев һәм А.Г. Платунова хезмәтләре өстәлә. График коллекция туплау җанланып китә (бу төр сәнгать әсәрләренең төп өлеше иске музей (хәзер ТР Милли музее) фондларында сакланып калган була). Казан авангардының 1920 елларда бу шәһәрдән күчеп китәргә мәҗбүр булган рәссамнары һәм аларның варислары белән тыгыз элемтә урнаштыру бу процессның барышына ярдәм итә. 1978–1979 елларда 1920 еллар Казан графикасын киң яктырткан күргәзмәләр циклы оештырыла, шуннан соң музейга сәнгать әсәрләре сатып алына, шулай ук рәссамнар үзләре, яки аларның туганнары күп кенә хезмәтләрне бүләк итеп бирәләр. Шуның нәтиҗәсендә, һәм алардан тыш та, ТР ДССМ тупланмасында Казанның график осталары И.Н. Плещинский, Ф.Ш. Таһиров, А.Н. Коробкова, Д.Н. Красильников, М.В.Барашев, К.К. Чеботарев, А.Г. Платунова һ.б.ның монографик коллекцияләре барлыкка килә.

Совет хакимиятенең беренче елларында музей хезмәткәрләре тарафыннан тупланган Казан сәнгате коллекциясе 1990 елда «Искусство Татарии 20–30-х годов. Сулф. Леф. Тат. АХРР» дигән зур күргәзмәдә (ул ТР ДССМда уздырыла) тәкъдим ителә. Экспозиция, шул чордагы традицион реалистик юнәлешләр буенча иҗат итүче авангардчы рәссамнарның каршылыклы иҗатына бәйле рәвештә, республика сәнгатендәге күптөрлелекне һәм каршылыклы юнәлешләрне чагылдыра. Күргәзмәнең каталогы [Каталог выставки…, 1980] ватан сәнгатенең берничә дистә еллар дәвамында сәнгать белеме өлкәсеннән читтә калып килгән әлеге катламын өйрәнүдә мөһим чыганак ролен үти.

ТР ДССМның күргәзмәләр оештыру һәм материаллар туплау эшчәнлеге 1990–2000 елларда Казан авангарды коллекциясен тулыландыруны дәвам итәргә мөмкинлек бирә. Моңа 2005 елда Мәскәүнең «Арт-Диваж» галереясында һәм ТР ДССМ нда уздырылган «АРХУМАС: казанский авангард 20-х» күргәзмәсе зур этәргеч ясый [АРХУМАС: казанский…, 2005]. Казандагы «Җайдак» («Всадник») графика коллективының әз тиражлы басма әсәрләре коллекциясе (1920 елларда ТАССР Үзәк музее туплаган ул басмалар ТР Милли музеенда сакланып калган) шуның тәэсирендә формалаша. Шуны да әйтергә кирәк, андый сәнгати басма берәмлекләр бик сирәк һәм алар бүген дә югары даирәләрдә зур ихтыяҗ белән файдаланыла. ТР ДССМ графиканы туплап бастырган «Җайдак» («Всадник») альманахының барлык 4 санын да (1990 елларда 1 нче саны А.И. Новицкийдан, 2005 елда 2 нче саны Б.М. Мөхетдиновтан; 2005 елда 2 нче һәм 3 нче саннары И.Д. Логиновадан) табып алуга ирешә. Аерым авторларны тулыландыру А.Г. Платунова, И.Н. Плещинский, шулай ук 2005 елда И.Д. Логиновадан

алынган альбомнар ярдәмендә башкарыла. 2005 елда А.А. Романович А.Г. Платунова һәм К.К. Чеботарев рәсемнәре коллекциясен бирә. Соңгы елларда музейга килеп ирешкән сәнгати кыйммәтле табыш – А.Г.Платунова тарафыннан 1925 елда иҗат ителгән «Портрет К.К. Чеботарева» хезмәте (аны 2005 елда И.И. Галиев бүләк итә).

2005 елдан башлап Казан авангардчылары рәсемнәре ТР ДССМ бүлекчәләрендә, «Хәзинә» Милли сәнгать галереясында күрсәтелә. Бу юнәлештә иҗат итүче рәссамнарның күргәзмәләре Казанда гына түгел, Мәскәүдә дә оештырыла. Аларның иҗади мирасы үзебезнең илдәге һәм хәзер инде чит илләрдәге зур музейлар тупланмалары һәм экспозицияләре составында да тәкъдим ителә. Мәсәлән, К.К. Чеботарев белән Н.С. Шикалов әсәрләре Дәүләт Третьяков галереясының XX гасыр рус сәнгате экспозициясендә, И.Н. Плещинский рәсемнәре һәм гравюралары Украинаның Киевтагы Милли сәнгать музее даими экспозициясендә тәкъдим ителә. А.С. Пушкин исем. Дәүләт сынлы сәнгать музееның графика фондларында һәм Рус Дәүләт музеенда «Җайдак» («Всадник») рәссамнарының әз тиражлы басмалары, гравюралары һәм аларның такталары саклана [Улемнова].

Болар барысы да Казан авангардчыларының җитди иҗади казанышларын дәлилли, аларның авангардчылык сәнгатендә рус һәм Европа формаларының катлаулы синтезын татар милли традицияләре белән баета белгән үзенчәлекле иҗатын раслый. 2013 елда ТР ДССМ ндагы үзебезнең ил авангардчылары хезмәтләрен туплаган коллекцияләрнең ике өлеше дә федераль кысаларда оештырылган, күптомлы басмаларны да эченә алган «Татарстан сәнгате хәзинәләре» («Художественные сокровища Татарстана») проектында тәкъдим ителде [Казанский авангард, 2014; Русский авангард…, 2014). Бүген һәркемгә мәгълүм булган «рус авангарды» төшенчәсе традициягә әверелгән билгеле бер исемнәр һәм символлар җыелмасын гына күздә тотса, 1920 еллар Казан авангардчылары сәнгате бу юнәлештә Мәскәү һәм Петербург рәссамнары билгеләгән чикләрнең күпкә киңрәк булуын күрсәтә, моны соңгы елларда тәкъдим ителгән күргәзмәләр һәм басмалар да раслый.

**Әдәбият**

АРХУМАС: казанский авангард 20-х. Государственный музей изобразительных искусств Республики Татарстан, г. Казань. Галерея «Арт-Диваж», г. Москва. 28 апреля – 6 июня 2005 / авт.-сост. и авт. вст. ст. И.И. Галеев, О.Л. Улемнова. М.: Скорпион, 2005. 168 с.: ил.

Казанский авангард 1910–1930-х: из серии «Художественные сокровища Татарстана» / авт. вст. ст. О.Л. Улемнова, сост. кат. С.Е. Новикова, О.Л. Улемнова. Казань: Заман, 2014. 112 с.: ил.

Каталог выставки произведений художников Татарии 20–30-х годов: к 70-летию образования ТАССР. Государственный музей изобразительных Р.Г. Шагеева, Д.Т. Садыкова. Казань, 1990. 96 с. : ил.;

Русский авангард 1900–1920-х: из серии «Художественные сокровища Татарстана» / Авт. вст. ст. О.Л. Улемнова, сост. кат. О.Г. Вербина, С.Е. Новикова, О.Л. Улемнова. Казань: Заман, 2014. 112 с.: ил.;

Русское искусство XVII – начала XX веков. Живопись. Каталог. Государственный музей изобразительных искусств Республики Татарстан / Автор-составитель Г.А. Могильникова. Казань: Изд-во «Казань-Kazan», 2005.

*Улемнова О.Л.* Графический коллектив «Всадник». 1920–1924. Каталог выставки «Сметая веками насевшую пыль...». Казань, 2014. 264 с.: ил.

***Улемнова Ольга Львовна,***
*сәнгать фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

УДК 351.852.13

*Н.В. Герасимова*

# 1920 ЕЛЛАРДА ТАТАРСТАН МУЗЕЙЛАРЫ СӘНГАТИ КОЛЛЕКЦИЯЛӘРЕН ФОРМАЛАШТЫРУДА ДӘҮЛӘТ МУЗЕЙ ФОНДЫНЫҢ РОЛЕ

В статье рассматриваются процессы перераспределения художественных произведений из Государственного музейного фонда в музеи Республики Татарстан в 1920-е годы, дается анализ сложившихся в результате коллекций.

**Ключевые слова:** музей, художественные коллекции, Государственный музейный фонд, Отдел охраны памятников искусства, старины и природы НКП ТАССР.

Дәүләт музей фонды (ДМФ) 1918 елда инкыйлабка кадәрге музей коллекцияләреннән, шулай ук, национализацияләп сарай һәм алпавыт утарларыннан, аерым фатирлардан, чиркәү-монастырьлардан һәм башка учреждениеләрдән алынган берәмлекләрдән туплана башлый. Алар, саклау максаты белән, инвентаризацияләнә һәм әһәмияте буенча бүленеп, илдәге музейларга урнаштырыла. Дәүләт музей фондының нигезе сәнгати-тарихи комиссияләр, аннан соң Музей эшләре буенча Бөтенроссия коллегиясе һәм Мәгариф халык комиссариатының сәнгати һәм борынгы һәйкәлләрне саклау, исәптә тоту бүлеге хезмәткәрләре тарафыннан салына [Путеводитель].

Музей эшләре буенча Бөтенроссия коллегиясе 1917 елның ноябрендә оеша. Ул музейда саклау әһәмияте булган әйберләрне национализацияләү, Мәгариф халык комиссаритының (МХК) 371 номерлы «Об объединении деятельности художественных и культурно-исторических музеев» дигән карары нигезендә МХК эшчәнлегенә ярашлы рәвештәге музейлар төзелешенең гомуми планын төзү белән шөгыльләнә; Мәскәүдәге һәм Петроградтагы мәдәни-тарихи музейлар эшчәнлеге белән идарә итә; урыннарда бу эшне губерналардагы үзләренең бүлекчәләре аша оештыра; музей эшләренең барлык мәсьәләләре буенча да карарлар кабул итә [Собрание…, 1945]. Фондның Петроград бүлекчәсендә бу эш белән В.И. Ерыкалов, Мәскәү бүлекчәсендә И.Э. Грабарь идарә итә. Җыелган сәнгать әсәрләре саклау фондларына җибәрелә: Петроградта алар Кышкы сарайга, Кронверкка, Мятлевлар һәм Бобринскийлар һ.б. йортларына, Мәскәүдә Инглиз клубы бинасына, Берг, Гершман, Зубалов хуҗалыкларына урнашкан була. Илдәге үзәк һәм җирле музейлар коллекциясе нәкъ менә шул саклау урыннарындагы әсәрләр белән тулылана да инде.

Бу процесс Казан губернасын да читләтеп узмый. 1919 елның августында Музей эшләре һәм сәнгати, борынгы истәлекләрне, табигатьне саклау бүлеге

оеша (1923 елның 1 сентябреннән ТАССР ХКС карары белән ул музей комиссиясе дип үзгәртелә). Бүлек составына профессор К.В. Харлампович, Б.Ф. Адлер, А.М. Миронов, сәнгать белгечләре В.П. Соколов, П.М. Дульский, шулай ук йөреп эшләүче интрукторлар М.И. Лопаткин, В.В. Перцов, П.А. Радимов кертелә [Протокол 25]. Казанда мондый бүлекне оештыруга РСФСР Мәгариф халык комиссариаты музей эшләре һәм сәнгати һәм борынгы һәйкәлләрне саклау бүлеге мөдире урынбасары И.Э. Грабарь (галим Казанга 1919 елның августында Казан һәм Болгарның истәлекле һәйкәлләрен өйрәнергә килә) зур роль уйный. Шул елда ук ул Казан губерна музеена (бу музей 1894 елда оеша: 1919 елда ул – Шәһәр фәнни-сәнәгый музее; 1919–1920 елларда – Казан Губерна музее; 1920–1944 елларда – ТАССР Үзәк музее; 1941–1981 елларда – ТАССР Дәүләт музее; 1981–1992 елларда ТАССР (1990 нан – ТССР) Дәүләт берләштерелгән музее; 1992–2001 елларда ТР Дәүләт берләштерелгән музее; 2001 елның мартыннан – ТР Милли музее) бүләк итеп «бер йөк картина һәм гравюралар» тапшыра. Мәсәлән: тугыз тасвир мөкатдәсен (икона) тәшкил иткән Новгород язмасы «Деисусный чин», В.К. Бялыницкий-Бирули «Март» (1914), Ф.В. Васильевның «Чебоксары» (?), С.Ю. Жуковскийның «Зимний мотив» (1901 (?)), билгесез рәссамның (П.А. Нилус булса кирәк) «Пейзаж. Этюд», П.И. Петровичевның «Пристань на Волге» (1902 (?)), И.Е. Репинның «Голова казака. Этюд» (1910), К.А. Коровинның «Розы» (1916) һәм В.Д. Фалилеевның 15 офорты. Болар музейның 25 еллыгына гаять кыйммәтле бүләк була [Дульский, 1920, с. 43]. П.М. Дульский билгеләп үткәнчә, музей тупланмасына килеп кергән бу хәзинә «Рус рәссамнары берлеге» эшчәнлеген билгеле бер дәрәҗәдә күзалларга мөмкинлек бирә [Дульский, 1920, с. 43].

Казан Губерна музеена Дәүләт музей фондының Мәскәү бүлегеннән сәнгать әсәрләре тапшыруның икенче этабы 1920 елның апрелендә уздырыла. Анда инде музей рәсем сәнгате һәм скульптура өлкәсендә барлыкка килгән яңа агымнар вәкилләре әсәрләренә байый. Мәсәлән: М.Ф. Ларионовның «Портрет», Н.С. Гончарованың «Евреи» һәм «Пейзаж», А.В. Грищенконың «Портрет», А.А. Осмеркинның «Натюрморт», О.В. Розанованың «Светопись», С.Т. Коненковның «Леда и лебедь», А.М. Гюрджанның «Леда» һ.б. [Список картин и скульптур…]. Шушы ук вакытта музей кызыклы гына тагын бер табышка ия була: ул чыгышы белән Чистай ягыннан булган Мәскәү сәүдәгәре Е.Д. Мясников тарафыннан инкыйлабка кадәр үк тупланган була. Е.Д. Мясников үз заманының сәнгать әсәрләрен туган шәһәрендә сәнгать галереясы ачу максаты белән җыя [Хроника, с. 75]. Шуңа күрә ул әсәрләр ТР Үзәк музеена гына түгел, ә Чистай шәһәрендәге Туган якны өйрәнү музеена да юллана. Бу хакта Дәүләт музей фонды сакланмасындагы әйтеп үткән сәнгать әсәрләрен музей эшләре

буенча Казан бүлекчәсе вәкиле А.Н. Тришевскийга тапшыру актында теркәлә [Акт о приеме…]. Әлеге факт Музей эшләре буенча Бөтенроссия коллегиясе хезмәткәрләренә карата хөрмәт уята. Алар шәхси сәнгать коллекцияләрен национализацияләү сәясәтен үткәргәндә үк, тупланмаларның язмышын хәл иткәндә аларның элекке хуҗаларының үтенечен-теләген истә тотканнар.

Казан музеена чираттагы бүләкне XX гасыр рәссамнарының С.А. Бахрушин тарафыннан тупланып, Третьяков галереясында сакланган 30 картинасы тәшкил итә. Алар арасында К.А. Коровин, А.Н. Бенуа, А.Я. Головин, Л.С. Бакст һ.б.ларның әсәрләре бар [Список картин из собрания…].

Шулай итеп, юбилей уңае белән Казан музеена Дәүләт музей фондыннан төрле тарихи дәверләрдә (борынгы чордан 1900 елларга хәтле), төрле юнәлешләрдә һәм стильләрдә (реализмнан башлап авангардчылыкка кадәр) иҗат иткән рәссамнарның 132 эше тапшырыла.

XIX гасыр чигендә һәм XX гасыр башында барлыкка килгән «Мир искусства», «Союз русских художников», «Голубая роза», «Бубновый валет» сәнгати берләшмәләре вәкилләре иҗатына аеруча зур игътибар бирелә. Казан музеен баеткан бу бүләкләрне һәм ул коллекциянең зур әһәмияткә ия өлешен сәнгать белгечләре Г.А. Могильникова [Могильникова, с. 12] белән О.Л. Улемнова югары бәяли. О.Л. Улемнова, Казан рәсем сәнгатендә авангардлык агымы көчәюгә нәкъ әнә шул хезмәтләр этәргеч бирде һәм илнең эре шәһәрләрендә, шул исәптән Казанда Сәнгати культура музее оештыру максатының ерак киләчәген дә алар билгеләделәр, ди [Улемнова, с. 12]. Җибәрелгән әсәрләрдән кызылармиячеләр һәм шәһәр эшчеләре өчен «Казанда дәүләткүләм беренче сәнгать һәм фән күргәзмәсе» оештырыла [Первая государстенная…].

1920 еллар ахырында, башкала музейларына национализацияләнгән коллекцияләр тупланып беткәч, аларның бер өлешен регион музейларына бүлеп бирү башлана. 1927 елның җәендә, мәсәлән, Казан музее элек Третьяков галереясында, Цветаева галереясында, Яңа Көнбатыш рәсем сәнгате музеенда, Строганов көллиятенең Румянцев музеенда сакланган 39 әсәргә ия була [Акт № 667]. РСФСР Мәгариф халык комиссариаты хезмәткәрләренең ел буе шушы эш өстендә нәтиҗәле хезмәт куюларын да билгеләп үтәргә кирәк. Алар музейның тулы ихтыяҗын ачыклау максаты белән, музей тупланмасының каталогын өйрәнү өчен, Махсус методологик комиссия төзиләр. Аның составына Б.П. Денике, А.М. Эфрос һ.б. керә. А.М. Эфрос 1926 елда Казанга Музейлар конференциясенә килә, шул вакытта ул музей тупланмасы белән дә таныша. Шулай ук ТР Үзәк музее сәнгать бүлегенең музей эшләре Казан бүлекчәсе хезмәткәре П.М. Дульский Мәскәүгә командировкага җибәрелә. Аның максаты Мәскәүдә җыелган материаллар белән танышу һәм картиналарның инде әзер исемлегенә кайбер

төзәтмәләр кертү була [Дульский, 1927, с. 3–4]. П.М. Дульский билгеләп үткәнчә, исемлек төзегәндә Методологик комиссия музейның Сәнгать бүлеге тупланмаларындагы җитешсезлекләрне бетерү максатын куя, чөнки Казан музеенда бу яктан сәйярлык (передвижничество) дәвере аеруча аз яктыртылган була, шуңа күрә комиссия музейга шул чор рәсем сәнгате үрнәкләрен – И.А. Айвазовский, А.П.Боголюбов, Ф.А. Васильев, В.Г. Перов, В.Д. Поленов, В.Е. Маковский хезмәтләрен мөмкин кадәр күбрәк кертергә тырыша [Дульский, 1927, с. 4]. 1920 еллар башында җанланып киткән бу эшне дәвам итеп, музейга «Мир искусства», «Союз русских художников» берләшмәләре рәссамнары М.В. Нестеров, В.А. Серов, С.Ю. Жуковский, И.И. Левитан әсәрләре дә өстәлә.

Дәүләт музей фондыннан ТР Үзәк музеена сәнгать әсәрләре соңгы тапкыр 1930 елның февралендә тапшырыла. Рус музее фондыннан 16 картинаны Казанга күчерү турындагы акт саклакланган. Казанга тагын XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында иҗат иткән Н.И. Альтман, Ф.В. Боткин, И.И. Бродский, Н.П.Крылов, Н.Д. Милиоти, В.А. Серов, Н.К. Рерих һ.б. рәссамнарның әсәрләре дә тапшырыла. Әлеге чараларның оештыручысы Мәгариф халык комиссариатының музейлар эше Казан бүлекчәсе гыйльми сәркатибе һәм ТР Үзәк музееның борынгы рус сәнгате бүлеге саклаучы хезмәткәре П.Е. Корнилов була, соңыннан ул Ленинградка күчеп китә һәм Рус музеенда фәнни хезмәткәр булып эшли.

ТАССР районнарындагы музейларга килгәндә, Музей эшләре буенча Казан бүлекчәсе хезмәткәрләре тырышлыгына карамастан, аларның фонды, әйтеп үткәнчә, Чистай туган якны өйрәнү музеендагы Е.Д. Мясников коллекциясеннән, Дәүләт музей фонды әсәрләреннән кала, беркая да күчерелми. ТР Милли архивында РСФСР фән, сәнгать һәм музей учреждениеләре баш идарәсенә Казан бүлекчәсеннән 24.12.1927 датасы белән республиканың Тәтеш, Зөя, Алабуга, Чистай кантоннары (районнары) музейлары коллекциясен тулыландыруны сорап язылган документлар саклкнган. Анда мондый юллар бар «желательно получить: картины русских школ, гравюры, фарфор, хрусталь и проч...» [В музейный отдел...]. Әмма, РСФСР фән, сәнгать һәм музей учреждениеләре баш идарәсенең музейлар бүлеген үзгәртеп кору белән бәйле булса кирәк, бу үтенеч җавапсыз калган.

Шулай итеп, 1919–1930 еллар аралыгында Дәүләт музей фондыннан ТАССР Милли музеена 180 берәмлек сәнгать әсәрләре килеп ирешкән һәм, әйтергә кирәк, алар музей коллекциясен сизелерлек дәрәҗәдә баеткан- нар да. Шәһәргә А.Ф. Лихачев (нигездә көнбатыш сәнгате) һәм О.С. Александрова-Гейнсның (XIX гасыр рус сәнгате) сәнгать галереяларын (аларда элеккеге хуҗаларының сәнгати зәвыгы чагылыш таба) тапшыру – музейның гомум коллекциясен борынгыдан башлап, XX гасырның яңа агымнарын колачлаган дәвердәге сәнгать үсешен яктыртырлык

итеп баета. Ягъни халыкларның барлык чордагы сынлы сәнгате әсәрләрен туплаган Сәнгати культура музее төзү идеясе, өлешчә, Казанда тормышка ашырыла [Искусство коммуны].

**Әдәбият**


Акт № 667. НА РТ ф. 2021. оп. 1, ед. хр. 78, л. 43–44.

Акт НА РТ ф. 2021. оп. 1, ед. хр. 114, л. 162.

Акт о приеме музейных экспонатов. НА РТ ф. 2021. оп. 1, ед. хр. 14, л. 1–2.

В музейный отдел главнауки РСФСР. НА РТ ф. 3682. оп. 1, ед. хр. 1185, л. 79.

*Дульский П.М.* Вступительная статья. // Выставка картин, выделенных государственным музейным фондом Москвы Центральному музею ТАССР. Каталог. Казань, 1927. С. 3–6.

*Дульский П.М.* Новые приобретения художественного отдела Казанского Губернского музея. // Казанский музейный вестник № 1–2. 1920, с. 35–46.

Искусство коммуны. 1918. 15 декабря.

*Могильникова Г.А.* История формирования коллекции русской живописи Государственного музея изобразительных искусств Республики Татарстан. // Русское искусство XVII – начала XX веков Живопись: каталог.

Государственный музей изобразительных искусств Республики Татарстан. Казань: Kazan-Казань, 2005. С. 9–15.

Первая государственная выставка искусств и науки в Казани. Каталог. Казань: «Первая государственная типография», 1920.

Протокол 25 совместного заседания коллегии Казанского подотдела и Совета общества археологии. Истории и этнографии 11 августа 1920 г. НА РТ ф. 271, о. 1, е. х. 162, л. 62.

Путеводитель. // Центральный государственный архив литературы и искусства Санкт-Петербурга. 2007 [Электронный ресурс] http://guides.rasarchives.ru/browse/guidebook.html?bid=402&sid=1202105 дата обращения: 18.08.2017).

Собрание узаконений и распоряжений правительства за 1919 г. Управление делами Совнаркома СССР. М, 1943, с. 553–554.

Список картин и скульптур, отобранных из Государственного Художественного Фонда Отдела изобразительных искусств Наркомпросса для пополнения Музея в г. Казани. НА РТ ф. 2021. оп. 1, ед. хр. 14, л. 8–9.

Список картин из собрания б. С.А. Бахрушина, переданных из помещения Государственной Третьяковской галереи, по постановлению Отдела по делам музеев и охране памятников искусства и старины Наркомпрсса, в Казанский музей. НА РТ ф. 2021. оп. 1, ед. хр. 14, л. 3–4.

*Улемнова О.Л.* АРХУМАС – мастерская художественного авангарда Казани // АРХУМАС. Казанский авангард 20-х. Каталог выставки. М.: Скорпион, 2005. С. 7–18.

Хроника // Казанский музейный вестник № 3–4. 1920 с. 75.


*Мәкалә РФФИ һәм Татарстан Республикасы хөкүмәтенең финанс ярдәме белән 17-14-16022 номерлы фәнни проекты кысаларында әзерләнде.*

***Герасимова Наталья Владимировна,***
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге фәнни хезмәткәре*

УДК 377.1:730

*Т.Н. Кривошеева*

# КАЗАН СӘНГАТЬ МӘКТӘБЕНДӘ СКУЛЬПТУРА ДӘРЕСЛӘРЕ АЛЫП БАРУНЫҢ КӨНБАТЫШ ЕВРОПА ҺӘМ КӨНЧЫГЫШ ТРАДИЦИЯЛӘРЕ

Статья посвящена отражению традиций восточной и западноевропейской школ в преподавании скульптуры в казанской художественной школе на трех этапах ее истории. Первый этап – начало XX века, время основания школы до 1920-х годов, второй – середина XX века, он связан с деятельностью С. Ахуна, последний – настоящее время, деятельность отделений керамики и скульптуры в Казанском художественном училище им. Н.И. Фешина.

**Ключевые слова:** этнический, скульптура, преподавание, школа, пластика.

Казан сәнгать көллиятенең скульптура бүлегендә һәм В. Суриков исем. Мәскәү дәүләт архитектура һәм сәнгать институтының Казан филиалында хәзер скульпторларның яңа буынын – иҗади эш процессында, техник һәм матди мөмкинлекләрдән файдалана белү белән бергә, электән яшәп килгән тәҗрибәне дә, мәдәни киңлектә үзтәңгәллеккә ирешү юлларын да оста файдалана белүче сәнгатькәрләрне әзерлиләр. Татар скульптурасының тарихи язмышы җиңел булмый: озакка сузылган дини һәм идеологик карашлар хөкем сөргән кырыс заманнарда иҗади процесслар бөтенләй туктап тора. Стиль формалаштыручы ике төп юнәлеш – академик реализм (Европа мәктәбе) һәм этник кушылмалар (Көнчыгыш, «төркиләргә кадәрге») хакында киңрәк тукталып үтү урынлы булыр. XX гасыр башында Республикада скульптур белем бирүнең кабатланмас үзенчәлеге һәм яңалыгы белән аерылып торган беренче омтылыш Казан сәнгать мәктәбенең (КСМ) скульптура бүлегендә ясала, ул Петербург сәнгать академиясендә пластика укыту тенденцияләрен хәтерләтә. Бу чорда бүлек эшчәнлегенә укытучылардан П. Дзюбанов белән В. Богатырев зур өлеш кертәләр [Кривошеева, 2006].

1917 елгы Октябрь борылышыннан соң Казан сәнгать-педагогика техникумында (КСМ-ның шул еллардагы исеме) укытуны халык хуҗалыгы өчен яраклаштырылган гамәли сәнгать юнәлешендә алып барырга тәкъдим ителә. Сәнгать белеме бирү буенча методик комиссия утырышында «ялгыз талантлар турында түгел, ә массакүләм гомуммәдәният хакында уйларга кирәк» дип чыгыш ясыйлар. 1927 елда КСМ Казан берләштерелгән сәнгать-театр техникумы буларак эшли. Методик комиссия утырышларының берсендә архитектура-сәнгать курсларында «совет» уенчыклары әзерләү мәсьәләсе дә күтәрелә.

1937 елда Казан сәнгать көллиятендә скульптура укытучысы булып Садри Ахун эшли башлый. Ул анда Урал сәнгать техникумын, аннан соң Сәнгать академиясен (А. Матвеев мастерское буенча) тәмамлагач килә. Садри Ахун, татар сынлы сәнгатендә, беренчеләрдән булып, әвәләп кеше сынын ясый, портретларны һәм җәнлек рәсемнәрен академик традицияләргә нигезләп иҗат итә.

Садри Ахун Казан сәнгать көллиятендә 1952 елга кадәр эшли. Бу уку йортында скульптура бүлеге фәкать 1948 елда гына оеша. Нәкъ менә шул елдан анда Н. Адылов, В. Маликов, Р. Нигъмәтуллина укый. Алар соңыннан Совет рәссамнары берлегенең татар бүлеге профессиональ секциясендә үзәк фигураларга әвереләләр. Казан сәнгать мәктәбеннән В. Богатырев киткәннән соң бу бүлектә академик скульптура буенча белем бирүнең икенче этабы башлана.

Ул елларда скульптур композицияләрнең стиле мәдәнияттә хакимлек иткән «социалистик реализм» методына нигезләнә.

XX–XXI гасырлар чигендә Татарстанда мәдәният-сәнгать мәҗбүри кануннардан азат ителә һәм татар скульпторларының һәркайсына иҗади үзенчәлекләрен сәнгатьтә тулысынча гәүдәләндерергә мөмкинлек туа, һәм алар аннан уңышлы файдаланалар да. XXI гасыр башында Казан сәнгать көллиятендә пластика укытуны яңартып җибәрү омтылышы уяна. Ул – көллиятне К. Маркс урамындагы Казан сәнгать мәктәбенең архитектор К. Мюфке проекты буенча махсус эшләнгән бинасына күчерү вакыйгасы белән дә бәйләнә. Аңа кадәр әлеге бина анда урнашкан Казан авиация институтыннан сәнгати керамика бүлеге өчен, һөнәрханә (мастерской) буларак, арендага алынган була. Анда студентлар, рәсемнәр һәм картиналар ясаудан тыш, декоратив скульптура, балчыкны әвәләп һәм төрле формадагы калыпларга салып әйберләр эшләү белән шөгыльләнәләр. Бу бүлекнең эшчәнлеге пластика укытуның яңа этабында калыплап сәнгать әсәрләре эшләүне башлап җибәрүдә генә түгел, скульптур композицияләрнең этник-милли символларын аңлап иҗат итүдә дә зур әһәмияткә ия. XX гасырның соңгы утыз елында Көнбатыш Европа һәм Россиянең мәдәни киңлегендә сәнгатьнең башка юнәлешләрен эзләүнең яңа формалары (модернизмга каршы буларак постмодернизм) барлыкка килде. Татарстанның мәдәни тормышы пластикасында бу, барыннан да элек, җирле архетипта, борынгы мәҗүсилек һәм мөселманлык үзенчәлекләрендә чагылыш тапты. Скульптура үсеше ыруглык үзенчәлекләрен саклаган хәлдәге яңа формалар ала. Казан сәнгать көллиятенең нәфис керамика бүлеге композицион әсәрләр тудыруда крайдагы борынгы фигуратив һәм орнаменталь мотивларга таяна. Декоратив материал буларак керамика бакча-парк пластикасының да, кечерәк формаларның да скульптур чишелешен хәл итәргә мөмкинлек бирә. Шуңа күрә керамика бүлегендә белем алучылар,

академик кысалар белән генә чикләнмичә, стильләштерүнең сәнгати чагылыш мотивларыннан һәм ысулларыннан иркен файдаланалар. Бу өлкәдә студентларның курс эшләреннән З. Гәрәеваның «Татар малае» («Татарский мальчик»), Р. Сабировның «Өзлексез хәрәкәттәге тормыш» («Жизни круговорот»), «Алтынурдачылар» («Золотоордынцы»), Т. Зәбировның «Тәкә» («Баран») һәм диплом эшләреннән З. Гәрәеваның «Өзлексез берләшү» («Бесконечное единение»), Т. Зәбировның «Үгезләр» («Быки») фигуралары аеруча кызыклы иҗат ителгән. З. Гәрәеваның «Татар малае» таш скульптураны хәтерләтә, аның аскы өлеше махсус рәвештә өскесеннән кыскарак эшләнгән: билдән җилкәгә кадәр ара, киресенчә, озынайтылган. Гомумән алганда фигура нәфис итеп, үсмерләрчә озын муенлы итеп ясалган. Малай мәдрәсә яки шул чор мәктәбе киеменнән; кайбер детальләре рельефлап әвәләнгән, икенчеләре исә тирән эзләр калдырып тырналгансыман. Батып торган эзләргә фирәзә төсен хәтерләткән бакыр окисе белән эмаль тутырылган. Ә шул ук авторның «Өзлексез хәрәкәттәге тормыш» композициясе берничә элементны берләштерә: ат, кулларын баш өстенә түгәрәкләп куйган алиһә-хатын һәм кошлар. Бу фигуралар борынгы керамик сфероконуслардагы атларны символлаштырган графиканы хәтерләтә, тик аның линияләре киң һәм аларга персонажлар өстәлгән. Шунысы кызык, студент бу эшен жгут техникасы нигезендә (чүлмәкне түгәрәкләп эшләүнең техник ысулын белмәгән чордагыча) эшләгән. Р. Сабировның «Алтынурдачылар»ы кыяга охшатылган таш скульптура стилендә иҗат ителгән. Кайсы яктан карасаң да тәэсирле булып күренә (фронталь итеп эшләнмәгән). Тасвирланышы белән ул артык аерылып тормый, архитектур яктан тыйнак һәм шактый нык буялган, автор бизәкләрне авангард стилендәрәк төшергән, форма бирүче линияләр һәм график таплар кулланган. Т. Зәбировның анималистик скульптуралары – «Тәкә» дә, «Үгезләр» дә уртак пластик чишелешләргә ия, гәрчә беренчесе – өстәлгә куярлык масштабта, икенчесе бакча-парк пластикасына нигезләнсә дә. Бу ике фигурада да хайваннарның гәүдәләнеше ачык детальләргә һәм бизәкләргә бай. Әйтик, тәкәнең кара ярымшарсыман өлешенә уелып алтынсу соляр (кояшсыман) тамгалар төшерелгән, стильләштерелгән башы белән мөгезе дә шундый ук характердагы орнаментлар белән бизәлгән.

Казан сәнгать көллиятенең скульптура бүлегендә укытуны бөтенләй яңача алып бару, 2001 елдан башлап, скульптор һәм укытучы А.М. Миңнуллина исеме белән бәйле. Ул бүлекнең матди базасын бөтенләй яңарта. Көллияттә, әкренләп, заманча станоклар, эш кораллары, балчык, гипс барлыкка килә. Скульптура остаханәсе (мастерское) шактый вакыт эшләми торганга, аның программасы да, педагогик ысуллары да яңабаштан үзгәртелә. Шулай да беренче чыгарылыш диплом ияләренә Сән-

гать академиясенең XX гасыр башындагы укыту алымнарын да, шул ук вакытта яңа методика нигезләрен дә узарга туры килә. А.М. Миңнуллина үзенең өченче ел яңача эшләү дәверендә инде бүлек укучыларының чын осталарча, профессионалларча иҗат итү алымнарын үзләштерүләренә ирешә. Студентларның эшләре имтихан комиссиясенең югары бәясен ала, һәм аларның иҗади хезмәтләре теләсә кайсы күргәзмәләр залында профессиональ осталарныкы белән ярыша алырлар иде. А.М. Миңнуллина методикасы студентларның дөньяви киңлектәге пластик сәнгать үрнәкләрен үзләштерүенә, борынгы скульптура әсәрләренең эчке архитектоникасын, форма төзелешен аңлап иҗат итүенә ирешүне күздә тота. Гомумән, Казан сәнгать көллиятендә скульптура буенча заманча укытуның нигезен бүген дә Сәнгать академиясендә XX гасыр башында кулланылган принциплар – борынгы үрнәкләрне өйрәнү, сюжет белән теманың беренчелегенә төшенү, образларны чынбарлыктагыча гәүдәләндерү тәшкил итә. 2006 елдагы диплом эшләре арасында Ф. Вәлиуллинның «Яшьлек» («Юность»), С. Ненароковның «Зәңгәр яулык» («Синий платочек»), Ф. Миңнебаевның «Әти» («Отец»), З. Мөхәммәдьянованың «Авыр әңгәмә» («Трудный разговор») иҗатлары аерым игътибарга лаек.

Ф. Вәлиуллин композициясендә яшьлек һәм җайдак темасы күтәрелгән, Җайдак – татар халкының яраткан персонажларының берсе, ә атка атланган егет, К. Петров-Водкин образына аваздаш булып, хыял, өметләр, якты киләчәк хисләре уята. Ат белән бәйле композиция башлап иҗат итүче скульптор өчен җиңел эш түгел, ә бу очракта автор аны уңышлы башкарып чыккан. З. Мөхәммәдьянова да ике фигуралы катлаулы композицияне җиңеп чыккан. Кыз белән егет фигуралары архитектоник яктан эчке киеренкелек халәте тудыра. Бер-берсенә каратып бастырылган фигуралар, скульптураның кайсы ягыннан гына карасаң да, үзара бәхәсле сөйләшүнең яңа ракурсын ачыклыйлар. «Әти» һәм «Зәңгәр яулык» әсәрләренең икесендә дә ялгыз утыручы фигуралар гәүдәләндерелгән. Эскәмиядә утыручы өлкән кеше скульптурасы тынычлыктан канәгатьләнеп калган картны хәтерләтә. Икенче скульптура хәрәкәтне – сугыш кыры тынып торган арада гармунда уйнаучы сугышчыны тасвирлый, ул «тальянкасын» тартып җибәргән халәттә гәүдәләндерелгән.

Димәк, композицион эшләрнең гәүдәләндерү рәвешеннән чыгып, Казан сәнгать көллиятендә скульптура укытуның ике төп юнәлешен аерып карарга була икән. Аның берсенең нигезен мифологик үзенчәлекләрдә дә чагылыш тапкан төрлелеккә, символлылыкка, тамгалылыкка ия этник пластика тәшкил итә. Икенчесе – В. Суриков исем. Мәскәү дәүләт архитектура һәм сәнгать институтының Казан филиалында скульптура укытуда кулланылган реализм юнәлеше. Монысы инде гипербола һәм гротесклардан азат, аның

бурычы укучыларны һәрнәрсәне тормышчан итеп һәм әдәбипсихологик нигездә сурәтләү осталыгына өйрәтүдән гыйбарәт. Бүген заман сәнгатендә бер генә юнәлештә иҗат итү мөмкин түгел, дөньякүләм һәм рус сәнгатенең авангардизм агымы мәдәниятләрне гомумиләштерүгә (синтезлауга) юл ачты, ягъни бер үк әсәрне иҗат иткәндә борынгы этник стильләр дә, Европа-рус мәктәбе алымнары да үрелеп бирелергә мөмкин.

***Кривошеева Татьяна Николаевна,***
*сәнгать фәннәре кандидаты,*
*Россия Рәссамнар берлеге әгъзасы*
*email: krita06@mail.ru*

## ТОРМЫШКА АШКАН ХЫЯЛ

*Альманах. Искусствоведение Татарстана. «Сәнәигы нәфисә». Выпуск 1. Теория, история, современная художественная практика, арт-рынок. Автор-составитель Р.Р. Султанова. Казань, 2017. 313 с.: ил.*

Сәнгать белеме өлкәсен киң колачлаган махсус җыентыкның дөнья күрүе республикабыз мәдәни тормышына яңа сулыш өрде. Мондый басмалар басылып чыгу яңалык түгел әлбәттә, ә бусы тирән эчтәлекле һәм концепцияләренең гаять киңлеге белән аерылып тора. «Альманах»ның бурычы ватан һәм дөнья сәнгать киңлегендә Татарстан Республикасы сәнгать тормышындагы заманча юнәлешләрне ачыклау гына түгел, ә, Рауза Солтанованың «Редактор сүзе»ндә тәфсилле әйтелгәнчә, сәнгать белеме фәне горизонтларын киңәйтү, яңа идеяләрне, кураторлык проектларын фәнни яктан дөрес бәяли белүне дә үз эченә ала.

Чыннан да, «Альманах» сәнгать белеме өлкәсендәге әлегә кадәр туплаган күнекмәләребезне бөтенләй киңәйтеп җибәрә, төрле юнәлештәге киң катлау белгечләрне фикер алышуга, бәхәсләшүләргә, хәтта тәнкыйди чыгышларга этәрә. Һәм болар барысы да объектив анализлау осталыгын камилләштерергә ярдәм итә, шулай ук арт-концепцияләргә төшенергә һәм сәнгати практикаларга юл ача.

«Альманах»ның әлеге чыгарылышы сәнгать белеме өлкәсендәге күп төрле юнәлешләрне ачыкларга мөмкинлек бирә. Басмада урын алган бүлекләрне атап үтү генә дә аны төзүчеләрнең фикри тирәнлеген дәлилли: әйтик, мирас, иҗади портретлар, сәнгать белеме бирү өлкәләрен җитди өйрәнүдән башлап, яңа басмаларны рецензияләүгә һәм арт-хроникаларга кадәр тематиканы эченә ала. «Альманах»ны горизонталь яссылыклардан торган пирамидаларга тиңләп була: нигезендә – аерым сәнгати катламнар (арт-хроника, күргәзмәләр, пленэрлар, иҗади сәяхәтләр); аннан өстә – «Зур Идел» һәм «Болгарлар. Миф. Чынбарлык» проекты, «Урман-арт» этнофутуристик симпозиум кебек елның үзенчәлекле вакыйгалары. Иҗади портретлар. Юбилярлар. Сәнгатьтә – яшьләр. Дүртенче яссылыкта – Сәнгать белеме бирү. Һәм, ниһаять, пирамиданың иң югары өлешендә – Мирас. Ул бүлектәге Динә Хисамованың «Формирование кадров скульпторов-монументалистов Татарии», Светлана Червоннаяның «Истоки и генезис искусства исламской эпиграфики. Резные надгробия крымских татар» хезмәтләре материалны чыганаклар ярдәмендә тирәнтен өйрәнеп язылганнар. Ольга Улемнова «Татарский левый фронт искусств» өлкәсен, 1920 еллардагы совет сәнгате темасының дәвамы рәвешендә, һәркемне җәлеп итәрлек итеп яктырткан. Николай Фешин иҗаты буенча әйдәп баручы белгеч Галина Тулузакова

күренекле нәкышьче турында күңелләрне күтәреп җибәрердәй мәкалә белән чыгыш ясый, автор мәгълүмати яктан гына түгел, теле-стиле буенча да югары кимәлдә яза белүе белән аерылып тора. Илебездә бүген сәнгать белеме үсеше картинасын Рауза Солтанова, сәнгатне һәм мәдәниятне өйрәнү юнәлешләренең мөһимлегенә басым ясап, кыска гына, әмма оста итеп тасвирлаган.

«Альманах»ның әһәмияте аның сәнгати практикага йогынтысы белән бәяләнә. Татарстанның көньяк-көнчыгыш регионы сәнгать белгечләре һәм гомумән сәнгать сөючеләр җәмәгатьчелеге әлеге басманы рухланып кабул иттеләр. Иҗади интеллигенция вәкилләре өчен үз эшчәнлекләрен Татарстан сәнгатенең бүгенге үсеш дәрәҗәсеннән чыгып бәяләргә, ягъни иҗатыңа тәнкыйть күзлегеннән карап, аны сәнгать белеменә нигезләп, үзеңнең күргәзмәлелек тупламаңны күздән кичереп, яңа оригиналь проектлар эшләргә, күңелеңә якын темаларга башка ракурстан карарга, шулай итеп, иҗади импульсыңны җанландырып җибәрергә мөмкинлек туды. Иҗатчы-рәссам өчен иң мөһиме – әсәрләреңнең чын мәгънәсендәге сәнгать белгечләре тарафыннан анализлануы. Уңай яктан яки реклама характерында гына түгел, ә объектив якын килеп, кирәк икән, конкрет тәкъдимнәр күрсәтелгән анализ ясалу зарур. Бүгенге сәнгать белемендә мондый анализлар онытылды диярлек, чөнки сәнгати концепцияләрнең төрлелеге чиктән ашты, ә аларның гәүдәләнеше сыйфатына карата сүз әйтергә хәзер бөтенләй батырчылык итмиләр. Ә инде яңа «Альманах»та басылган материалларга таянып, сәнгать әсәрләренә тәнкыйди күзлектән чыгып бәя бирүгә, фикерләр каршылыгын ачыктан-ачык белдерүгә юл ачылды. «Зур Идел» («Большая Волга») X һәм XI күргәзмәсенә карата белдерелгән бәяләмәләр һәрчак көнүзәк темаларның берсе булып кала бирә. Владимир Кошаевның күләмле мәкаләсендә 2008 елгы күргәзмәләрнең программа тезислары белән рәсем сәнгатенә карата булган таләпләр һәм тәкъдимнәр тәңгәллеге хакындагы мөһим идеяләр күтәрелә. Автор сәнгатьнең эчтәлеге белән кызыксыну көчәюен билгеләп үтә. Ул гомумсәнгать һәм, аерым алганда, провинциядә яшәп иҗат итүче авторларның күбесе өчен актуаль саналган милли-тарихи бердәмлеккә, Россиядә сәнгатькә караш һәм заманча сәнгати фикерләү проблемаларына киң урын бирә. Ә менә 2013 ел күргәзмәләрен яктыртуга саерак туктала. Бу өлеш, нигездә, анда катнашучылар хакында констатацион характердагы шәрехләмәләрне генә хәтерләтә.

Басманың «Творческие портреты (художник о своем творчестве)» бүлеге сәнгать осталары турында автор поэзиясе – «За кругом бытия» – рәссамнар игътибарын аеруча җәлеп итә. Әлбәттә, алар арасында урын алу өчен үзенчәлекле талантка ия булырга кирәк, ә ул һәркемгә бирелмәгән, әмма андый шәхесләр безнең якларда да бар. «Альманах»ның әһәмияте тагын шунда – аның

аша без рәссамнар гына түгел, ә сәнгать белгечләре һәм сәнгатебезнең тарихчылары хакында да шактый мәгълүмат алдык. Мин үзем, мәсәлән, киң белемле тикшеренүче Динә Вәлиева турындагы мәкаләне бик рәхәтләнеп укыдым. «Альманах»ның алдагы чыгарылышларында әйтеп үтелгән темалар тагын да тирәнрәк күтәреләчәгенә ышанып калабыз. Мондый басманың бурычы да бит мәдәни-сәнгати киңлектәге һәр вакыйганы җәһәтлек белән яктырта бару.

Мәдәният, сәнгать белгечләрен, тарихчыларны, крайны өйрәнүче һәм музей хезмәткәрләрен, галереялар оештыручы һәм педагогларны дисциплинаара фәнни диалогка җәлеп итү максаты белән даими уздырыла торган фәнни-гамәли конференцияләр, беренче чиратта, сәнгать белеме өлкәсендә, республика белгечләреннән тыш, Россиянең төрле регионнары һәм башка илләр сәнгатькәрләрен турыдан-туры актив фикерләүгә тарту өчен оештырыла. Анда күтәрелгән һәр проблеманың һәм аларның чишелеш юлларының «Альманах»ның алдагы чыгышларында яктыртылып баруы зарур.

Сәнгать белеме өлкәсендә күтәрелгән проблемалар, тикшеренү барышында килеп туган оригиналь идеяләр, өйрәнелә торган тема буенча гамәли хезмәткәрләрне генә түгел, регион сәнгате теоретикларын да яңача фикерләүгә этәрергә мөмкин. Мин үзем күп еллар дәвамында Татарстанның көньяк-көнчыгыш төбәгендә сынлы сәнгать үсешенең төп юнәлешләрен ачыклау, ватан һәм дөнья сәнгате үсешенең гомум агымы контекстында аның аерым вәкилләре иҗатын барлау өстендә эшлим. Ә инде «Альманах»ның әлеге басмасы белән танышып чыгу миңа башлаган эшемне дөрес планлаштырып алып барырга ярдәм итте, аның файдасызга югалып әрәм булмасына ышанычым артты.

Басманың авторлар коллективы искиткеч зур һәм профессиональ яктан югары дәрәҗәдәге эш башкарган. Татарстанның көньяк-көнчыгыш төбәгендә сәнгати эшчәнлек алып барган барлык хезмәттәшләрем исеменнән шушы «Альманах»ны төзеп-туплап чыгаручы иҗади коллективны чын күңелдән котлыйм. Менә дигән белгеч, сәнгать өлкәсендә гадәттән тыш актив эш алып баручы Рауза Солтановага аеруча рәхмәтлебез. Ул, әлеге басманың һәм башка күп кенә проектларның фәнни җитәкчесе һәм авторы, республика сәнгать тормышын җанландыруга зур көч кую белән бергә, үзенең фикердәшләрен иҗади эшкә рухландыручы да.

«Альманах» басмаларын туплап чыгару дәвам итәчәгенә, аның һәр санына ихтыяҗның зур булачагына ышанычыбыз зур.

***Горюнова Нина Михайловна,***
*сәнгать белгече, Лениногорск музыкаль сәнгать-педагогика көллияте укытучысы*

## ВЕЛИЕВ А. XXI ГАСЫР БАШЫ АЗӘРБАЙҖАН ТЕАТРЫ

А. Велиевның «XXI гасыр башы Азәрбайҗан театры» монографиясе Азәрбайҗан милли театрының СССР таркалу һәм республиканың бәйсезлеген торгызу чорындагы проблемаларын өйрәнеп тикшерүгә багышланган. Китап авторның күпьеллык тикшеренүләренә нигезләп язылган һәм ул басманың темасына тулысынча тәңгәл килә.

Әлеге хезмәттә Азәрбайҗан театр сәнгатенең бөтенлеген тәшкил иткән һәртөрле оештыру юнәлешләре, шулай ук аның бәйсез, мөстәкыйль формадагы үсеше тәкъдим ителә.

Авторның максаты – бүгенге шартларда Азәрбайҗан театрын торгызу буенча потенциаль мөмкинлекләрне, аның хокукый, икътисади нигезләрен, матди-техник үзенчәлекләрен ачыклау. А. Велиев аны милли мәдәниятне торгызу сәясәте контекстыннан чыгып, билгеләнгән стратегик принципларга һәм нәзари үрнәкләргә (модельләргә) таянып тормышка ашыра.

Автор үзенең монографиясендә бүгенге заман театры үсеше процессларын оптимальләштерүче нәзари үрнәкләр (модельләр) булдыруны бурыч итеп куя.

Шуны ассызыклап үтәргә кирәк, авторның эзләнү-тикшеренүләре югары бәяләүгә лаек нәтиҗәләр бирә.

А. Велиев, бөтендөнья театры концептуаль үрнәкләреннән (модельләреннән) файдаланып, Азәрбайҗан театрын һәрьяклап прагматик призма аша бәяли. Азәрбайҗанда театр эшчәнлегенең яңа шартлардагы үсешен билгеләүче иҗтимагый-сәяси, икътисади һәм хокукый реалияләргә зур игътибар бирә. Театр эшчәнлегенең идеологик һәм административ принципларына чагыштырма анализ ясап, дөньякүләм театр сәнгатенең заманча модельләренә аерым тукталa, «театраль киңлек» төшенчәсенең мәгънәсен ача.

Үз темасы буенча чыганаклар базасының байлыгына карамастан, монография авторы тарихи-мәдәни даирәнең, сәнгать белеменең һәм борынгыдан (Борынгы грек театры, Борынгы Рим театры һ.б.) сакланып калган рухи мирасның аерым өлкәләренә дә мөрәҗәгать итә, тынгысыз эзләнүләре һәм практик эшчәнлеге нәтиҗәсендә яңа материаллар таба (мәсәлән, Көнбатыш Европада һәм АКШтагы театраль процесслар хакында). Алар китапның фәнни әһәмиятен күтәрәләр.

Сүз дә юк, бүгенге дөньяның югары технологияләре, теләсә нинди ераклыкка мәгълүмат тапшыруның зур тизлеге кешеләрне тагын да катлаулырак, техник яктан заманча җиһазландырылган күңел ачу чараларына ныграк җәлеп итә. Шуңа күрә автор китабында Азәрбайҗанның хәзерге милли театр оештыру процессындагы матди-техник үзенчәлекләргә аерым бүлек багышлый.

Китап, үз халкының мәдәнияте белән тирәнтен кызыксынып тикшеренүче – театр белгеченә хас булганча, матур тел белән,

мавыктыргыч, тәэсирле итеп, милли төсмерләргә баетылып язылган. Басмада күптөрле, шул ук вакытта махсус сайланган, зур кыйммәткә ия истәлекле иллюстрацияләр урын алган.

Китапның кушымтасына «Театр һәм театр эшчәнлеге турында» Азәрбайҗан Республикасы Законы, «Азәрбайҗан театр сәнгате үсеше турында» Азәрбайҗан Республикасы Президенты боерыгы, ««2009–2019 елларда Азәрбайҗан театры» Дәүләт программасын раслау турында» Азәрбайҗан Республикасы Президенты боерыгы, «“2009–2019 елларда Азәрбайҗан театры” Дәүләт программасы» кебек дәүләткүләм документларны өстәп, автор Азәрбайҗанда театр сәнгатенә бүгенге хакимиятнең мөнәсәбәтен ассызыклый.

Кешеләр тормышына вакыт китергән котылгысыз үзгәрешләр сәнгатьнең бу төре өчен куркыныч янамый. Театр дөньясы – рухи интеллектуаль кеше өчен иң мөһиме. Автор шушы хакыйкатьне аңлап кына калмый, әлеге төшенчәне монографиясендә тагын да тирәнрәк чагылдыруга ирешә.

***Шаһиев Рәфкать Шириаздан улы,***
*филология фәннәре кандидаты.*
*Әлмәт шәһәре*

# САБИТОВА И.И. ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ СҮЗЬЯСАЛЫШ СҮЗЛЕГЕ: «КЕШЕ» ТЕМАТИК ТӨРКЕМЕНӘ КАРАГАН ЛЕКСИКА

«Татар теленең сүзьясалыш сүзлеге: “кеше” тематик төркеменә караган лексика» басмасы «2014–2020 елларга Татарстан Республикасында дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында нәшер ителде. Аны төзүче автор – Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты лексикография бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты И.И. Сабитова. Җаваплы редакторлары филология фәннәре докторлары, профессор Ф.Ә. Ганиев һәм профессор К.Р. Галиуллин.

Сүзьясалышы сүзлекләренең төп үзенчәлеге сүз ясалуның юлларын билгеләүдән, ясаучы һәм ясалма сүзләр арасында үзара бәйләнешләрне ачыклаудан гыйбарәт. Сүзьясалышы сүзлекләрендә нинди дә булса бер ирекле тамыр (яки ирекле нигез) астына бөтен тамырдаш сүзләрне җыю белән бергә аларның үзара бәйләнешләрен күрсәтү дә мөһим шарт. Мондый басмалар сүзләрнең сүзьясалыш потенциалын һәм структурасын төгәлрәк билгеләү өчен дә хезмәт итәләр. Тәкъдим ителгән сүзлек хәзерге лексикографиядә кабул ителгән принципларга җавап бирерлек дәрәҗәдә һәм сүзьясалыш сүзлекләренә куела торган таләпләрне искә алып эшләнгән. Автор әлеге кулланмасын күренекле дериватолог А.Н.Тихоновның сүзьясалыш оялары принципларына нигезләп төзелгән һәм белгечләр тарафыннан югары бәяләнгән «Словообразовательный словарь русского языка» (2 томда), К.Г. Ишбаев һәм З.К. Ишкилдина төзегән башкорт теленең кыскача сүзьясалыш сүзлеге үрнәгендә әзерләгән.

Татар тел белемендә сүзьясалыш сүзлекләренә караган ике белешмәлек билгеле. Беренчесе – А.М. Ямалетдинова һәм И.А. Латыйпова тарафыннан «Кеше. Кеше тәне (организмы) өлешләре» дигән тематик төркем материаллары буенча төзелгән «Русча-татарча тематик сүзьясалышы сүзлеге» – Башкортстанның Туймазы шәһәрендә 2007 елда дөнья күрә. Икенчесе – шул ук елда Ф.С. Сафиуллина, З.Н. Кириллова, Ә.Ш. Йосыпова һәм И.Г. Мифтахова тарафыннан әзерләнгән «Татарча-русча тамырдаш сүзләр сүзлеге» – Казан федераль университеты нәшриятында басылып чыга. И.И. Сабитова хезмәтендә исә аларның да уңай яклары чагылыш тапкан. Нәтиҗәдә телебездәге «Кеше» тематик төркеменә караган лексик берәмлекләр сүзьясалыш ояларына туплап бирелгән, бу тематик төркемгә кергән сүзләрнең сүзьясалыш потенциалы шактый тулы һәм ачык күрсәтелгән, ояларга кергән ясалма сүзләрнең сүзьясалыш структурасы дөрес итеп билгеләнгән сүзлек барлыкка килгән.

Ирексездән, ни өчен төзүче шушы тематик төркем лексикасына мөрәҗәгать иткән соң?

дигән сорау туа. Моның җавабы бик гади. Кешенең тән әгъзаларын белдерә торган сүзләр – соматизмнар телнең иң борынгы катламына карый. Алар үзләренең телдә булган үзгәрешләргә аз бирелүчән булулары, даимилекләре, сүзьясалыш потенциалы югарылыгы белән аерылып тора һәм лексиканың иң тотрыклы тармагын тәшкил итә. Бу сүзләр күпсанлы, күпмәгънәле һәм көнкүрештә, аралашуда еш кулланыла, татар теленең төп лексик фондын хасил итәләр. Шуңа күрә дә авторның әлеге тематик төркем өчен сүзьясалыш сүзлеген төзүне максат итеп алуы гаҗәпләндерми.

Тәкъдим ителә торган әлеге сүзлек ике бүлектән тора. Сүзьясагыч ояларны тәшкил иткән төп бүлектән соң, ояларга урнаштырылган ясалма сүзләрнең алфавит тәртибендәге исемлеге дә бирелгән. Һәрбер ясалма сүз янында ул урнашкан ояның нумерациясенә туры килгән индекс та күрсәтелгән.

Сүзлек өчен материал күптөрле чыганаклардан – татар теленең төрле типтагы сүзлекләреннән, анатомия буенча дәреслек-кулланмалардан җыелган. Сүзлектә барлыгы 3325 сүз туплап бирелгән. Шуларның 3147 се ясалма сүз һәм алар үзләренең сүзьясалыш бәйләнешләрен саклаган 178 ояга урнаштырылган.

Татар телендә сүзьясагыч кушымчалар, гадәттә, нигез сүзне үзгәртмичә, аңа турыдан-туры ялганып, яңа сүзләр ясыйлар. Сүзлектә кайсы сүзьясалыш нигезенә нинди сүзьясагыч чаралар кулланып, нинди сүзләр ясалуы күрсәтелгән. Нигез сүзләрнең сүзьясалыш оялары эчендә деривацион таралышы һәм мөмкинлекләре дә ачыкланган. Ояга кергән ясалма сүзләрнең зур өлешен кушымчалау ысулы белән ясалган синтетик сүзләр тәшкил иткән. Мәсәлән:

**МЫЕК** *и. анат.*
    мыек-**лач** *и. зоол.*
    мыек-**лы** *с.*
    мыек-**сыз** *с.*
    мыек-**ча** *и.*
        мыекча-**лы** *с.*
        мыекча-**сыз** *с.*
            мыекчасыз-**лар** *и. күпл. зоол.*
    мыек-**чан** *с.*
...

Кушымчалаудан тыш, ояларда күпсанлы кушма сүзләр, шул исәптән парлы сүзләр дә урын алган: *эч-бавыр, эч-баш, эч-карын, эчәк-бавыр, йөз-кыяфәт* һ.б. Бу ояларда компонентлары кушылып язылган кушма сүзләр дә күп: *икейөзле, керфеккорсаклылар, йөззурлык, үрдәкборын, озынборын, каратүш, тәнкисәр* һ.б.

**АЯК I** *и. анат.* Әгъза
    ...
    аяк-кул *җый. и. к.* **кул**
    ...
    аяг/үрә *рәв.* [к//г]
    аяк/чу *җый. и.*
    аяк бит-*е и. к.* **бит**
    ...
    баш-аяк *җый. и. к.* **баш**
    алтын/сыман каз/аяк *и. бот.*
    баш/аяк *рәв. гади с. к.* **баш**
    ...
    агу-**лы** каз/аяк *и. бот.*
    ...

Татар телендә сүзьясалыш системасының тагын бер үзенчәлеге – аналитик конструкцияләрнең

күп булуы. Бу үзенчәлек «кеше» дигән тематик төркемгә караган сүзләрдән ясалган ояларда да чагылган: *бит алмасы, борын канаты, борын яфрагы* һ.б. Шул ук вакытта бу төркем кысаларында биология, медицина өлкәләренә караган күпсанлы терминнар да (*дагаборынлылар, үрдәкборын, йомшактәнлеләр, карга борыны, тәнкисәр, кызылтүш, күкрәк куышлыгы* һ.б.) байтак ясалган.

Сүзлекнең күләме 8,7 автор табагы һәм ул 600 данә тираж белән басылып чыккан. Сүзлек киң катлау укучыларга, мәктәп укытучыларына, студентлар, аспирантлар, галимнәргә тәкъдим ителә.

«Кеше» тематик төркеменә караган лексиканың сүзьясалышы сүзлеге – татар телендә аерым бер тематик төркем кысаларында төзелгән беренче хезмәт. Эзлекле фәнни принципларга таянып, җентекләп тикшерелгән, өйрәнелгән һәм сүзлеккә теркәлгән бай тел материалы телебезнең, борынгы чорлардан алып, хәзерге көнгә кадәрге үсешен, таралышын күзалларга ярдәм итә, һәм татар теленең искиткеч зур сүзьясалыш потенциалына ия икәнен тагын бер кат исбатлый.

***Сәфәров Ринат Таһир улы,***
*филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

**2017 елның 19–29 июнь көннәрендә** Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре Новосибирск өлкәсенең Колыван һәм Каргат районнарында комплекслы экспедициядә булдылар. Экспедициянең максаты – әлеге региондагы татар авылларын барлау, халыкның рухи һәм матди культурасын өйрәнү, тел үзенчәлекләренә һәм фольклорына кагылышлы материал туплау иде. Экспедиция дәвамында галимнәребез Колыван районының Умар (Юрт-Ора), Акбалык (Юрт-Акбалык), Казанка һәм Каргат районының Муса (Мусы), Җәйләү (Теренино), Кышлау (Шибаки), Форпост-Каргат авылларында яшәүчеләр белән очраштылар. Колыван районының Умар авылында чат татарлары, Акбалык һәм Казанка авылларында Идел буеннан күчкән Казан татарлары яши. Каргат районының борынгы төп халкы – бараба татарлары. Алар да төрле чорларда бирегә күчеп килгән Казан татарлары белән кушылган. Институт галимнәре Новосибирск галимнәре белән аралашты, Колыван районы җитәкчесе Виктор Аверин, Каргат аршәһәре мэры Олег Орел белән очрашты, аларга соңгы елларда институтта чыккан китапларны бүләк иттеләр. Олег Хисамов Каргат шәһәре телевидениесенә интервью бирде. Экспедиция нәтиҗәле эшләде, Новосибирск өлкәсендә яшәүче татар халкының мәдәни мирасын яктырткан бай материал тупланды.

**2017 елның 3–14 июль көннәрендә** ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре Ульяновск өлкәсе авылларына комплекслы экспедиция уздырдылар.

И.И. Ямалтдинов (фольклорчы) җитәкчелегендә Ф.З. Яхин (археограф), Н.Х. Нургаянова (музыка белгече), Ф.С. Баязитова, М.Р. Булатова (диалектологлар), Ф.И. Таһирова (тел белгече) һәм М.Р. Газизова (сәнгать белгече) өлкәнең 20 торак пунктында (Иске Кулаткы районының Иске Атлаш, Муса авылы (Мосеевка), Иске Мостәк, Урта Терешка, Кирюшкино, Иске Зеленый, Вязовый Гай, Яңа Зимичә (Нов. Зимницы), Иске Яндука авылларында һәм Иске Кулаткы бистәсендә; Карсун районының Нугай иле (Нагаево), Сакускай (Уразовка), Татар Горенкасы, Аксу (Тат. Голышкасы) авылларында; Мәләкәс районының Атнагыл (Аллагулово), Мөси (Моисеевка), Филипп авылы, Мукшы күле (Мордово озеро), Боровка авылларында) булдылар.

Галимнәребез анда татар халкының милли-мәдәни мирасын өйрәнеп тикшерделәр, тел, фольклор, сәнгать, музыка, археография өлкәсенә караган, шулай ук шушы төбәк өчен генә хас булган халык авыз иҗаты материаллары туплап кайттылар.

**2017 елның 20–22 июлендә** Кыргызстанда «Алтай цивилизациясе һәм алтай телләре семьясына кергән тугандаш халыклар» дип исемләнгән халыкара форум

булып узды. Форумның төп максаты – алтай телләре семьясына кергән халыкларны Евразия киңлегенә тартуны активлаштыру, алар арасындагы мәдәни, фәнни бәйләнешләрне ныгыту. Форум кысаларында тел, археология, антропология мәсьәләләре буенча дистәләгән чыгышлар ясалды, аларда алтай телләре семьясына кергән халыкларның тарихы, мәдәниятенең бүгенге проблемалары күтәрелде. Татарстан вәкилләре составында Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры К.М. Миңнуллин да катнашты.

**2017 елның 5 сентябрендә** Болгар ислам академиясен рәсми ачу тантанасы булды. Сүз, башлап, Татарстан Республикасы Диния нәзарәте баш мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллинга бирелде. РФ Президентының Идел буе федераль округы буенча вәкаләтле вәкиле Михаил Бабич, тантанага җыелган кунаклар каршында чыгыш ясап, халыкка дәүләт башлыгының котлау сүзләрен җиткерде. Владимир Путин юлламасында Болгар ислам академиясенең ислам тәгълиматын җиткерүдә эре үзәкләрнең берсенә әвереләчәгенә ышаныч белдерелә. Ислам уку йортын ачу алдыннан ТР Президенты һәм академия ректоры кабул итү имтиханнарын уңышлы үтеп, шушы уку йортына кергән 36 егеткә студент билетлары тапшырды. Аларның 27 се магистратурада белем алачак, ә 9 студент докторантура программасын үзләштерә башлаячак.

**2017 елның 3–5 сентябрендә** Казанда «Рухи ефәк юл. Иҗат. Берләшү» халыкара фәнни-дини конференция уздырылды, ул Болгар ислам академиясен рәсми ачу тантанасына тоташып китте. 5 сентябрь көнне конференция кысаларында Әбү Бәкер Каландарның Алтын Урда чорында язылып, фарсычадан тәрҗемә ителгән «Каландар-наме» дигән хезмәтен тәкъдим итү уздырылды. Китапны рус теленә тәрҗемә итү проекты ТР Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты М.Г. Госманов исем. Алтын Урда һәм татар ханлыкларын өйрәнү үзәге тарафыннан тормышка ашырылган. «Әбү Бәкер Каландарның “Каландар-намә”се: дини һәм тарихи аспектлар» дигән Түгәрәк өстәл әңгәмәсендә бу чараны оештыручылар, әлеге проект авторлары һәм Россиянең башка төбәкләреннән, Кытайдан, Иран, Казакстан, АКШ, Финляндия, Азәрбайҗаннан килгән галимнәр катнашты.

**2017 елның 7–8 сентябрендә** «Идел һәм Урал буе халыкларының тарихи язмышы» дигән тема буенча V Бөтенроссия фәнни форумы кысаларында һәм халыкара катнашлыгында «Идел һәм Урал буе халыклары инкыйлаблар арасында (1905–1917 еллар)» дигән Бөтенроссия фәнни конференциясе, «Идел һәм Урал буе халыкларының соңгы империя чоры тарихи чыганаклары» буенча Түгәрәк өстәл, «Габдерәшит Ибраһимов: иҗтимагый-сәяси эшчәнлегенең Россия чоры»на багышланган семинар уздырылды. Әлеге ча-

раларда Төркия һәм Германия галимнәре, Казан, Оренбург, Ульяновск, Чабаксар, Самара, Тольятти һәм башка шәһәрләрдән белгечләр катнашты.

**2017 елның 14 сентябрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, К. Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма һәм комедия театры белән берлектә, «Кәрим Тинчурин һәм татар театры» дип аталган Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе үткәрде. Әлеге чара Кәрим Тинчуринның тууына 130 ел тулу уңаеннан оештырылды. Конференция кысаларында Кәрим Тинчурин шәхесе һәм иҗатына бәйле көнүзәк проблемаларны ачыклау, милли театрлар репертуары тарихында аның иҗатын барлау, драматург әсәрләрен аңлауда музыка һәм сәхнә бизәлешенең өлеше хакында фәнни чыгышлар яңгырады. Фәнни-гамәли конференция Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы, Казан (Идел буе) федераль университеты, Казан дәүләт мәдәният институты, фәнни оешмалар, театр сәнгате белән бәйле уку йортлары, Татарстан Республикасы театрлары, Уфа дәүләт «Нур» театры, М. Фәйзи исемендәге Оренбург дәүләт татар драма театры, ТР Милли музее, архив хезмәткәрләре, ТР Язучылар берлеге һәм матбугат вәкилләре, аспирантлар, студентлар катнашында узды. Конференция барышында Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең кече зал фойесында Кәрим Тинчурин шәхесенә багышланган фәнни басмалар, театраль афиша һәм буклетлар, музей экспонатлары һәм драматургның шәхси әйберләреннән торган күргәзмә эшләде.

**2017 елның 28 сентябрендә** Алматы шәһәрендә казакларның күренекле язучысы М.О. Ауэзовның тууына 120 ел тулу уңае белән «М.О. Ауэзов һәм милләтнең рухи яңарышы» дигән Халыкара фәнни сипозиум уздырылды. Симпозиум эшендә Россия фәнни җәмәгатьчелеге исеменнән Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры Ким Мөгаллим улы Миңнуллин катнашты һәм «Милли традицияләр сагында төрки телле совет язучылары: Мөхтәр Ауэзов» («Тюркоязычные советские писатели на страже национальных традиций: Мухтар Ауэзов») дигән доклад белән чыгыш ясады. М. Ауэзовның Музей-йортына «Г. Тукай: энциклопедия»се, язучының 1960 елда татар телендә дөнья күргән «Абай» романы (Сәрвәр Әдһәмова тәрҗемәсе) китаплары бүләк ителде.

Научное издание

**НАУЧНЫЙ ТАТАРСТАН**
На татарском языке

Фәнни басма

**ФӘННИ ТАТАРСТАН**
2017. № 3

Бизәлеш авторы – Э. Бәшәрова
Компьютерда биткә салучы – Н. Абдуллина

Басарга кул куелды: 14.09.2017. Басылды: 28.09.2017
Офсет ысулы белән басыла. Гарнитура «Times».
Кәгазь форматы 70×108 1/16.
Басма табак 11,25. Тираж 500. Заказ

Журнал Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында әзерләнде

Редакция адресы:
420111, Казан шәһ., К. Маркс ур., 12
«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе
Тел. (843) 590-55-93
E-mail: f_tatarstan@mail.ru

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты
420111, Казан шәһ., Бауман ур., 20